**Сылтама өчен:** Җамалетдинов Р. Р., Нурмөхәммәтова Р. С. Ләбиб Леронның «114 адым» (2025) циклында лингво-стилистик үзенчәлекләр // Tatarica. 2025. № 2 (25). 7–20 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-7-20

## Кереш

«Телнең эстетик функциясе, нигездә, матур әдәбият стилендә тормышка ашырыла. Матур әдәбият стиле үзенең киң кулланылышта булуы ягыннан телдәге башка стильләрдән аерылып тора. Беренче нәүбәттә, ул үзенең нәфислеге, матурлыгы һәм эмоциональ яңгырашы белән игътибарны җәлеп итә. Анда күп төрле сөйләм үзенчәлекләре бергә кушыла. Барыннан да бигрәк, матур әдәбият стилендә сәнгатьчә сурәтләү чараларына зур урын бирелә һәм язучының үзенә хас алымнары киң чагылыш таба. Тел чаралары аша әйләнә-тирәне, чынбарлыкны, иҗтимагый күренешләрне сәнгатьчә кузаллау туа. Матур әдәбият, чынбарлыкның көзгесе буларак, үз эченә җәмгыять тормышының күп якларын ала. Анда халыкның үткәне дә, хәзергесе дә ачык гәүдәләнә. Шунлыктан, матур әдәбият стиленең тел чараларын сайлап алуда, милли әдәби тел нормаларын эшкәртүдә һәм үстерүдәге специфик яклары шуннан чыгып та билгеләнә», – дип яза тел белгече В. Хаков «Стилистика һәм сүз сәнгате» хезмәтендә [1, б. 3].

Х. Курбатов фикеренчә, «стилистика телнең җанлы хәләтен өйрәнә, сүз, җөмлә, аваз һәм интонациянең мәгънә һәм тәэсир көче нечкәлекләренә игътибар юнәлдерә, тел хәзинәсендәге әлеге байлыкларның кайсы кайда, ничек һәм нинди максат белән файдалануын билгели» [2, б. 17].

Татар тел белемендә стиль төрлелекләре турында кайбер фикерләр XVIII гасырда ук күренә башлый (С. һәм И. Хәлфиннар, Н. Ф. Катанов, К. Насыйри). XX йөз башында Г. Ибраһимов, Х. Бәдигый, Л. Җәләй, В. Хангилдин һ.б. үзләренең хезмәтләрендә стильләргә кагышлы проблемалар күтәрәләр. 1950 нче еллар ахырыннан башлап, стиль мәсьәләләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә башлый (М. Бакиров [3], И. Бәширова [4, 5], Х. Курбатов [1, 6], В. Хаков [2, 7] һ.б.). Бу галимнәрнең тикшеренүләре стилистиканың күп кенә яңа проблемаларын һәм юнәлешләрен билгеләп, функциональ стилистика төп юнәлеш буларак эзлекле рәвештә интенсив үсә башлый.

## Тикшерү материаллары һәм методлары

Бу мәкалә, Ләбиб Леронның «114 адым» (Унбер каһарман эзеннән) исемле циклында [8] урын алган әсәрләрен тикшерү объекты буларак алып, татар сүзенең сәнгатьчә тәэсир итү көчен, эстетик функциясен һәм тел байлыгыннан файдалану мөмкинлекләрен ачуга юнәлтелгән. Эзләнү барышында текстлар семантик-стилистик анализ, «сүз-сурәтләмә», күзәтү, тасвирлау методлары һәм алымнары кулланылып тикшерелде.

## Фикер алышу

«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон 2015 елда, җәлилчеләр авылларын йөреп чыгу бурычын куеп, «11 батыр» дип аталган проект башлап

җибәрә. Аның бу эшенә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты да кушыла.

Проектта катнашучыларны җәлилчеләр авылларының хәзерге хәле, шул исәптән, аларда никадәр кеше яши, мәктәпләр бармы, булса каһарманнарның исемнәре бирелгәнме, авылдашлары хәтерендә сакланалармы кебек сораулар кызыксындыра. Дөрес, җәлилчеләрнең кайберләре, мәсәлән, Абдулла Алиш, Муса Җәлил бу авылларда ел саен искә алына. Моннан тыш, бары тик Марий Элдәге бер мәктәп кенә Гайнан Кормаш исемен йөртә. Л. Лерон 2024 елдагы бер әңгәмәсендә: «Чит төбәкләрдән чыккан Әхмәт Симай, Әхәт Атнашевларга мөнәсәбәт ничек икән? Аларны да онытмаска иде», – дип, бу эшнең максатын билгели һәм: «Гомерләрен кызганмаган шәхесләрнең барысын да тигез дәрәҗәдә искә алырга тиешбез. Алар арасында биш шагыйрь дә бар. Барысын да истә тотарга кирәк», – дигән фикерен ассызыклый [9].

Проект барышында «Интертат» электрон газетасы битләрендә «Җәлилчеләр җире» исемле рубрика барлыкка килә (җитәкчесе – Гөлүзә Ибраһимова). Проектны тормышка ашыруда олпат язучылардан – Ләбиб Лерон, Вахит Имамов, яшьрәк буын вәкилләреннән Рөстәм Галиуллин катнаша [10]. Ләбиб Лерон башлап җибәргән «11 батыр» проекты нәтиҗәдә «114 адым» (114 адым – үлемгә хөкем ителгәннәр камерасыннан гильотинага кадәр җәлилчеләр үткән ара) исемле поэтик цикл буларак дөнья күрде.

А.С. Пушкин иҗатында урын алган цикллар үзенчәлекләрен тикшергән М.Н. Дарвин һәм В.И. Тюпа кебек галимнәр: «Европа сәнгать теориясендә «цикл» беренче тапкыр XVIII-XIX гасыр чикләрендә, романтизм формалашкан чорда барлыкка килә» дигән фикер әйтәләр. А.В. Шлегель исә: «бары тик элгәреләр яки аннан соңгылар аркасында гына тулы мәгънәлегә әйләнгән күренешләр циклик формага ия була алалар» дип искәртүне кирәк саный» [11, б. 5 ].

Әдәби терминнар һәм төшенчәләр энциклопедиясенә килсәк, циклләштыруга биредә түбәндәге билгеләмә бирелә (грек. Kyklus – түгәрәк, тәгәрмәч): «...бу – берничә мөстәкыйль әсәрне үзенчәлекле бербөтенгә берләштерү. Әдәбият үсешенең барлык этапларында да циклларны табарга мөмкин...» [12, б. 1190]. Лирик цикл бердәмлеге (шигырьләр циклы) XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы шагыйрьләре тарафыннан аерым өлешләрдән яки бүлекләрдән торган зур күләмле әсәргә тиң бербөтен буларак карала [13].

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, Л. Леронның «114 адым» әсәрен цикл дип бәяли алабыз, чөнки ул гомуми исем белән берләштерелгән аерым шигъри текстлар бөтенлегеннән гыйбарәт. Әлбәттә, авторга аерым шигырьләрен цикл бөтенлегенә оештыру, туплау өчен, үз иҗатына хас булган цикл принципларын һәм сәнгати формаларны уйлап табарга кирәк була. Шул ук вакытта һәр әсәре үз мөстәкыйльлеген һәм төгәллеген саклап калырга, шуның бәрабәренә «яңача җемелдәүче бербөтен» барлыкка килүен тәэмин итәргә дә тиеш була [14].

Л. Леронның бу әсәрендә цикл идеясе композиция белән дә раслана: ул 1942 елдан 1943 елның августына кадәр «Идел-Урал» легионында эшчәнлек алып барган татар яшерен оешмасының 11 әгъзасына (Әхмәт Симаев, Гариф Шабаев, Сәлим Бохаров, Зиннәт Хәсәнов, Фуат Булатов, Абдулла Баттал, Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Муса Җәлил, Әхәт Атнашев, Фоат Сәйфелмөлеков) багышланган шигырьләрдән тора. Шул ук вакытта һәрбер шигырь – яшерен төркем әгъзаларының каһарманлыгына багышланган мөстәкыйль әсәр буларак кабул ителә.

Л. Е. Лапина фикеренчә, лирик циклның композициясе, «бер үзәкле, үзәккә омтылучанлыгы» белән аерылып тора [15, б. 123]. Л. Лерон циклның өстәмә исемендә («Унбер каһарман эзеннән») композициянең доминантасын күрсәтә, шунлыктан автор сюжетны, геройларның батырлык юлларын калкуландырып күрсәтү максатыннан, хәтер музее буйлап сәяхәткә кора. Кормаш-Җәлил төркеме батырлыгы феноменына төшенүгә багышланган «батырлыкка хәтле юл үтәсе» [8, б. 3] сәяхәт Л. Лерон циклының лирик сюжетына әверелә һәм автор лирик сурәтләү принцибын куллана.

Әсәрнең сәнгати бердәмлеге исә әдәби контекстта формалаша, ул әдәби традиция фонында барлыкка килә.

1946 елда Татарстан Язучылар берлегенә, М. Җәлилнең төрмәдә язган 60 шигыреннән торган блокнот тотып, элекке хәрби әсир Нигъмәт Терегулов килә. Аннары Брюссельдәге совет консуллыгына Каршылык күрсәтүдә катнашучы бельгияле Андре Тиммерманс саклап калган икенче блокнотны китерәләр. «Моабит дәфтәре»ннән шигырьләр Константин

Симонов кулына элэгэ һәм ул аларны рус теленә тәрҗемә итүне оештыра. Шулай итеп, Муса Җәлилнең батырлыгы бөтен илгә мәгълүм була. 1956 елның 2 февралендә СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә, немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә күрсәткән ныклыгы һәм батырлыгы өчен, Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 1966 елда Казанның 1 Май мәйданында герой-шагыйрь истәлегенә монументаль комплекс барлыкка килә.

Җәлил! –
Күп тә үтмәс, һәйкәл булып,
Казаннарда калкыр бер заманны... [8, б. 3].

Җәлил турындагы әдәбиятның күләме турында без аның исеме белән бәйле библиографик күрсәткеч буенча фикер йөртә алабыз. Ул 1976 елда университетыбызда басылып чыга. Аңа 1919–1973 елларда дөнья күргән 2690 китап кертелә. Бүгенге көнгә бу исемлек күп тапкырлар арткан, бу – М. Җәлилне герой-шагыйрь итеп сурәтләүнең ныклы әдәби традициягә әверелүенә тагын бер дәлил. Менә шуңа да циклның кереш өлешендә Л. Лерон татар шагыйренә «рухи әйдаман», Ватаннарына тугрылык йөзеннән «Ил-милләте» шәһите [8, б. 4] булу өчен, үзләрен газаплы үлемгә дучар иткән 11 батырның рухи лидеры [8, б. 3] статусын бирә. Аларның яшьлеге легендар да, каршылыклы да 1920 елларга туры килә, шуңа күрә шагыйрь Әхмәт Симаевка багышланган әсәрендә «барабаннар кагып үтәр яшьлек» дип яза [8, б. 4].

Геройлар язмышының фаҗигалелеге хыял һәм чынбарлыкның антитезасы аша тудырыла: «үтәсе юл озын» – «үтәсе юл кыска» [8, б. 4]. Нәтиҗәдә геройлар юлы зур символга әверелә:

Үтәсе юл сират күпередәй –
Кылдан нечкә, үткен кылычтан да... [8, б. 4].

Шуның бәрабәренә шәһит сүзе укучылар күз алдында дини эчтәлекле – иман өчен корбан булган кеше мәгънәсен ала. Моңа шигырьләргә Сират күпере образы кертелү нәтиҗәсендә дә ирешелә. Әхмәт Симаев көрәштәшләре белән бергә яшьлегендәге революцион идеалларына тугры кала һәм Берлинның Плетцензее төрмәсендә һәлак була. Текстта сынаулар темасы «бик нечкәләп, кат-кат тикшерү» [18, б. 353] мәгънәсенә ия булган «җиде иләктән үткәрү» фразеологизмын куллану нәтиҗәсендә ачыла. Шагыйрь шигырендә, «җиз иләк» образын куллану аша, читләтеп әйтү алымына мөрәҗәгать итә. Германия рейхының империя суды озак тикшерүдән соң «Кормаш һәм башка ун төркем» эше буенча, «Рейх мәнфәгатьләренә хыянәт иткән өчен» дигән формулировка белән, күмәк үлем хөкеме чыгара. Аллаһы Тәгалә каршында алар җәза көнендә шәһитләргә әвереләләр. Әмма цикл юллары артында легионерларга карата оештырылган совет тикшерүе дә чагылып китә.

Яшерен оешма әгъзасы Гариф Шабаевны искә алып, шагыйрь аның Башкортстанның Иске Турай авылында туып-үскән булуына басым ясый. Бу геройның шәхси язмышы турында фикер йөрткәндә, автор төрки халыклар эпосы юлларындагы читләтеп әйтелгән фәлсәфи сорауны куя:

Илләр язмышымы – дүңгәләктәй?
Гомер агышымы – күбәләктәй?
Көн тудисә, күктә ут дөрли.
Янган мичкә күмер төшә диләр [8, б. 5].

Бу читләтеп әйтүдә язмыш вариантларының күплегенә ишарә бар, аларның кайсын сайлау – бу шәхес ихтыярында. Моның белән шагыйрь безнең халкыбыз телендә әле дә актив кулланылышта булган *кеше – күмер* чагыштыруын яңарта (мисал өчен, Яман кеше утлы күмер кебек: көйдерә дә, каралта да). Гариф Шабаев фашист төрмәсендә ата-бабаларының намусына тап төшерми, кайчандыр язмыш үзен илтеп ташлаган үзбәк Алты-Арыгын да батырлыгы белән яктырта:

Иске Турайдагы тояк эзе,
Алты-Арыктагы кояш йөзе
Күз нурында калды тулышып... [8, б. 5].

Уфа губернасының Миякә авылында туып үскән Галләнур Бохараев тормышын сурәтләгәндә шагыйрь Казан финанс хезмәткәрләре курсларын тәмамлаган егет биографиясенең чынбарлыктагы фактларын фаҗигале язмыш метафорасына әйләндерә:

Исәп-хисап. Гомер. Соңгы сынау...
Әҗәл үзе... тарта... чут төймәсен...
Ярты сәгать…һәм...өч минут бары..
Кинәт... кыеп үтә... ут көймәсе... [8, б. 5].

Биредә дини мәгънәле шәһитлек хәвефле канатлары белән туган җирне каплаган, гомер хисабы – чут төймәләренең соңгысын тартучы куркыныч Әҗәл мифологик образы аша күзаллана: «Илдә-көндә хәвеф канат җәйгән» [8, б. 5].

Шигырьләр арасындагы дәвамлы бөтенлекне, нәтиҗәдә цикллыкны үтәли тоташтырып торучы *җан – күбәл*әк образы да бар. Автор моңа чагыштыру нигезенә салынган маскарад битлеге темасы ярдәмендә ирешә:

«Ак Күбәләк төсле аклык кунды / Галләнурның тыныч ал йөзенә» [8, б. 5]. Әсирлектә үзен Сәлим Бохаров дип атаган яшерен көрәшченең үлемен шагыйрь реалистик алымнар белән тасвирлауга ирешә.

Сарман районының Иске Кәшер авылында туып-үскән егеткә багышланган шигырендә Л. Лерон иләк ярдәмендә фольклор темасын үстерә (мәсәлән, Иләк асты җилгә, / Өсте ярый илгә). Аның өчен ил өстенә килгән бәладән читтә калу мөмкин түгел:

Дөнья куласа күк: бер урында тормый,
Әйләнә дә баса бер заманны;
Аста кала – якты еллар, ак хыяллар,
Өскә менә – чорның бар яманы [8, б. 5].

Л. Лерон, Совет татарларының Октябрь инкыйлабыннан соң илдән күчеп килгән татарлар белән әсирлектә очрашуларын күрсәтү өчен, Дәрдемәнднең атаклы «Кораб» шигыреннән өземтәгә мөрәҗәгать итә һәм әсәрендә «юл сайлау» темасын кабат күтәрә. Зиннәт Хәсәнов Гайнан Кормаш һәм Муса Җәлилнең башка көрәштәшләре юлын сайлый. Ул яшерен оешмадагылар кушуы буенча легионның музыкаль капелласында җырчы һәм укучы-декламатор буларак катнаша, бер үк вакытта легионерлар арасында листовкалар да тарата.

Шагыйрь әсәрендә татар кешесенең җанын актару (айкау) сәләтенә ия булган «Сарман җыры»н күп мәгънәле образ буларак кулланыла. Әлеге җыр, бер яктан, геройны туган җире белән бәйли һәм аның легионның музыкаль капелласында катнашуын да күрсәтә. Икенче яктан, бу җырның иҗат ителү тарихына мөрәҗәгать итсәк, аңа М. Җәлилнең турыдан-туры катнашы булуын һәм Мәскәүдәге татар опера студиясе тарихына бәйлелеген күрәбез. Усман Әлмиев аны композитор Заһит Хәбибуллин белән бергәләп, Мәскәү консерваториясендәге Опера студиясенең йомгаклау концерты өчен, халык җырлары мотивында иҗат итәләр. 1938 елда җыр радиодан башкарыла һәм тиз арада популярлык казанып, халык җыры рәтендә йөри башлый.

Яшерен оешманың тагын бер әгъзасы Фуат Булатовка багышланган шигырендә Л. Лерон аның шәхси язмышы образын метафоралаштыра һәм тормышны чоңгылында йомычка бөтерелергә мәҗбүр елга белән чагыштыра. Кырыс чынбарлык геройның хыялларын күңел кайту салкынлыгы белән җанын көйдерә торган күмергә әйләндерә. Фуат Булатовны шагыйрь коточкыч сугыш ялкынында янып беткән күбәләккә охшата. Геройның үлем драматизмы өзелгән кылның нәфис музыкаль образы («өзелде кыл») аша ирештерелә. Геройның җаны зинданның таш идәненә тамган кан тамчылары тавышының кайтавазы булып терелә:

Өзелде кыл. Тамды ташка өмет.
Сулкылдады бер моң...
сулык-сулык... [8, б. 7].

Монда үлем мизгеле, киресенчә, батырлык үлемсезлегенә каршы куела.

Шул рәвешле автор Муса Җәлилнең өзелгән җыры темасын яшерен генә сиздерүгә ирешә. Биредә Мәләвездән килгән инженер-төзүченең Герой-шагыйрь белән сугышка кадәр үк Оренбургта танышканнарын билгеләп үтәргә кирәктер.

Абдулла Батталга багышланган шигырендә шагыйрь 1917 елның октябреннән соң башланган тарихи ыгы-зыгыга эләккән татар халкының фаҗигале язмышы турында уйлана. Абдулла Баттал упкыннан чыга: төрмәдә Кормашның, Җәлилнең көрәштәшенә әверелә. Әсәр лирик героеның «гомер минем кыска булыр сыман» [8, б. 7] дип сиземләве, цикл авторы фикеренчә, чынга ашмый, чөнки Абдулла Баттал, 11 батыр сафына басып, халкы хәтерендә үлемсезлеккә ирешә: «Ялгышкан ул... Озын булды гомере: / Мәңге яши, әнә 11 батыр» [8, б. 7].

Гайнан Кормаш турында язган шигырендә революция еллары гаять авыр, тынгысыз еллар буларак күзаллана. Геройның 1937 елда кичергәннәре шагыйрь тарафыннан совет лозунглары аша оста тасвирлана:

Хакимлек ит дисәң – хөсетләргә,
Явызларга бирсәң мөмкинлекләр,
Чәнечкеле зур бер биләмәгә
Әверелер иде бу киңлекләр... [8, б. 8]

Кулак улы тамгасы сугылган Гайнан туган җиреннән качып кына кулга алынудан котылып кала. Фашистлар төрмәсенә эләккәч, ул тәнендә камчы эзләре калдырган, төзәлмәс яра ясаган Ватанында Җиңү сәгатен якынайту өчен, көрәш юлына басуны өстен күрә.

Геройның кичерешләрен җиткерү өчен, Л. Лерон ант интонациясенә мөрәҗәгать итә: «Бирешмәскә! Ахыргача – бергә!». Яшерен оешма әгъзаларының тормышы бу эпизодта утлы күмер белән ассоциацияләнә, аның яктысы әйләнә-тирәдәге караңгылыкны бер мизгелгә җиңә. Әлеге үлем шаһитләре каһарманнарның җәзалап үтерелү алдындагы батырлыкларына таң калалар. Монда кан

тамчысы 11 гомер символына әверелә: «Таш идәнгә тамды унбер гомер...» [8, б. 8].

Әкиятче-язучы Абдулла Алиш язмышы турында уйланып, Л. Лерон Болгар тарихының хронотобын актуальләштерә. Геройның үлемен шагыйрь тормыш үренең иң югары ноктасына күтәрелү белән ассоциацияли («Менеп бара гомер үрләренә» [8, б. 9]). Батырлыкның үлемсезлеге темасы геройның гильотина бәрелүеннән җиргә миллионлаган очкын булып сибелгән күз карашы кояшы образы аша тапшырыла.

Шигырьдә авторның Муса Җәлилнең батырлык феномены хакындагы фикерләре татар халкының язмышы һәм язмыш сынаулары каршында ныклыгы турында уйлануларга әйләнә. Л. Лерон укучысына батырлык чыганакларын ата-бабаларның героик үткәненнән эзләргә кирәк дигән фикерне җиткерә. Бу фикерне көчәйтү өчен, шагыйрь *батырлык, каһарманлык, гаярьлек; вөҗдан, намус; батыр, шәһит; милләт уллары, газиз балалар* дигән синонимнар рәтенә мөрәҗәгать итә. Болардан тыш, текстта *кайгы-хәсрәт, фараз-сорау, шифа-дәва, хәсрәт-афәт, зәхмәт-кырау, хан-әмир* кебек сүз парлары очрый. Татарларның милли психологиясе антитезада ачыла:

Эшләгәндә билен бөккән татар,
Яулар килсә, билен турайткан ул.
Баш имәгән, баш бирмәгән татар
Үзен данлап, илен зурайткан ул! [8, б. 9]

Бу шигырь композициясе нигезен Җәлилгә, көрәштәшләренә хас характерның төп сыйфаты – шәхеснең героик потенциалы тәшкил итә. Герой-шагыйрь образы артында Ватанны саклаучы халык образы калка. Л. Лерон бу көрәшче татарлар батырлыгын пычратучыларның әле дә барлыгына әрни, аларның эш-гамәлләрен, М. Җәлилнең мәшһүр шигырен бераз үзгәртеп, варварлык дип бәяли. Ватан өчен һәлак булганнарны онытмау темасы бу текстта яңача үсеш ала: «Нигә кайбер милләт улларының / Үлгәчтен да һаман кадере юк?» [8, б. 9]. Шагыйрь яшерен оешмачылар тарихының ни өчен төзәлми торган ярага әверелүен аңларга тырыша. Л. Лерон һәлак булганнар истәлеге алдында геройларның туганнарының җаваплылыгы темасын күтәрә: «Нәселләре бүгенге ни хәлләрдә?» [8, б. 9].

Әхәт Атнашев турындагы шигырендә Л. Лерон төрмәнең күп катлы образын – таш капчыкны гәүдәләндерә. Анда элекке ориентирлар буталган, анда кем хыянәтче, кем дошман икәнен аңлау кыен, ә тормыш коточкыч төшкә охшап кала, аның кочагыннан ычкыну мөмкин түгел.

Шагыйрь яңадан сугышчан бердәмлек, геройларның хыялларын һәм өметләрен мәңгегә сызып ташлаган 114 адымлы үлемсезлек юлы турында искә төшерә. Монда тереклекнең сүнүе лампадагы фитилнең сүнүе белән чагыштырыла. Догалар дискурсы шагыйрьнең Кормаш төркемендәге көрәштәш-каһарманнарның исемнәрен догада искә алырга чакыруында кабат үзен сиздерә.

Фоат Сәйфелмөлеков турындагы шигырендә Л. Лерон, тормыш-көрәш мотивын үстереп, замандашлары хыялларын утка ыргыткан, язмышларын канга батырган дәһшәтле XX гасыр портретын кертә. «114 адым» циклы авторының җаны татар халкының Мәңгелеккә күчәргә мәҗбүр булган легендар улларының күңел әрнүенә җавап бирә.

Цикл текстларының бөтенлеге әсәрләрдәге көчле позициядә торган үтәли образлардан тыш, шигырь исемнәрендә дә яшерелгән: *Утәсе юл – гомер...; Янган мичтә күмер төшә диләр...; И давыллы гомер...; Зилзиләләр купса; Тамды ташка өмет...; Айның сүнгән чоры; Ташта – тамчы, тәндә – камчы эзе; Күзләрдәге кояш; Батырлыкка дәлил; Яшәү чиге; Үлем юлы.*

**Төп нәтиҗәләр**

Әдәби әсәр иҗат итү автордан тел байлыгын, сүзләрнең эчке потенциалын иҗади рәвештә файдалана белүне сорый. Тел – язучының төп материалы. Л. Лерон шигъри циклын язганда, тарихи контекст тудыру өчен, төрле чорга туры килгән образ-сурәтләрдән иркен файдалана. Алар текстта көчле позицияләрдә кулланылалар. Татар теле сүзлеге хәзинәсеннән язучы синонимик чылбырлар тудыра: *зилзилә, давыл, туфан, гарасат; хатирә, истәлек; аркадашлар, көрәштәшләр; адәм, бәндә, милләт улы; тәмуг, җәһәннәм; кузы, күмер* һ.б. Әсәрнең стилендә, эмоциональ башлангыч беренче планга чыгып, синтаксиска да үз йогынтысын ясый. Л. Лерон еш кына риторик сораулар бирә, өндәү конструкцияләрен куллана. Язучының максаты – укучыны тетрәндерү, хәтерендә каһарманнарга карата хөрмәт хисе уяту. Әсәрдә язучы, 11 батыр портретын тудыру белән беррәттән, алар артында калкыган халык һәм чор портретларын да үстереп җибәрүгә ирешә. Батырларның шәхси портретларын

сурәтләгәндә Л. Лерон алар биографиясенә бәйле топонимик лексиканы (*Мостафа, Яңа Аллагол, Иске Турай, Кыргыз Миякә, Олы Тигәнәлек, Көек* һ.б.) да еш куллана. Батырларның туган авыллары тора-бара *Татар иленә, Ватанга* әверелә. Бу мәгънәдә ул *туган җир, ил-көн, дөнья* сүзләренең эчке потенциалын уңышлы куллана. Шагыйрь каһарманлык тамырларын ачу өчен борынгы төрки сүзләргә мөрәҗәгать итү алымын да куллана. Язучы еш кына, портретларны төгәл итеп күрсәтү өчен, чагыштырулардан файдалана, табигать күренешләрен эчке хисләр белән янәшә куя. Шагыйрь стилистик максатларда аерым сүзләрнең, фразаларның кабатлануына корылган сурәтләргә аеруча игътибарлы.

Әйе, батырлык онытылмый һәм ул күпләрне иҗатка рухландыра. М. Җәлилгә багышланган, аның иҗатын өйрәнеп язылган хезмәтләрнең, әсәрләрнең саны бихисап. Без биредә аларның күпсанлы булуын әйтеп үттек. Алар хәзерге буынны да битараф калдырмый. Без әлеге мәкаләдә карап үткән «114 адым» шигъри циклы шагыйрь Ләбиб Леронның җәлилчеләрнең туган якларына сәяхәт кылганнан соң дөнья күргәнлеген дә ачыкладык. Моның шулай икәнлеге, авторның каһарманнарга җан биргән, аларны үстергән яклардан алган хисләре шигырьләренең һәр юлыннан күренеп тора. Циклның лингво-стилистик үзенчәлекләрен барлау телебезнең бүгенге көндәге торышын, тел-сурәтләү чараларының кулланылу активлыгын билгеләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. *Хаков В. Х.* Стилистика һәм сүз сәнгате. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 158 б.
2. *Курбатов Х. Р.* Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. Казан: Мәгариф, 2002. 199 б.
3. *Бакиров М. Х.* Шигърият дөньясына сәяхәт. Фольклордан язма шигырьгә күчеш тарихыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 238 б.
4. *Бәширова И. Б.* Сүз белән сурәт ясау. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 175 б.
5. *Бәширова И. Б.* Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 97 б.
6. *Курбатов Х. Р.* Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 19 б.
7. *Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (Стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.
8. *Лерон Л.* «114 адым» (Унбер каһарман эзеннән): цикл // Казан утлары. 2025. №8. Б. 3–10.
9. *Ибраһимова Г.* Ләбиб Лерон җәлилчеләргә багышланган яңа проект турында: Аларны онытмау максаты тора // URL: https://tatar-inform.tatar/news/labib-leron-alilcelarga-bagyslangan-yana-proekt-turynda-alarny-onyttyrmau-maksaty-tora-5890624?ysclid=mgdobrtmmo916467318 (мөрәҗәгать итү вакыты 30.07.2025)
10. *Мөхәммәтова Р.* «Җәлилчеләр җире»: Башта авылларда бер Гөлүзә йөрсә, инде 3 олпат шәхес килеп төшсен әле! // URL: https://intertat.tatar/news/alilcelar-ire-basta-avyllarda-ber-goluza-iorsa-inde-3-olpat-saxes-kilep-tossen-ale?ysclid=mgdovrhsza114650438 (мөрәҗәгать итү вакыты 24.07.2024)
11. *Дарвин М.Н., Тюпа В.И.* Циклизация в творчестве Пушкина: Опыт изучения поэтики конвергентного сознания. Новосибирск: Наука, 2001. 292 с.
12. Литературная энциклопедия терминов и понятий / гл. ред. и сост. А.Н. Николюкин. М.: Интелвак, 2001. 1600 с.
13. *Белоусова О. О., Дашевская О. А.* Поэтика цикла и книги в современном литературоведении // Вестник Томского государственного университета. 2014. № 389. С. 6–14.
14. *Фигут Р.* Лирический цикл как предмет исторического и сравнительного изучения. Проблемы теории // Европейский лирический цикл. Историческое и сравнительное изучение. М.: Российский государственный университет, 2003. С. 11–37.
15. *Ляпина Л. Е.* Лирический цикл как художественное единство // Проблема целостности литературного произведения. Воронеж, 1976. С. 123.
16. Муса Джалиль: библиографический указатель, 1919-1973. Казань: Изд-во Казанского университета, 1976. 220 с.
17. *Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: ике томда. II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 365 б.

# ЛИНГВОСТИЛИСТИЧЕСКОЕ СВОЕОБРАЗИЕ СТИХОТВОРНОГО ЦИКЛА ЛЯБИБА ЛЕРОНА «114 АДЫМ» («114 ШАГОВ», 2025)

**Радиф Рифкатович Замалетдинов**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
sovet.rus16@gmail.com.

**Раушания Сагдатзяновна Нурмухаметова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
rsagadat@yandex.ru.

Статья посвящена рассмотрению особенностей функционирования языковой личности автора в художественном тексте. Материалом исследования послужил стихотворный цикл Лябиба Лерона «114 шагов» («По следам 11 героев»). Произведение посвящено 80-летию Победы в Великой Отечественной войне. Автор воспевает подвиг группы Курмаша-Джалиля. Цель исследования – выявить роль изобразительно-выразительных средств, способов связи, употребления и динамического взаимодействия слов, выражений и конструкций во внутреннем композиционно-смысловом единстве стихотворного цикла писателя. В ходе лингвостилистического и лингвопоэтического анализов текста выделены лингвистические средства, с помощью которых достигается эстетическое воздействие произведения. В «114 шагах» выделяются образ-персонаж, образ-представление, где воплощается татарская концепция героизма. У Лябиба Лерона эмоциональное восприятие языка постоянно сопровождается восприятием аналитическим. Поэт стремится в этом произведении лиричность соединить с историзмом.

**Ключевые слова:** татарский язык, лингвостилистика, стихотворный цикл, группа Курмаша-Джалиля, Л. Лерон

**Для цитирования:** Замалетдинов Р. Р., Нурмухаметова Р. С. Лингвостилистическое своеобразие стихотворного цикла Лябиба Лерона «114 адым» («114 шагов», 2025) // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 7–20. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-7-20

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-21-33

# THE PLACE OF THE LINGUOCULTURAL CONCEPT "SUGYSH" ("WAR") IN THE TATAR NATIONAL CONSCIOUSNESS

**Gulnaz Irshatovna Ziyatdinova,**
Kazan National Research Technical University named after A.N. Tupolev – KAI,
55 B. Krasnaya Str., Kazan, 420015, Russian Federation,
ggulnaz0507@mail.ru.

**Alfiya Shaukatovna Yusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
alyusupova@yandex.ru.

**Firuza Ramzilovna Sibgaeva,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
FiruzaRS88@yandex.ru.

To reveal the universal and specific aspects in the perception of reality by representatives of various linguocultural traditions, it is necessary to conduct a comprehensive analysis of the main cultural concepts found in linguistic materials. Our analysis is based on lexicographic sources. The purpose of our study is to identify the semantic, linguocultural, and associative components that comprise the semantic structure of the "Sugysh" ("War") concept. The significance of cultural concepts is determined by frequency of their use. They are incorporated into phraseological units, proverbs, sayings, poetic, and song texts. As a socio-political phenomenon, this concept has a multifaceted definition in the Tatar language. It is studied by different sciences – history, political science, philosophy, sociology, etc. The theme of war holds a significant place in literature and art, reflecting the past and the present of the Tatar people. The article proves that the concept of "war" has a complex structure, consisting of different groups of features.

**Key words**: war, linguistic worldview, linguocultural concept, national concept sphere, Tatar language

**For citation:** Ziyatdinova, G., Yusupova, A., Sibgaeva, F. The place of the linguocultural concept "sugysh" ("war") in the Tatar national consciousness // Tatarica. 2025. № 2 (25). pp. 21–33. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-21-33

## Introduction

Language not only reflects reality, but also interprets it, creating a unique reality a person lives in. "Essentially, a person lives in the world of concepts (mental entities), that were created to satisfy intellectual, spiritual, and social needs, since a significant part of information comes through the word. A person's success in society depends not only on language proficiency, but also on speech culture and ability to penetrate the secrets of language" [1].

The intensive study of issues, related to the reflection of the interconnection between human life and culture in language by linguists, anthropologists, historians, and cultural experts, has led to the emergence of the linguacultural approach in the investigation of this problem. Of great importance for this approach is the theoretical and practical description of the cultural values system in language as a whole.

Cultural linguistics as a science was formed in the second half of the 20th century. According to V. Maslova, cultural linguistics emerged at the intersection of linguistics and culture, it studies the reflections of folk culture found and fixed in language [1, p. 14].

As of the current date, there are four main trends in linguocultural research: 1) the phraseological trend (by V. Telia); 2) the logical-linguistic or conceptological trend (by N. Arutyunova, A. Wierzbicka); 3) the lexicographical trend (by V. Rudnev, Y. Stepanov); 4) the linguodidactic trend (by V. Vorobyov).

In Tatar linguistics, the problems of the linguistic worldview are reflected in the works of R.

Zamaletdinov. In 2004, his monograph titled "Tatar Culture in Linguistic Reflection" was published. The work explores the features of conceptualization of fragments of people's material and spiritual worlds in the Tatar linguistic worldview. The monograph sheds light on the problem of the world representation in the Tatar language and creates a basis for further research in this field [2].

A person lives in a world of concepts. According to the scientific interpretations of S. Askoldov, E. Kubryakova, S. Lyapin, and O. Skidan, a concept is a "multidimensional mental construct that reflects the process of the world cognition, the results of people's activity, their experience and knowledge about the world, and stores information about it" [3, pp. 40–59].

The analysis of key cultural concepts in linguistic research is necessary to reveal uniqueness and universality in perception of reality by representatives of various linguo-cultural communities. In this regard, of great importance is to identify the cultural component of the concept "Sugysh" ("War") in the Tatars' linguistic worldview. This concept, as a socio-political phenomenon, has numerous and various definitions in the Tatar language.

**Research materials and methods**

To determine the semantic scope of the concept, it is necessary to consider the referential situations it pertains to. During the study, such methods as the linguocultural analysis, the analysis of lexical entries, and the conceptual analysis were employed.

**Discussion**

A concept is a multidimensional unit, which comprises not only definitional characteristics, but also connotative, figurative, evaluative, and associative descriptions. All the listed features must be taken into account when describing a concept. Concepts are capable for conveying information ranging from the elementary notions to the most complex conceptual structures of high-level abstraction.

The study of concepts begins with thematic and etymological dictionaries. The work ("Kyskacha ruscha-tatarcha sugysh sүzlәre (tylmachy)" ("Russian-Tatar Military Dictionary")) published in 1926, was the first attempt to organize and systematize military-related lexicon. Among the main reasons for its compilation were Tatar soldiers' lack of the Russian language proficiency in the first quarter of the 20th century, discrepancies in translations of military regulations and documents into Tatar, problems with publication of numerous military newspapers during this period, and other factors. The positive and significant effect of the dictionary was due to the fact that it recorded examples of the experience in creating terminology based on our native language, the issue that has been relevant to this day [4].

R. Muginov's "Ruscha-tatarcha khәrbi terminnar sүzlege" ("Russian-Tatar Military Terminology Dictionary"), published in 2000, is one of the most significant works systematizing Tatar military vocabulary. Containing approximately 8,000 lexical units, the dictionary not only offers Tatar equivalents for Russian terms, but also provides the meanings of many words as is done in an explanatory dictionary [5].

According to the data from E. Sevortyan's "Tәrki tellәrneң ehtimologik sүzlege" ("Etymological Dictionary of Turkic Languages") [6, pp. 290–291], "war" is *sokush* – Uighur dial., *sogush* – Alt. dial., *sogys* – Kaz., *sugysh* – Tat., *khugysh* – Bash.; it means: quarrel, combat, beating, teasing each other, butting, fighting (about roosters)), colliding with each other (while running).

Words, formed with the suffix *-mak,* are less common compared to those formed with the suffixes -(u/ış): *sokush* (Turkic dial.) – meaning battle, war, struggle; *sokash* (Uyghur dial.) – meaning battle, war, struggle; *sogush* (Kyrg., Alt. dial.) – meaning battle, war, struggle, torment, torture.

In the Tatar-Russian and Russian-Tatar dictionaries of the 19th century, the words *sugysh (war)* and *yau (battle)* are used in parallel to mean "hostilities". F. Khisamova identifies the lexeme *sugysh* as characteristic only of the old Tatar language [7, p. 30]. In this meaning it is not found in Turkic-language written records, while the word *sönüs* is recorded in the ancient Turkic dictionary. In written records, such as the "Urta Aziya tәfsire" and "Oguz-name", the word *urush* is used to mean "war". This fact is documented in the written records of the Golden Horde and Khwarezm [7, p. 33].

Among modern Turkic languages, the lexeme *sugysh* in this specific phonetic form is used only in the Tatar language. In slightly different phonetic forms, it appears in in Uyghur – *sokush,* Kazakh – *sogys,* and Bashkir – *hugysh.*

R. Safarov's work "Military Vocabulary of the Tatar Language" (2015) studies Tatar military vocabulary in both synchronic and diachronic aspects. The scholar identifies historical-genetic layers and analyzes characteristic features of military

vocabulary in the modern Tatar language [8]. Furthermore, in 2017, R. Safarov compiled the "Tatarcha-ruscha khərbi leksika sүzlege" ("Tatar-Russian Dictionary of Military Vocabulary"). The dictionary primarily includes the terms for types of weapons and military equipment, their components, parts, and protective gear; units denoting elements of protective clothing and their parts; names of various military formations and personnel; designations for military leaders; units representing specific battlefield episodes and military symbols; vocabulary related to the description of prisoners of war, and other such terms pertaining to the military sphere. To clarify meanings more comprehensively and accurately, illustrative materials are provided for each word, highlighting their usage features [9].

"Milliyat sүzlege" ("**Dictionary of the Nation**") is a dictionary providing the following meanings for the word "*sugysh" ("war"):* quarrel, beating, struggle, confrontation, massacre. In the ancient Turkic language, we find the words *sөңgesh* and *chənchesh*. In Tatar literature, words borrowed from Arabic, such as *khərb* and *gazva* are used to convey the meaning of "war" [10, p. 395].

Lexical units reveal their initial essence in the Tatar and related languages through a feature embedded in the stem of nomination: *sugysh* – an armed conflict, war, dispute, clash, battle, struggle, fight. As we can see, associations of hostility and militarism predominate in this concept, at the same time, there is also the meaning of joint, peaceful activity – in E. Sevortyan's "Tөrki tellərneң ehtimologik sүzlegendə" ("Etymological Dictionary of Turkic Languages" (EDTL)), this shade of meaning is described as involving discussion or assistance in resolving disputes [8, p. 291].

The most important stage in describing the concept of "Sugysh" is defining its core element. In this case, an explanatory dictionary is helpful. The "Tatar teleneң aңlatmaly sүzlege" ("Explanatory Dictionary of the Tatar Language") provides the following meanings for *sugysh*: 1. The same as "sugyshu" (meanings 2–4). "*At the gatherings, of course, you sing, play 'back-hitting', play 'ring-on-a-stick'*". (A. Shamov). 2. The act of hitting each other, a clash, a fight. "*As for our grandfather, there was no such thing as mutual fighting, associating, or insulting-degrading each other in front of him!*" (M. Gali). "*Two roosters, fighting with their combs dipped in blood, both flew away in fear from under his feet in different directions*" (G. Apsalamov). 3. Armed conflict between states, armies, etc. Patriotic War. Weapon of war. Civil War. // A specific type of this conflict is the "bayonet fight" (combat in the front lines). "*I fought on the front lines*" (B. Rakhmat) [11, p. 369]. As we can see, the dictionary lists six meanings for the lexeme "*sugysh*". In its modern interpretation it continues to maintain its connotations of hostility and militarism and remains a unit constituting the concept sphere of "social concepts and relations".

"Sinonimnar sүzlege" ("The Dictionary of Synonyms") by Sh. Khanbikova and F. Safiullina lists the following synonyms for this concept: *orysh, yau, dau, bərelesh, үteresh, kan koesh, kөrəsh, kyinash (brawl, raid, dispute, clash, massacre, bloodshed, struggle, altercation)* [12, p. 168].

The concept of "Sugysh" ("War"), the lexeme *kөrəsh (struggle)* in the "Tatar teleneң aңlatmaly sүzlege" ("Explanatory Dictionary of the Tatar Language") has the following definitions: 1. The attempt of two people to overpower each other using force, a hand-to-hand fight, an effort to defeat one another. *"Nokta Vəlineң khəldən tayuy da minekennən kim bulmagandyr. Chөnki kөrəshneң aktygyna taba ul mine bernərsə də ehshlətə almyi bashlady"("Probably, Vali's exhaustion was no less than mine. Because towards the end of the struggle, he could no longer make me do anything*") (Sh. Kamal). // A sports contest conducted according to specific rules, a test of strength between two people. Tatar wrestling. *"Chyprəklər, yaulyklar җyelyp təmam bulgach...bolynlykka tөshtelər. Kөrəshlər, uzyshlar bashlandy" ("When the headscarves and towels had been collected... they went down to the meadow. As wrestling matches and races began")* (G. Tukay). // Competition, rivalry. *"Җiңel atletika buencha yaryshlarny karauchylar ... dөn'yanyң bieklekkə sikerүche iң yakhshy sportchylary arasynda bargan kisken kөrəshne onyta almaslar" ("Spectators of the track and field competitions... will never forget the fierce struggle that took place among the world's best high jumpers")* (Socialistic Tatarstan). 2. Active efforts, confrontation, and conflict of opposing social groups, movements, etc., aiming to gain control or victory. *"(Əsərdə) vakyiga bailar belən yarlylar arasyndagy kөrəshkə nigezləngən" ("(In the work) the plot is based on the struggle between the rich and the poor")* (M. Gali). // The clash between individual representatives belonging to these groups or movements. *"Fəkhri belən Vəli Khasanov arasyndagy kөrəshne min ike kesheneң yzgyshuy gyna dip karadym" ("I*

*regarded the struggle between Fakhri and Vali Khasanov as merely a squabble between two individuals")* (G. Ibragimov). 3. Any activity conducted to achieve a certain goal, an active effort directed towards that end. *Shəkhsi borchular artka chigende, ikmək əchen kərəsh, frontny təehmin itү əchen kərəsh hərkaida berenche urynga kilep basty (Personal worries receded into the background, the struggle for bread, the struggle to supply the front came to the forefront everywhere)* (G. Bashirov). 4. War, battle, combat. *Kərəsh əle shaktyi kyzu bargan chakta, Yrge Kigəvenle yagynnan CHON otryady kilep chykty. While the fighting was still quite intense, a CHON (Special Purpose Detachment) unit appeared from Verkhney Kigenle* (Sh. Kamal). 5. Special. The clash of opposites in the process of development (in nature, in society). *Tabigat'neң irken kүkrəgendə Məңge kərəsh, məңge khərəkət. In the boundless bosom of nature, there is eternal struggle and perpetual movement.* 6. Fig. The clash of opposing feelings, aspirations, etc. *"Khikəyadə keshelektə bulgan 'yavyz' həm 'yakhshy' kholyk kərəshe, passiv kүzətүche karashynnan kilep, berberenə karshy kuelgan bulsa, ike syinyf arasyndagy kərəsh surətlənderelgən". ("In the story, the internal fight within a person between his 'evil' and 'good' qualities, as perceived from an observer's passive perspective, when these sides are contrasted, is depicted as a struggle between two classes")* (G. Nigmaty) [11, p. 341].

In linguistics, the mechanism of meaning formation is associated with the concept of the valency of a linguistic sign, that is, the ability of an individual sign to relate to other signs. Two types of valency are considered: systematic, or constructively-technical valency, which involves adherence to a pattern (grammar), and spontaneous or interpretative-meaning valency, which can be attributed both to language as a whole and to any element of the language system, speech forms, or texts.

It was revealed that the concept of "Sugysh" ("War") in the Tatar language, in terms of its meaning within the worldview, was found to be interconnected with other closely related concepts. These connections are evidenced by lexical units recorded in lexicographic sources: *sugysh, kərəsh, bərelesh, orysh, kyinash, үlem ueny, yau, dau, kul sugyshy, bəige, yarysh, arka sugysh, sugysh kyry, sugysh allasy, front, gaskər, ilbasar, atysh, sugysh ueny, fikerlər kapma karshylygy, kyrylysh, alysh, ehchke kərəsh* (*war, struggle, collision, clash, quarrel, game of death, raid, dispute, hand-to-hand combat, contest, competition, home front, battlefield, god of war, front, army, invader, shootout, war game, clash of ideas, fray, battle, internal conflict).*

The examples provided are related to the meaning of "Sugysh" ("War"). They show the confrontation of parties and constitute the associative field of the concept under investigation. Through these fields, numerous conceptual representations are actualized in the speaker's mind. The associative connections between words are not accidental; they align with the processes of human cognition.

The segregation of valency models and verbs helps to reveal that in the Tatar language there is a rather large group of verbs conveying the idea of developing confrontation: *(sugysh) bashlau, (sugysh) achu, (sugysh uty) kabyzu, karshy toru, sugysh khalətendə bulu; sugysh khərəkətlərе alyp baru, bəreleshү, pychakka-pychak kilү, (sugysh) ig"lan itү, sugyshu, kərəshү, kəch synashu, atakalau, basyp kerү, yaulap alu, kyryp tashlau, utka totu, tar-mar itү, (utka) tashlanu, korallanu, (sugyshka) kerү, (sugyshta) halək bulu, sugyshyp alu, həжҗүm itү, (sugyshta) katnashu, (sugyshtan) chygu, kaitu, (sugyshka) əndəү, (sugyshka) omtylu, (sugysh) teləү, (sugyshny) propagandalau, (sugyshka) yrgylu, atakalau, shturmlau, (sugyshny) otu, (sugyshta) җiңү, khəbərsez yugalu (sugyshta), (sugysh) kichү, (sugysh) kyrү, (sugyshta) yatyp kalu, үlep kalu h.b. (to start (a war), to declare (a war), to ignite (the fire of war), to resist, to be in a state of war; to conduct military operations, to fight, to come to blows, to declare (war), to wage war, to struggle, to test one's strength, to attack, to invade, to conquer, to massacre, to subject to fire, to destroy, to throw oneself (into the fire), to arm oneself, to enter (a war), to perish (in war), to win through fighting, to assault, to participate (in a war), to exit (a war), to return, to urge (to war), to aspire (to war), to desire (war), to propagandize (war), to plunge (into battle), to attack, to storm, to win (a war), to be victorious (in war), to go missing (in action), to endure (a war), to experience (a war), to be left lying (on the battlefield), to die, etc).*

The attributes of war are divided into two large groups: 1. The attributes that characterize war negatively: *sanguinary, unjust, bloody, terrible, merciless, ruthless, with losses, fierce (war), cold, imperialist.* 2. The attributes that characterize war positively: *glorious, great, holy, just*.

Based on the examples, the following types of war can be distinguished: *class struggle, cold war, holy, colonial, and local wars.*

Word combinations formed according to the first type of izafet: *bətendən'ya sugyshy,*

*grazhdannar sugyshy, atom-təsh sugyshy , yaulap alu sugyshy, azat itү sugyshy, basyp alu sugyshy, yaulap alu sugyshy, vatan sugyshy, banditlar sugyshy, dəreslek sugyshy, diңgez sugyshy, su asty sugyshy, hava sugyshy, shtyk sugyshy, razvedka sugyshy, hөҗүm sugyshy, partizannar sugyshy, iodryk sugyshy, bəisezlek sugyshy, atom-təsh sugyshy h.b.* (*world war, civil war, nuclear war, war of conquest, war of liberation, war of aggression, Patriotic War, gang war, war for truth, naval war, underwater warfare, air war, bayonet fighting, war of intelligence agencies, offensive war, guerrilla war, fist fight, war of independence, atomic war, etc.)*

In the "Concise Russian-Tatar Dictionary of Military Terms" additional meanings of the word "sugysh" are provided: "*uz' ara sugöshö, partizan sugöshö, mina sugöshö, qop sugöshö, tau sugöshöa, köche sugösh" ("close-range war, partisan war, mine war, top war, mountain war, retreat war*") [4, p. 63].

The "Ruscha-tatarcha khərbi terminnar sүzlege" ("Dictionary of Russian-Tatar Military Terms") lists the following types of war: *civil war –grazhdannar sugyshy, invasive war – basyp alu sugyshy, maneuver war – manevrly sugysh, guerrilla war – partizannar sugyshy, cold war – salkyn sugysh, atomic war – atom-təsh sugyshy* [5, p. 47].

In the "Tatarcha-ruscha khərbi leksika sүzlege" ("Tatar-Russian Dictionary of Military Lexicon", R. Safarov provides the following vocabulary entry for the lexeme "sugysh" (war): 1. War. *Moreover, for several years now a war has been going on in the western part of the country against the Poles and Lithuanians, the Swedes have risen against the Russians, the Crimean Khan came and burned down the whole of Moscow, leaving only the Kremlin standing* (F. Bayramova); 2. Battle, engagement; combat; **hand-to-hand fight (kul sugyshy)**. *But when warrior after warrior began to fall, it came to hand-to-hand combat, and swords and daggers were used* (F. Bayramova); **warhorse (sugysh aty)**; **battleaxe (sugysh baltasy)**; *During excavations of Bulgar cities and villages, all kinds of weapons and military attire were found, such as swords, battle axes, scabbards, arrow and spear tips, iron three-pronged spikes scattered underfoot against charging enemy cavalry, spurs, knee pads, elbow pads* (R. Fakhretdinov); **battlefield (sugysh kyry).** *The people of Kazan never knew how to fight from generation to generation; they preferred to engage in trade, and quarreling on the battlefield was an alien concept to them, and even now, it seems, little has change.* (M. Khabibullin). *Moreover, almost all of the Votyak-Vogulsfled from the battlefield; they are no longer to be found around Iskar...* (F. Bayramova); **battlefield (sugysh məidany, sugysh kyry)**. *The Votyak-Ostyaks were the first to break under this rain of fire; they gradually retreated among the trees and then abandoned the battlefield entirely* (F. Bayramova); **internecine war, internal war (үzara sugysh, ehchke sugysh)**. *I fear that internecine wars and a solitary life in the forests and steppes might plunge our people back into a savage state* (F. Bayramova); **civil war; internecine strife (ehchke sugysh)**. *Due to the civil wars, much here was ruined, the order of governance was disrupted, and moreover, it turned out that the people had become considerably distanced from religion and knowledge* (F. Bayramova) [9, p. 86].

Military experience is reflected in the thematic terminology. However, over time, military terminology also changes: some words lose their relevance, and new terms emerge. Significant transformations, that occurred in the armed forces after the Great Patriotic War, introduced new words, concepts, and terms into the language. The perceptions, associated with war in the mind of a linguistic personality, also undergo changes. The recent military events in Ukraine have introduced entirely new words and terms into our language, such as "special military operation", "unmanned aerial vehicle", "red line". A new profession has appeared — UAV operator. The word "mobilization", which began to fade, has been reactivated. These events have exerted a certain influence on our linguistic consciousness and have given rise to a completely new interpretation of the concept under study. If we previously divided the features of the "battlefield" into groups characterizing it positively and negatively, no features characterizing the Special Military Operation in a positive or negative light have been found. Therefore, it itself creates a third – neutral group.

As mentioned above, to reveal the concept to the full, it is necessary to use not only the vocabulary as the material under study, but also a thorough analysis of the phrases. According to L. Cherneyko, "spontaneous, unprepared speech is especially valuable, precisely because it reflects the attitude towards the world, its correct assessment. Furthermore, it makes it possible to highlight culturally significant units, for which vocabulary serves as a background that sets off the figure" [13, p. 7].

The concept of "war" is also revealed through singular nouns – for example, *the German War*:

"Today, several thousand Japanese prisoners were marched past our garrison. I was amazed at how resilient they were. According to our soldiers, they had been living off their own food for 15 days now and said they had enough for another 15 days. They carried this entire load on their backs. In addition, they had a blanket on their backs, some even had mats woven from reeds, various bags, an overcoat, canteens, aluminum mugs, mess tins, etc. A weak donkey would hardly be able to lift such a load. As a rule, the Japanese stop for a rest after 8 km, while with us it is after 4 km. Most of the Japanese were sullen, joyless, unshaven people, they walked heavily, leaning on sticks" [14].

A. Malikov's diary is a documentary eyewitness account. Not everything he recorded was included in his autobiographical works. This is noted in the article by A. Yu. Khabutdinov and M. M. Khabutdinova: "It is obvious that the writer 'aligned' his works with the established canon of depicting the victorious army, avoiding instances of unregulated behavior by soldiers and commanders, etc. It should also be remembered that in the USSR, the topic of the war with Japan was relegated to the background, compared to the war with Nazi Germany. One of the limiting factors was the unresolved post-war situation, as the peace treaty, establishing the borderline, has not been signed to this day" [16, p. 208].

In newspaper and journal articles, contributed to the "From a Writer's Notebook" series, A. Malikov describes his trips to anniversary events

[11] *Tabi* are traditional Japanese ankle-length socks with a separate big toe.

[12] *Karafuto* is the Japanese name for Sakhalin Island.

and meetings with legendary fellow soldiers (see, for example, "Куриль чәчәкләре" ("Kuril Flowers") [11], "Хәтер атаулары" ("Islands of My Memory") [12]). This tradition is now kept up by the writer's son.

The images of Japanese prisoners of war appear not only in the works of A. Malikov, but also in A. Gilyazov's memoir-novel "Iəgez, ber doga!" ("Let Us Pray!") (1991–1993). This theme is explored in detail in M. Khabutdinova's article [21]. The Tatar writer does not hide his admiration with the Japanese whom he had the opportunity to meet in the Karaganda Correctional Labor Camp (KARLAG):

"Among the foreign prisoners, the Japanese were the first to master Russian. While the Chinese learned a dozen words in ten years, I never met a single Japanese who couldn't speak Russian. A proud, rebellious, and strong people! They say the Chinese, Koreans, and Japanese all look alike. Absolutely not. If representatives of these three nations were lined up in front of me, I would be able to spot the Japanese without a doubt! The eyes of the Japanese radiate grandeur, education, self-confidence, mystery, and cunning in the best sense of the word. The Japanese never took part in ethnic squabbles, never quarreled over trivialities, and never fought over food. They truly are a strong, great people!" (Translated by N. Ishmukhametov) [10, p. 278].

With no less respect, the author of the novel describes the Japanese work culture, although the opposition between 'our own' and 'theirs' turns out to be in favour of 'theirs':

"A few words should be said about the way they worked. If a Japanese man takes on a task, you can be sure he'll see it through. In the camp, as usual, there're a 'daylight working hours': you work from dark until dark, or rather, you're forced to work that way. But the Japanese don't obey this stupid rule. After working four hours, he stops, rests, regains his strength, and an hour later rolls up his sleeves again for another four hours, working conscientiously. You can hang him, you can cut him to pieces, but you won't be able to make him work longer than eight hours. And ours hang around all day, pretending to do work, but in fact there's very little work done" (translated by N. Ishmukhametov) [10, p. 278].

A. Gilyazov noted the Japanese's cleanliness:

"The Japanese are neat, tidy, and clean people. In Aktas[13], they settled next to the bathhouse. They heated it and washed their clothes. I sometimes bragged... (That's me all over, I'm guilty of that!) I said: 'A Japanese major general used to wash my clothes!' Although these words are absolutely true, there was no need to brag about it, was it?" (Translated by N. Ishmukhametov) [10, p. 279].

In the novel, A. Gilyazov cites facts that testify to the Japanese's desire to create a cozy environment:

"It turned out that Japanese prisoners of war had lived in Maikuduk[14] for a long time. And supposedly, no sooner had they arrived at the new place than they began to improve it, decorate it, and comb it. The Japanese planted a large number of trees, and between them they created flower beds, in which they sowed night-blooming violets – matthiolas. Dormant during the day, their petals-eyelashes closing, the flowers awaken with the onset of dusk and spread their fragrance far and wide across the surrounding area" (quoted from [21]).

Describing a fight between the Japanese and criminals in the novel, A. Gilyazov shares his observation that the Japanese's docility has its limits; in critical situations, they behave with great courage and heroism. The Japanese are immortalized in the novel as the pioneers building Aktas. The Tatar writer admired the steadfastness with which the prisoners of war endured the hardships of the labor camp:

"It's impossible to imagine, for example, a Japanese officer eating a sandwich made from crushed fish bones! You'll never see anything like that! The Japanese are the proudest, most unyielding people who never lose their human nature even in the most difficult trials. Oh, they never complain, they don't moan if they're hungry, they don't look for scraps, they pull themselves together, they wait for better times, they believe in goodness and in their God" [10, p. 278].

The author's dialogue with Colonel Sattaro Toguchi, who spoke Russian fluently and with almost no accent, is revealing:

One day I asked him: "Sattaro-san, will the Russians and Japanese ever live in peace?" He looked at me with his coal-like eyes and after a short thought he said: "Never!" I was even scared, I swear to God!" [10, pp. 279].

It is known that there were approximately 22,000 Japanese prisoners of war in the Spassky[15]

[13] *Aktas* is an urban-type settlement in the Karaganda region of Kazakhstan.

[14] *Maikuduk* is a suburb of a residential area of Karaganda.

[15] The Spassk prisoner-of-war camp in Karaganda was established on June 24, 1941, on the premises of a sec-

camp. They were used as labor force in mines, brick factories, repair and mechanical plants, and construction companies. They left the camp by the mid-1950s. In 1987, the Japanese government negotiated the removal of the remains of the Japanese prisoners of war buried in Karlag (for details see: [19]).

D. Gallyamova's book cites eyewitness accounts of the Japanese prisoners of war held in NKVD Camp No. 97 in Yelabuga.

"According to Japanese sources, there were 50,000 Japanese prisoners of war in the USSR from December 1945 to 1956, and 9,000 medical officers in Yelabuga" (quoted from: [13, p. 155]). According to eyewitnesses, "among them were colonels, lieutenant colonels, captains, and lower ranks; the bulk of the contingent consisted of young officers".

> "The Japanese, like the Germans, were completely self-sufficient. They worked inside the camp: in the kitchen, the dining hall, the bath and laundry facilities, and also chopped wood, grew vegetables, and fattened pigs. Surgeons, therapists, ophthalmologists, and dentists, under the supervision of Soviet doctors, treated their compatriots", recalled L. Shevnina [14, p. 155].

According to N. Kuznetsova's memoirs, there were many sick prisoners of war from the Kwantung Army, and they were placed in the second zone [14, p. 156].

In 1948, some of the prisoners of war were released to their homeland.

Following the signing of the Agreement between the USSR and Japan "On Persons Held in Prisoner of War Camps" on April 18, 1991, an exchange of information on the burial sites of deceased Japanese began. Small delegations of Japanese began visiting our country, particularly Yelabuga. The city conducted grave openings, collection of remains and things preserved with the deceased, cremation, and other procedures. In October 2000, the Japanese erected a monument in Yelabuga. In 2002, a Japanese delegation visited Yelabuga, including former prisoners of war who met with their saviors—Dr. T. Nechaeva and paramedic Z. Kamaeva (for details see: [14, pp. 155–189]).

---

tion of the Karlag camp. From 1941 to 1950, approximately 70,000 prisoners passed through it: 30,000 Germans, 22,000 Japanese, 6,000 Romanians, and 1,600 Austrians. More than 7,000 foreign soldiers remained permanently in Karaganda. Five thousand are buried in Spassk.

## Results

Our analysis of Tatar literary works, commemorating the events of the 1945 Soviet-Japanese War, has revealed that A. Malikov can rightfully be considered a pioneer of this theme not only in Tatar but also in Russian literature. Unfortunately, translations of his autobiographical novella "The Island of My Youth" went unnoticed by critics due to political circumstances [23], [24]. On the one hand, in his poem, essays, and autobiographical prose, the Tatar writer develops the image of the Japanese, within the framework of the ideological stance, as treacherous, ruthless enemies. On the other hand, his nonfiction and memoir-like sources reveal the writer's ethnographic interest in Japan and its inhabitants (his descriptions of housing, clothing, cuisine, and everyday life of the Japanese). A. Gilyazov's novel highlights the common destinies of KARLAG prisoners, regardless of nationality. The author depicts the Japanese prisoners of war as proud, independent, hardworking, resilient, and courageous individuals who distinguished themselves going through difficult times. D. Gallyamova's book includes eyewitness accounts of the prisoners' life in the second zone in Yelabuga. The local historian includes a number of interesting photographs from the city administration's correspondence with Japanese officials. This dialogue resulted in the installation of a monument on the burial site of the Japanese prisoners of war and the arrival of the survivors in the city for commemorative events.

## Conclusions

In postwar Tatar literature, the study of the images of Japan in general, and Japanese soldiers and prisoners of war in particular is a promising trend and, in our opinion, requires further development. As our research has shown, this theme is represented in various literary genres: from diaries to poetry, from essays to novels.

**References**


1. Golovin, A. (1958–1960). *Tyl-front* [Rear-Front]. Blagoveshchensk, Amurskoe kn. izd-vo. (In Russian)
2. Burenkova, G. (1958). *Pervaya kniga pisatelya* [The Writer's First Book]. Amurskaya pravda. 3 dek. P. 3. (In Russian)
3. Vasil'ev, L. (1965). *Pobeda na Zapade i na Vostoke* [Victory in the West and in the East]. L. Vasil'ev. Dal'ne vost. komsomolets. 23 marta. P. 3. (In Russian)
4. Voronkov, A. A. (2007). *Front bez tyla: o pisatele A. Golovine* [A Front without a Rear: About

Writer A. Golovin]. Amur: lit.-khudozhestv. al'manakh. No. 6, pp. 79–82. (In Russian)

5. Kireeva, N. V. (2017). *Est' li massovaya literatura v Priamur'e XXI v.* [Is There Mass Literature in the Amur Region in the 21st Century?]. Losevskie chteniya – 2017: materialy X regional'noi nauchno-prakticheskoi konferentsii. Pod red. A. V. Urmanova. Pp. 80–91. Blagoveshchensk, Izdatel'stvo BGPU. (In Russian)

6. Malikov, A. (1945). *Ataudagy khislər* [My Experiences on the Island]. Sovet ədəbiyaty. No. 7, pp. 42–47. (In Tatar)

7. Malikov, A. (1948). *Sakhalin yazmalary* [Sakhalin Notes]. 28 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

8. Malikov, A. (1973). *Yash'lek utravym* [The Island of My Youth]. Sovet ədəbiyaty. No. 11, pp. 73–92. (In Tatar)

9. Malikov, A. (1978). *Yash'lek utravy* [The Island of Youth]. 149 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

10. Gilyazov, A. M. (2013). *Sailanma əsərlər: 6 tomda* [Selected Works: In 6 Volumes]. 1 t. 687 p. Kazan', Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

11. Malikov, Ə. (1970). *Kuril' chəchəklər*e [Kuril Flowers]. Sost. Ə. Malikov. Sovet ədəbiyaty. No. 4, pp. 113–125. (In Tatar)

12. Malikov, A. (1985). *Khəter ataulary (yazuchy kөndəlegennən)* [Islands of My Memory (from the writer's diary)]. Sotsialistik Tatarstan. 21, 23 aprel'. (In Tatar)

13. *Adib Malikov – zapiski soldata ehpokhi* (2021) [Adib Malikov – Notes by a Soldier of the Era]. Sost. Anvar Malikov. Pp 133–156. Kazan', Rukhiyat. URL: https://bf-tatneft.ru/fond/documents/books/Malikov_%D0%A1%D0%B0%D0%B9%D1%82(1).pdf. (In Russian)

14. Malikov, A. M. (1945). *Kөndəlek* [A Diary]. Lichnyi arkhiv pisatelya A. M. Malikova. Tetrad' s karandashnymi i chernil'nymi zapisyami na russkom i tatarskom yazykakh. (In Tatar)

15. Gallyamova, D. G. (2019). *Elabuga... serdtsu blizkoe zvuchanie* [Elabuga... a Sound Close to My Heart]. 267 p. Kazan', Tsentr innovatsionnykh tekhnologii. (In Russian)

16. Khabutdinov, A. Yu., Khabutdinova, M. M. (2025). *Voennye dnevniki tatarskikh pisatelei: put' k chitatelyu skvoz' ramki tsenzury* [Tatar Writers' War Diaries: A Path to the Reader through Censorship]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 2, pp. 204–211. https://doi.org/10.26907/2782-4756-2025-80-2-204-211. (In Russian)

17. Nasyikhova, L. R. (2023). *Zhanrovo-tematicheskie i stilisticheskie osobennosti tatarskoi frontovoi publitsistiki v gody Velikoi Otechestvennoi voiny (na primere dnevnikov i ocherkov): dis. ... kand. filol. nauk* [Genre, Thematic and Stylistic Features of Tatar Frontline Journalism during the Great Patriotic War (based on diaries and essays): Ph.D. Thesis]. Kazan', 157 p. EDN: BBGWHW (In Russian)

18. Gosman, Kh. (1948). *Sakhalin yazmalary* [Sakhalin Records]. Berenche kitap. Kyzyl Tatarstan. 30 noyabrya. (In Tatar)

19. *Toponomika naselennykh punktov Yuzhnogo Sakhalina. Russko yaponskii spravochnik-ukazatel'* (1998) [Toponomics of Settlements on Southern Sakhalin. A Russian-Japanese Handbook]. V. V. Pereslavtsev. Vestnik Sakhalinskogo muzeya. No. 1(5), pp. 359–368. (In Russian)

20. *Ob istorii pereimenovaniya naselennykh punktov Yuzhnogo Sakhalina i Kuril'skikh ostrovov v 1946 - 1947 godakh* (2015) [On the History of the Renaming of the Settlements on Southern Sakhalin and the Kuril Islands in 1946–1947]. I. A. Samarin. Vestnik Sakhalinskogo muzeya. No. 1(22), pp. 196–226. (In Russian)

21. Khabutdinova, M. M. (2018). *Obraz yaponskikh uznikov stalinskikh lagerei v romane A. M. Gilyazova "Davaite pomolimsya!"* [The Image of Japanese Prisoners of Stalin's Camps in A. Gilyazov's Novel "Let's Pray!"]. Kul'turnye, ehkonomicheskie, tekhnologicheskie kontakty i vzaimodeistvie Yaponii i Tatarskogo mira: istoriya i so vremennost': sbornik nauchnykh trudov. Vyp. II. Pp. 248–255. Kazan', Institut istorii im. Sh. Mardzhani AN RT. (In Russian)

22. Ten, T. (2009). *Poslednii svidetel' i poslednii samurai* [The Last Witness and the Last Samurai]. Karavan. 13 marta. (In Russian)

23. Malikov, E. (1976). *Ostrov moei yunosti* [The Island of My Youth]. Povest'-vospominanie. Per. s tatar. M. Skorokhodov. 96 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

24. Malikov, E. (1984). *Ostrov moei yunosti* [The Island of My Youth]. Povest'-vospominanie. 128 p. Moscow, Sov. Rossiya. (In Russian)

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА 1945 ЕЛГЫ СОВЕТ-ЯПОН СУГЫШЫ ҺӘМ ЯПОН ХӘРБИ ӘСИРЛӘРЕ ОБРАЗЫ

**Лариса Рафаэль кызы Усманова,**
ФТУ «Югары икътисад мәктәбе»,
Россия, 109028, Мәскәү ш., Покровский бульвар, 11 йорт,
ousmanoval@gmail.com.

**Рәмзия Марс кызы Болгарова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
Ramziya.Bolgarova@kpfu.ru.

**Кәрим Айдар улы Хәбетдинов,**
ФТУ «Югары икътисад мәктәбе»,
Россия, 109028, Мәскәү ш., Покровский бульвар, 11 йорт,
karim.khabutdinov@mail.ru.

Мәкаләдә татар язучыларының 1945 нче елгы Совет-япон сугышы һәм япон әсирләре белән бәйле вакыйгаларга багышланган әдәби әсәрләре анализлана. Сугыштан соңгы чор татар әдәбиятында япон хәрбиләре (сугыш кырында, әсирлектә) төрлечә сурәтләнә. Әсәрләренең беренчесе 1945 нче ел белән билгеләнгән. Совет-япон сугышында разведчик булган Ә. Маликов үзенең күргәннәрен көндәлекләрендә, поэма, очерк һәм автобиографик повестьларында язып калдырган. Чыганаклардан күренгәнчә, татар язучысы, бер яктан, японнарның образын цензура күрсәтмәләренә туры китереп эшләгән, аларны рәхимсез, мәкерле дошман буларак сурәтләгән, ә икенче яктан, аның Япония һәм японнар белән кызыксынуы ориентализм рухында булган. Тагын бер татар язучысы А.М. Гыйләҗев япон хәрби әсирләре белән Караганда төзәтү-хезмәт лагеренда була (КАРЛАГ). «Йәгез, бер дога!» романында язучы япон хәрби әсирләрен зур хөрмәт белән искә ала, аларның оешканлыгын, хезмәт сөючәнлеген, пөхтәлеген, тәртиплелеген, кыюлыгын, чыдамлыгын, сабырлыгын, телгә сәләтлелеген билгеләп үтә. Д.Г. Галләмова китабында 1945–1948 нче елларда Алабугадагы 97 нче санлы НКВД лагерендәге Квантун армиясе әсирләре турында бай фактологик материал бар.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, 1945 нче елгы Совет-япон сугышы, хәрби әсирләр, японнар образы, Әдип Маликов, Аяз Гыйләҗев, Долорес Галләмова

**Сылтама өчен:** Усманова Л. Р., Болгарова Р. М., Хәбетдинов К. А. Татар әдәбиятында 1945 елгы совет-япон сугышы һәм япон хәрби әсирләре образы // Tatarica. 2025. № 2 (25). 66–83 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-66-83

## Кереш

Озак вакытлар әдәбият белемендә Андрей Головинның «Тыл-фронт» романы [1] 1945 нче елгы Совет-япон сугышы турындагы беренче совет китапларыннан саналган [2; 3; 4]. Автор разведка мәктәбе начальнигы булып хезмәт итә, Квантун армиясенә каршы сугышларда катнашып, аерым разведка операцияләрен җитәкли. Ул әлеге вакыйгаларны үз күзләре белән күргән, шуларда катнашкан, шунлыктан бик күп детальләрне нечкәлекләренә кадәр белә. Әлеге әсәр 1953–1959 нчы елларда языла. Шул вакыт эчендә автор «турыдан-туры күзәтүләрдән дә, күп санлы документлар һәм материалларны өйрәнү юлы белән дә табылган бай фактик материалны яңадан сәнгатьчә эшкәртеп чыга» [1]. Профессор Н. В. Киреева фикеренчә, А. Головинның әлеге романы, соцреалистик хәрби эпопея жанр элементларын 1930 нчы елларда совет әдәбиятында кулланыла башлаган шпион боевигы формулалары белән берләштереп язылган, шунлыктан «совет чорының бестселлеры»на әверелгән [5, б. 80–81].

Татар әдәбиятында 1945 нче елгы Совет-япон сугышы вакыйгаларын беренче булып Ә.М. Маликов чагылдыра. Аның сугыш турындагы тәэсирләре автобиографик повесть, очерк һәм поэмаларында чагылыш тапкан, шулай ук көндәлекләрендә дә сакланып калган.

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Анализ өчен материал буларак Ә.М. Маликовның әдәби әсәрләре («Атаудагы хисләр» поэмасы [6], «Сахалин язмалары» очерклары [7], «Яшьлек утравым» повесте [8; 9]), А.М. Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога!» роман-истәлеге [10]), шулай ук Ә. М. Маликовның көндәлекләре [11; 12; 13; 14], Д.Г. Галләмованың «Япон хәрби әсирләре Алабугада. НКВД лагере №97» (1945) [15] мәкаләсе алынды.

Әлеге тикшеренүнең максаты булып татар язучыларының 1945 нче елгы Совет-япон сугышы вакыйгаларын һәм аннан соңгы совет әсирлеге шартларын чагылдырган әсәрләрендә Япония һәм япон хәрбиләренең образ үзенчәлекләрен мәдәни-тарихи һәм чагыштырма методлар ярдәмендә ачыклау тора.

**Фикер алышу**

1939 нчы елда булачак язучы Әдип Маликов (1921–2009) илнең Ерак Көнчыгыш чикләрен саклау өчен армия хезмәтенә алына. Башта ул Благовещенскида, ә 1940–1946 нчы елларда Сахалинда 79 нчы укчы дивизия составында хезмәт итә. 1945 нче елның 11 нче августында Япониягә каршы игълан ителгән сугышның беренче сәгатьләреннән үк разведчиклар отделениесе командиры сыйфатында Көньяк Сахалинны азат итүдә катнаша. Канкойгыч сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен, сержант Ә. М. Маликов «Батырлык өчен», «Японияне җиңгән өчен» медальләре, 2 нче дәрәҗә «Ватан сугышы» ордены белән бүләкләнә.

Илебез әдәбиятында бу татар әдибен 1945 нче елгы Совет-япон сугышы темасын ачучыларның берсе дип атарга була. Сугыш шартларының кырыс булуына карамастан, Ә. М. Маликов кулыннан каләмен төшерми: шигырьләр, поэмалар яза, дивизия газетасы өчен очерклар әзерли, көндәлекләр алып бара (бу хакта тулырак: [16; 17]).

Тылда, фронтта хезмәт иткәндә, шулай ук 1945 нче елгы Совет-япон сугышы вакытында башыннан кичергәннәрне ул автобиографик поэмасында, повесть, очеркларында (Х. Госман рецензиясе [18]), солдат көндәлекләрендә, публицистик мәкаләләрендә чагылдыра. Ә. М. Маликов әсәрләрендә, бер яктан, *үз-чит* оппозициясе 1941–1945 нче еллардагы әдәби традицияләр юнәлешендә, СССР дошманнарына каршы көрәштә чиктән тыш полярлашкан патриотик пафоста эшләнсә, икенче яктан, аерым материаллар әдипнең ориенталистик текстлар язуга тартылуын күрсәтә.

Японнарның мәкерле дошманнар, самурайлар, «башкисәрләр», «камикадзелар», «басып алучылар» образын эшләгәндә Ә.М. Маликов «сугыш ярсуы» һәм «җанвар» мотивларын үстерә:

> «В Манчжурии, напротив нас, – Квантунская армия, захватившая огромные территории Китая. Это цвет императорских войск, головорезы, воспитанные в духе ненависти к советским людям. Гарнизон Хэйхэ[1] состоит из закаленных в сражениях в Корее и Китае горнострелковой дивизии, кавалерийской бригады, нескольких артиллерийских дивизионов, батальона смертников-камикадзе и своры собак. Неужели придется когда-нибудь столкнуться с ними?» [13, с. 77].

Сахалин музеена культпоход эпизодында японнар шулай ук Сахалин утравының «симез рулетын» йотарга хыялланган «басып алучылар» дип тасвирлана:

> «В 1920 году японцы захватили и Северную часть Сахалина, оккупация длилась пять лет. На Северном Сахалине молодую советскую власть потопили в крови. Оккупация, строившаяся на терроре и грабеже, продлилась пять лет. Уходя, захватчики подожгли тайгу, превратили половину острова в пожарище. Большевиков, партизан и членов их семей повесили за ноги на соснах» [13, с. 84].

Музей экспозицияләрен тасвирлау аша Ә. М. Маликов рус-япон сугышлары тарихын реконструкцияли:

> «1905 нче елгы рус-япон сугышында патша Россиясе җиңелеп, Көньяк Сахалин японнар кулына төшкәч, биредә яшәүче рус, кытай һәм айно халыклары тагы да коточкычрак хәлгә калалар. Японнар аларны авыл-авыллары белән ерак тайга эченә, тау-таш араларына сөрәләр» [7, б. 6].

1920 нче елда Япония, Россиядә Гражданнар сугышы баруыннан файдаланып, Сахалинның төньяк өлешен басып ала һәм аны биш ел дәвамында оккупацияләп тора. 1925 нче елда Япония СССР белән килешү төзи, Төньяк Сахалинны Советлар Союзына кире кайтара. Менә ни өчен Ә. М. Маликов очеркларында

[1] *Хэйхэ* – Кытайдагы шәһәр. Хэйлунцзян провинцясе Айхуэй административ өлкәсенең үзәге булып тора (КНР).

японнар «комсыз килмешәкләр» [7, б. 6] «басып алучылар» [13, б. 85] дип тасвирлана. Совет солдатлары Амурның икенче ярында дошманның хәрби хәзерлеген кызыксынып күзәтәләр:

«За неуклюжесть сурово наказывают, иногда набрасывают петлю на шею и привязывают к хвосту лошади». «Самураи делают упор на физическую силу, учатся виртуозно владеть древними приемами дзюдо» [13, б. 77].

Взвод командиры солдат Маликовны Харамитог биеклекләрен «тапка-бенте» мәктәбен узган башкисәрләр саклый дип кисәтә. Өйрәнү вакытында япон ефрейторларның яшь япон солдатларын резина таяклар белән кыйнауларын белгәч, татар язучысы японнарның җитезлек һәм чыдамлык тәрбияләү методларына шаккаткан:

«Если избиваемый закричит или упадет, его запинают до крови с криками: “Мы из тебя сделаем настоящего самурая, научим тебя быть смелым и чутким, сын собаки”» [13, с. 84–85].

Ә. М. Маликов, әсәрләренә «чит текст»лар (командирларның чыгышлары, совет газеталарыннан цитаталар) кертеп, 1945 нче елгы Совет-япон сугышының максатларын укучыларга җиткерә. Көньяк Сахалин операциясе турындагы материал очеркларда көндәлек рәвешендә бирелә. «Чит территория» турындагы күзаллауны формалаштыру өчен, Ә. Маликов көндәлегендә һәм очеркында япон торак пунктларының (Харамитога, Котон, Кэтон, Камисисука, Найро, Тойохара) исемнәрен санап чыга, шулай ук үзәнлек, сопка һ. б. исемнәрен атый. «Сахалин язмалары»ннан япон офицерлары флигелендәге «карта» эпизоды укучыларга Япониянең территориаль дәгъвалары масштабын күзалларга ярдәм итә:

«Над полкой висел узорчатый ковер. Присмотрелись – оказывается, карта Азии. Территория Советского Союза до Урала и Каспия «украшена» японскими флагами. А на горах Урала изображен памятник императору-микадо» [13, с. 118].

Язучы япон диверсантлары, снайперкүкеләр, пулеметчылар, миналы атлар һ. б. белән очрашулары турыда яза, тәҗрибәсе белән уртаклаша. Разведчик, әлеге һөҗүмдә катнашып, «Батырлык өчен» медале дә алган.

Совет идеологик традициясе кысаларында сугыш вакыйгаларын тасвирлаганда японнар портретында ерткыч, агрессив башлангыч ассызыклана. Мәсәлән, повесть авторы һөҗүм вакытында аңа «ерткычларча тешен ыржайткан» «тәбәнәк буйлы» япон һөҗүм итте, дип яза. [13, б. 84–85] Ә. М. Маликов дошман солдатларының нәфрәт тулы күзләренә игътибар юнәлтә. Мәкерле дошман провокацияләренең берсе түбәндәгечә тасвирлана:

«Ак флаг тотып чыккан япон парламентерларын каршы алырга баручы безнең бер төркем офицер һәм солдатларга минометтан, ут ачтылар, ә япон парламентерлары бу вакытта траншеяларга төшен качтылар» [8, б. 13].

Ә. М. Маликов камикадзе культын җентекләп тасвирлый:

«Место камикадзе, погибшего за императора, – в центре рая. Это вдалбливают в головы японских солдат. Говорят, что их доблесть будут воспевать в песнях. Родственникам и семьям камикадзе дарят подарки. Свою жизнь они продают заранее.

Провожая смертников в армию, родители заранее устраивают им торжественные «похороны». В ожидании приказа камикадзе ведут разгульную жизнь, полиция смотрит сквозь пальцы на их бесчинства… Нарушение клятвы карается смертью, принудительным харакири» [13, б. 122].

Ә. М. Маликов безнең гаскәрләргә камикадзе-очучылар, пулеметчылар һ. б. китергән зыян турында болай дип сөйли:

«Японская военщина, если бы это было возможно, весь народ превратила бы в камикадзе» [13, б.123].

«На одном участке было окружено 90 японцев, но ни один не сдался в плен, в последнюю минуту распарывают животы и умирают. Это, по их убеждению, верность императору. О совершивших харакири смертниках их соотечественники слагают легенды, песни и передают их из уст в уста.» (13 нче август язмаларыннан) [14].

Ә. М. Маликов үзенең әсәрләрендә японнарның басып алган территорияләрендә русларга карата гына түгел, ә башка этнос вәкилләренә карата күрсәткән ерткычлыкларын да тасвирлый. 1945 нче елның 8 нче августында хәрби операция башлануы турындагы хәбәр башта очерклар авторында илһам уята:

«Җитәр! Кырык ел көттек без моны – Көньяк Сахалин 40 ел япон итеге астында ыңгырашты» [7, б. 12].

Бу тойгыны борчулы өмет алмаштыра:

«Сугыш! Мин армиядә алты ел хезмәт итү дәверемдә бу көн турында күп мәртәбәләр уйлый идем. Куркыныч та, шомлы да булып күз алдына килә иде ул» [7, б. 8].

Ә. М. Маликов дошман оборонасы сызыгына игътибар итә:

«Менә дошман жире»… «Күп еллар буе төзелгән ныгытмалар, дотлар һәм җир асты юллары» [7, б. 13].

Көндәлекләр авторы дошман оборонасын өзеп чыга алган совет солдатларының (генерал Батурин, орденлы танкист Демин һ. б.) батырлыгына соклана. Разведчик Ә. М. Маликов Совет Армиясенең техник өстенлеге белән горурлана. Язучы үзләренең фидакарь хезмәте белән Җиңү сәгатен якынайтучы тыл хезмәтчәннәре турында ихтирам белән сөйли. «Сахалин язмаларында» фронт һәм тыл бердәмлеге темасы шулай сурәтләнә (аучы Шакир Муллануров турындагы очеркны карагыз).

Ә. М. Маликов япон солдатлары арасында немец пропагандасының көченә шаһит була, моңа бик гаҗәпләнә. Сорау алулар вакытында япон солдатларының күбесе СССР ның фашистлар Германиясен җиңүе турында белмәве, шуңа күрә руслар чигенеп Япониягә кадәр барып җиткәннәр дип уйлаулары ачыклана. Японнар үзләрен миллион кешелек армия составында русларның 100 меңлек армиясенә каршы сугышабыз, дип белгәннәр.

«На одной высоте захватили пленных. Оказалось, что многие японские солдаты еще не знают, что война с Германией кончилась. Им вдолбили, что немцы притесняют русских. Поэтому, дескать, русским земли не хватает, и они покушаются на их территорию [в оригинале – на нашу землю]. Смешно просто!» (18 нче август язмаларыннан) [13, С. 145].

Чигенү хаосы 19 нчы август көндәлек язмасында тасвирланган:

«Железнодорожная станция «Котон». Из леса выходят заблудившиеся японские кони. Здесь много трофейного риса и галет, брошенного имущества, шелковой одежды и посуды. Сегодня должна состояться массовая сдача в плен» [8, б. 146].

22 нче август көндәлек язмасында Камисисука шәһәрендә, яраланувына карамастан, үз постын калдырмаган һәм озак вакыт оборонада торган япон офицерының батырларча һәлак булуы тасвирлана. Татар язучысы аның турында хөрмәт белән сөйли: «самурай» әсирлеккә бирелүгә яки урманга качып китүгә караганда, сугышта һәлак булуны яхшырак күрә [13, б. 9].

Совет Армиясенең Көньяк Сахалин операциясе вакытында Көньяк Сахалин, сентябрь башында Курил утраулары японнардан азат ителә. Ә. М. Маликов үзенең шигырендә Совет Армиясенең япон сугышында җиңүен шулай мәңгеләштергән:

Без кырык ел көтеп, бу көнне
Каныбызда саклап китердек;
Тын океанда соңгы походны
Бөек Җиңү белән бетердек [7, б. 6].

Көндәлек язмаларында язучының дошманга карата нәфрәте акрынлап кызыксыну белән алышынуы сизелә, күрше халык һәм аның мәдәнияте турында күзаллауларын киңәйтү мөмкинлеге барлыкка килә. Көнчыгыш һәм аның борынгы мәдәнияте белән кызыксыну – ватан әдәбиятының күптәнге традициясе. Язучы көндәлеген эш дәфтәрләре сыйфатында куллана, анда яңа әсәрләренең идеяләре һәм караламалары теркәлә. Ул башка милләтләрнең тормыш образларын хөрмәт белән тасвирлый. Мәсәлән, Ә. М. Маликов японнарның торакларын берничә тапкыр бик җентекләп тасвирлый, соцреализм әдәбияты кысаларында, ярлы япон алачыкларын император һәм аның чолганышының сарайларына каршы куя.

Япон капитаны йортының тасвирламасы игътибарга лаек:

«Без япон капитаны яшәгән йорт эченә керәбез. Аның идәненә дөге саламыннан үрелгән маталар җәелгән. Чөйдә ранец, фуражка һәм башка хәрби киемнәр эленеп тора. Өстәлдә фотокарточкалар, төрле кәгазьләр, зур көзге һәм япон хәрби начальникларының рәсемнәре. Әйберләрнең күбесе: патефон, бритва, портсигар, стена сәгате, фотоаппарат һәм башкалар Американыкы. Күрәсең, бу әйберләр Филиппин кебек атауларда халыктан талап алынганнар» [7, б. 12].

Аннары язучы укучыларны япон солдатларының туклану рационы белән таныштыра:

«Япон солдатларының үз гомерләрендә бер генә тапкыр да ипи күргәннәре юк, аларда тик офицерларга гына бертөрле дә тәме булмаган галетлар бирелә. Япон солдатларына иртән шикәр сибеп бер тарелка дөге боткасы, көндез дөге

боткасы һәм киптергән балык, ә кичен балык консервасы һәм бәрәңге бирәләр икән» [7, б. 12].

Японнар капитуляция билгесе итеп йорт түбәләренә ак һәм кызыл флаглар элгәннәр. Язучы көндәлегендә японнарның тактадан ясалган торакларын, япон хатын-кызларының иркен чалбар һәм агач башмакларын, шулай ук японнарның гореф-гадәтләрен җентекләп тасвирлый:

«Японские женщины ходят все в брюках, детей носят за спиной. На ноги одевают деревянные колодки (башмаки) или таби (тапочки). Многие люди носят резиновые сапоги.

Грузы возят на колясках и велосипедах. Их столько, что пешеход на улице берет любой и, когда доезжает до места, оставляет без надзора» [13, б. 148].

«Японцы – народ небольшого роста, большинство худощавые, изнуренные, но хитрые и нахальные. На каждом шагу стараются русского солдата угостить сигаретой или папиросой, низко кланяются, пожимают руку и т.д. Но в то же время ночами убивают наших красноармейцев по одному» [14].

«Өй җиһазлары бик җиңелчә һәм зур мастерлык белән эшләнгәнәр. Комнатада барысы да ялан аяк йөриләр, чөнки идән өстәл дә, урындык та, койка да булып хезмәт итә.

Тәмәкене бергәләп, идәндә аякларны бөкләп утырып тарталар, ә уртада пепельница куелган. Мин әле кофта яки юбка кигән бер хатын-кызны да күрмәдем. Алар арасында җирән, сары, кара һәм ак чәчлеләре дә юк. Чәчләре барысыныкы да шомырт кебек кара. Балалары барысының да бер төсле, ата-аналары ничек итеп бер-берсеннән аларны аера ала икән? Эшчән халык күбесенчә аякларына таби кия һәм обмотка урый, башларына салам эшләпә яки япон фуражкаларын кия. Ирләр чәч үстермиләр, офицерлар шулай ук. Хатын-кызлар тоташ тегелгән бизәкле күлмәк-ыштаннан йөриләр. Һәр японец чалбар каешына арт яктан сөлге тагып йөри. Юынган чакта, битләрен сабынлап сөлге белән юалар, аннан соң сөлгене ныклап борып битләрен сөрткәч, аны киптерәләр» (1945 елның 29 нчы августындагы язмадан) [17, б. 25].

«Идәннәрен бервакытта да юмыйлар. Тик бернichә ел үткәч, дөге саламыннан үрелгән калын маталарын гына алмаштыралар. Өйләрендә өстәл дә, урындык та бик сирәк очрый. Монда кешеләр һәрвакыт аякларын бөкләп идәнгә утырып ашыйлар, идәндә йоклыйлар, ә аяк киемнәрен тышта салып калдыралар». (1945 елның 29 нчы августындагы язмадан)» [7, б. 25].

Көндәлектә рус эмигранты белән очрашу тасвирлана, ул Ә. М. Маликовка японнар турында кызыклы фактлар сөйли:

«Алар иреннәренә атланмай сөртәләр, ә итне бик сирәк ашыйлар, ди (1945 елның 2 сентябрендәге язмадан) [14].

23 нче август язмасында ул японнарның гади халкының Кызыл Армия солдатларын ничек каршы алуын җентекләп тасвирлый:

«Дети вплотную подходят к нашим повозкам и с большим удовольствием принимают то, что мы им даем. Старики снимают шапки и кланяются до земли. Женщины поначалу спрятались по домам, но затем поняли, что мы не едим людей, да и рогов у нас нет.

Девушки машут руками, а бывшие японские солдаты отдают честь. Но добрые они такие, что порох держи всегда сухим. Все японцы улыбаются, вернее стараются быть веселыми. Конечно, некоторые от всего сердца, а многие из-за страха. Потому что им все время говорят, что русские не жалеют никого, расстреливают каждого попавшего в плен, издеваются. По факту ничего не оказалось» [13, б. 146].

Кореялеләрнең дә русларның килүенә шатлануы татар солдатының игътибарыннан читтә калмаган: өлкән яшьтәге кореяле японнарның «аларны кешегә санамавы» турында сөйли [13, б. 147].

Ә. М. Маликов япон телен белмәвенә һәм аңа җирле халык белән мимика ярдәмендә аралашырга туры килүенә үкенә:

«Они – народ очень общительный. Когда вступаешь в общение с ними, они наших сразу окружают и с любопытством разглядывают, ощупывают наши автоматы. Японцы пустили слух, что ППД вооружаются только коммунисты и комсомольцы. Говорят, что с ППД в одного прицеливаются, а убивают десятерых» [13, б. 147].

Карафуто губернаторлыгы башкаласында совет солдатлары исерек япон хәрбиләренең коралларын ташлауларын күргәннәр:

«Они рады, что освободились от муштры и сохранили свои жизни. Для солдат – это большой праздник, они и нас приглашают выпить» [13, б. 148].

Көндәлегенең 15 нче сентябрь язмасында япон хәрби әсирләре тасвирланган:

«Сегодня мимо нашего гарнизона провели несколько тысяч пленных японцев. Я удивляюсь тому, какие все же они выносливые люди. По рассказам наших бойцов, они уже 15 дней живут за счет своих продуктов и говорят еще на 15 дней хватит. Весь этот груз несут на себе. Кроме того, за спиной одеяло, у некоторых даже маты, сплетенные из камыша, различные сумки, шинель, фляги, алюминиевые кружки, котелки и т.д. Маломощный ишак едва ли поднимет такой груз. По правилу, у японцев привал через 8 км, а у нас через 4 км. Большинство японцев люди угрюмые, невеселые, небритые, шагают тяжело, опираясь на палочки» [14].

Ә. М. Маликовның көндәлеге – документаль дәлил, ул үзе күргәннәрне яза. Автор язганнарның барысы да автобиографик әсәрләренә кермәгән. Моңа үзләренең мәкаләләрендә А. Ю. Хәбетдинов һәм М. М. Хәбетдинова да игътибар итә: «Күрәсең, язучы үз әсәрләрен җиңүче армияне сурәтләүнең раслан- ган кануннарына «яраклаштырган», хәрби хезмәткәрләрнең һәм командирларның уставка туры килми торган эшләрен тасвирламаган. Шуны да онытмаска кирәк: СССРда Япония белән сугыш темасы нацистлар Германиясе белән сугыш темасына караганда икенче планга күчерелгән булган. Тоткарлаучы факторларның берсе сугыштан соңгы вәзгыятьнең җайга салынмавы булды, чөнки чикләрне билгели торган тынычлык килешүенә әлегә кадәр кул куелмаган» [16, б. 208].

«Язучы блокнотыннан» сериясендәге газета-журнал мәкаләләрендә Ә. М. Маликов үзенең юбилей чараларына баруын һәм легендар полкташлары белән очрашуларын тасвирлый (мәсәлән, «Куриль чәчәкләр» [11], «Хәтер утраулары» [12]). Хәзер бу традицияне язучының улы дәвам итә.

Япон хәрби әсирләре образлары Ә. М. Маликов әсәрләрендә генә түгел, шулай ук А. Гыйләҗевнең «Йөгез, бер дога!» романында да очрый (1991–1993). Бу тема М. Хәбетдинова мәкаләсендә җентекләп тикшерелгән [21]. Татар язучысы Караганда төзәтү-хезмәт лагеренда (КАРЛАГ) очраткан японнарга соклануын яшерми:

«Чит ил тоткыннарыннан японнар урысчаны иң тиз эләктереп алдылар. Кытай ун елга нибарысы ун сүз үзләштерсә, японнар арасыннан телне белмәгән кешеләрне очратмадым. Горур, буйсынмас, көчле халык. Кытай, кореялы, япон – төскә-биткә бер чамадарак халык, диләр. Һич алай түгел, менә шушы бер төбәктә яшәп ятучы өч халык вәкилләрен аралаштырып тезеп күрсәтсәләр, япон вәкилләрен һич ялгышусыз аерып алачакмын! Японнар күз карашында олпатлык, гыйлем, үз-үзенә ышану, серлелек һәм яхшы мәгънәсендә хәйлә бөркелеп тора. Японнар берчакта да милли тарткалашларга, вак-төяк ызгышларга катнашмадылар, ипи-тоз өчен дошманлашып йөрмәделәр Булса да була икән нык куллы, бөек халык!» [10, б. 278].

Роман авторы японнарның хезмәт культурасын да хөрмәт белән тасвирлый, шул ук вакытта *уз-чит* оппозициясе үзенекеләр файдасына булмый:

«Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, эш-хезмәткә килгәндә, япон эшка тотына икән, ышан, ул аны наять башкарып чыгачак. Лагерьда, гадәттә, «световой рабочий день», бер караңгыдан икенчесенә кадәр эшләтәләр, мәҗбүр итәләр. Япон исә бу җүләр кагыйдәгә буйсынмый, ул дүрт сәгать эшләгәч туктый, ял итә, хәл җыя, бер сәгатьтән тагын җиңен сызгана, тагын дүрт сәгать дәвамында эшли, ут уйната. Ас син аны, кис, сигез сәгатьтән ары эшләтә алмыйсың. Урыс исә көннәр буе былагайланып, эшләгән булып йөри, башкарган эше эт яламаслык» [10, б. 278].

А. М. Гыйләҗев японнарның чисталыкларын да ассызыклый:

«Японнар – пөхтә халык, чиста халык. Актаста алар мунча тирәсенә урнаштылар: мунча ягалар, кер юалар. Мин кай арада мактанып та куям... (Нишлим, бар инде шундыйрак гадәтләрем!) «Япон генерал-майоры минем керләрне юа иде! » – дип җиффәрәм» [10, б. 279].

Романда А. М. Гыйләҗев японнарның үзләре торган җирдә уңайлыклар булдырырга омтылуларын дәлилләүче фактларны да китерә:

«Оказывается, в Майкудуке[2] долгое время жили японские военнопленные. А они якобы не успеют на новое место прибыть, как тут же начинают облагораживать его, украшать, причёсывать. Японцы высадили большое количество деревьев, а между ними разбили цветочные клумбы, на которых посеяли ночные фиалки – маттиолы. В дневное время дремлющие, сомкнув реснички-лепестки, цветы с наступлением сумерек просыпаются и далеко-далеко по округе распространяют своё благоухание» (Цит. по [21]).

А. М. Гыйләҗев үзенең әсәрендә японнарның җинаятьчеләр белән сугышуын тасвирлый, шунда ул аларның йомшак, юл куючан булуларының да чикләре барлыгын күрсәтеп, критик ситуацияләрдә японнарның

[2] *Майкудук* – Караганда янындагы шәһәр.

үз-үзләрен бик кыю һәм каһарманнарча тотуларын сурәтли. Японнар романда Актасны беренче төзүчеләр буларак тасвирлана. Татар язучысы хәрби әсирләрнең хезмәт лагерендагы авырлыкларга бирешмәвенә соклана:

«Әйтик, япон офицерын төелә-төелә балык сөягеннән әвәләгән бутерброд ашаганын күз алдыңа китереп кара! Һичкайчан була торган хәл түгел! Иң горур, иң буйсынмас, әллә нинди кыен хәлләргә калганда да кешелек сыйфатларын җуймаган, сынмаган, буйсынмаган адәм япон булыр. О-о, алар берчакта да зарланмыйлар, сукранмыйлар, ачыксалар, юкны-барны эзләмиләр, язмышларын учларына йомарлап, җаннарын эт типкесенә ычкындырмыйча, яхшылык көтәләр, яхшылыкка һәм Ходаларына ышаналар» [10, б. 278].

Авторның русча бернинди акцентсыз сөйләшә торган елгыр полковник Саттаро Тогучи белән диалогы да бик кызыклы:

Мин аннан: «Саттаро-сан, берәр заман урыс белән япон тату яши башлармы?» – дип сорадым. Ул миңа кап-кара күзенең нурларын терәп уйланды да: «Никогда!» – дип җавап бирде. Каушадым хәтта, валлаһи!» [10, б. 279].

Билгеле булганча, Спас лагеренда 22 меңгә якын япон хәрби әсире булган. Аларны шахталарда, кирпеч заводларында, ремонт-механика заводларында, төзелеш предприятиеләрендә эшче көч буларак файдаланганнар. Алар лагерьдан 1950 нче еллар уртасында азат ителә. 1987 нче елда Япония хөкүмәте Карлагта күмелгән япон хәрби әсирләренең җәсәдләрен туган илләренә кайтару турында килешү төзи (бу турыда тулырак: [19]).

Д. Г. Галләмова китабында япон хәрби әсирләренең Алабугадагы 97 нче санлы НКВД лагеренда булулары турында шаһитләрнең истәлекләре китерелә.

«Япон чыганаклары буенча, СССР да 1945 нче елның декабреннән 1956 нчы елга кадәр 50 мең япон хәрби әсире, Алабугада – 9 мең медицина хезмәте офицеры булган». ([13, б. 155] буенча цитата). Шаһитлар раславынча, «алар арасында полковниклар, подполковниклар, капитаннар һәм түбәнрәк званиедәге хәрбиләр булган, төп контингентны яшь офицерлар тәшкил иткән» [...].

«Японнар, немецлар кебек үк, тулысынча үз-үзләренә хезмәт күрсәтә иде. Лагерь эчендә: азык-төлек блогында, ашханәдә, мунча-кер юу бүлегендә эшләгәннәр, шулай ук урман кискәннәр, яшелчә үстергәннәр, дуңгыз симерткәннәр. Хирурглар, терапевтлар, окулистлар, стоматологлар совет табиблары күзәтүе астында үз ватандашларын дәвалаганнар», – дип искә ала Л.А. Шевнина [14, б. 155].

Н. А. Кузнецова истәлекләре буенча, Квантун армиясе хәрби әсирләре арасында авырулар күп була, аларны икенче зонага урнаштыралар [14, б. 156].

1948 нче елда әсирләрнең бер өлеше туган илләренә кайтарыла.

1991 нче елның 18 нче апрелендә СССР һәм Япония арасында «Хәрби әсирләр өчен лагерьларда булган затлар турында» килешүгә кул куелганнан соң, вафат булган япон әсирләренең җирләнгән урыннары турында мәгълүмат алмашу башланды. Японнар зур булмаган делегацияләр белән безнең илгә, шулай ук Алабугага да киләләр. Шәһәрдә каберләрне казу, җәсәдләрне һәм каберләрдә сакланып калган әйберләрне җыю, аннары кремация һәм башка процедуралар үткәрелә. 2000 нче елның октябрендә Алабугада японнар тарафыннан япон хәрби әсирләренә һәйкәл куела. 2002 нче елда Алабугага Япония делегациясе килә, алар арасында элеккеге хәрби әсирләр дә була, алар үзләренең коткаручылары – доктор Т. А. Нечаева, фельдшер З. Ш. Камаева белән очрашалар (бу турыда тулырак: [14, б. 155–189]).

**Төп нәтиҗәләр**

1945 нче елгы Совет-япон сугышы вакыйгаларын тасвирлаган татар әдәбияты әсәрләренә ясаган анализ шуны күрсәтә: Ә. М. Маликов бу темага татар әдәбиятында гына түгел, ә ватан әдәбиятында да беренче булып алынган язучы дип саналырга хаклы. Кызганычка каршы, аның «Яшьлегем утравы» автобиографик повестеның тәрҗемәләре сәяси хәлләр аркасында тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә калды [23; 24]. Японнарның образы, бер яктан, поэма, очеркларда һәм автобиографик прозада татар язучысы тарафыннан, идеологик караш кысаларында, мәкерле, рәхимсез дошман буларак күрсәтелсә, икенче яктан, нәфис-документаль прозада һәм мемуар характердагы чыганакларда әдипнең Япониягә һәм анда яшәүчеләргә карата этнографик кызыксынуы күзәтелә (японнарның тораклары, киемнәре, кухнялары, көнкүреше тасвирлана). А. М. Гыйләҗев «Йәгез, бер дога!» романында милләтенә карамастан, Карлаг тоткыннары язмышларының уртаклыгына игътибар бирелә. Автор япон хәрби әсирләрен

горур, бәйсез, хезмәт сөючән итеп сурәтли. Д. Г. Галләмова китабында әсирләрнең Алабуганың икенче зонасында булуы турында шаһитләрнең истәлекләре дә урын алган. Ул туган якны өйрәнүче фоторәсемнәрдә шәһәр администрациясенең Япония рәсми оешмалары белән эшлекле язышуыннан кызыклы фотодокументлар китерә. Диалогның нәтиҗәсе булып, япон хәрби әсирләре күмелгән урында һәйкәл кую, исән калган элекке япон әсирләренең шәһәргә истәлекле чараларга килүе була.

## Йомгак

Татар әдәбиятында Япония образын, япон хәрби әсирләре һәм сугыштан соңгы чор япон әсирләренең образларын өйрәнү перспективалы булып тора һәм алга таба да эзләнүләрне таләп итә. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, бу тема төрле әдәбият жанрларында, көндәлекләрдән шигъри әсәрләргә кадәр, очерклардан романнарга кадәр сурәтләнгән.


## Рәхмәт сүзе

Әтисенең хәрби көндәлеге белән якыннан танышу, эшләү мөмкинлеге тудырганы өчен, күренекле татар язучысы Ә. М. Маликовның улы А. Ә. Маликовка чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.


**Әдәбият**


1. *Головин А.* Тыл-фронт: 2 кн. Благовещенск: Амурское кн. изд-во, 1958-1960.
2. *Буренкова Г.* Первая книга писателя // Амурская правда. 1958. 3 дек. С. 3.
3. *Васильев Л.* Победа на Западе и на Востоке // Дальневосточный комсомолец. 1965. 23 марта. С. 3.
4. *Воронков А. А.* Фронт без тыла: о писателе А. Головине // Амур: лит.-художеств. альманах. 2007. № 6. С. 79–82.
5. *Киреева Н. В.* Есть ли массовая литература в Приамурье XXI в. // Лосевские чтения – 2017: материалы X региональной научно-практической конференции / под ред. А.В. Урманова. Благовещенск: Изд-во БГПУ, 2017. С. 80–91.
6. *Маликов Ә.* Атаудагы хисләр // Совет әдәбияты, 1945. №7. Б. 42–47.
7. *Маликов Ә.* Сахалин язмалары. Казан: Таткосиздат, 1948. 28 б.
8. *Маликов Ә.* Яшьлек утравым // Совет әдәбияты. 1973. №11. Б. 73–92.
9. *Маликов Ә.* Яшьлек утравым. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 149 б.
10. *Гыйләҗев А. М.* Сайланма әсәрләр: 6 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 687 б.
11. Маликов Ә. Куриль чәчәкләре // Совет әдәбияты. 1970. №4. Б. 113–125.
12. *Маликов Ә.* Хәтер атаулары (язучы көндәлегеннән) // Социалистик Татарстан. 1985. 21, 23 апрель.
13. Адиб Маликов – записки солдата эпохи / авт-сост. Анвар Маликов. Казань: Рухият, 2021. С. 133–156. // URL: https://bf-tatneft.ru/fond/documents/books/Malikov_%D0%A1%D0%B0%D0%B9%D1%82(1).pdf
14. *Маликов Ә. М.* Көндәлек. // *Личный архив писателя А.М. Маликова.* Тетрадь с карандашными и чернильными записями на русском и татарском языках. 1945. 30 л.
15. *Галлямова Д. Г.* Елабуга... сердцу близкое звучание. Казань: Центр инновационных технологий, 2019. 267 с.
16. *Хабутдинов А. Ю., Хабутдинова М. М.* Военные дневники татарских писателей: путь к читателю сквозь рамки цензуры // Филология и культура. Philology and Culture. 2025. №2 С. 204-211. https://doi.org/10.26907/2782-4756-2025-80-2-204-211
17. *Насыйхова Л.Р.* Жанрово-тематические и стилистические особенности татарской фронтовой публицистики в годы Великой Отечественной войны (на примере дневников и очерков): дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2023. 157 с. EDN: BBGWHW
18. *Госман Х.* Сахалин язмалары. Беренче китап // Кызыл Татарстан. 1948. 30 ноябрь.
19. Топономика населенных пунктов Южного Сахалина. Русско- японский справочник-указатель / В.В. Переславцев // Вестник Сахалинского музея. 1998. № 1(5). С. 359-368.
20. Об истории переименования населенных пунктов Южного Сахалина и Курильских островов в 1946–1947 годах / И.А. Самарин // Вестник Сахалинского музея. 2015. № 1(22). С. 196–226.
21. *Хабутдинова М.М.* Образ японских узников сталинских лагерей в романе А.М. Гилязова «Давайте помолимся!» // Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и со временность: сборник научных трудов. Вып. II. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018. С. 248–255.
22. *Тен Т.* Последний свидетель и последний самурай // Караван. 2009. 13 марта.
23. *Маликов Э.* Остров моей юности: Повесть-воспоминание / пер. с татар. М. Скороходов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. 96 с.
24. *Маликов Э.* Остров моей юности: Повесть-воспоминание. М.: Сов. Россия, 1984. 128 с.

# ОБРАЗ СОВЕТСКО-ЯПОНСКОЙ ВОЙНЫ 1945 Г. И ЯПОНСКИХ ВОЕННОПЛЕННЫХ В ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

**Лариса Рафаэлевна Усманова,**
НИУ «Высшая школа экономики»,
Россия, 109028, г. Москва, Покровский бульвар, 11,
ousmanoval@gmail.com.

**Рамзия Марсовна Болгарова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
Ramziya.Bolgarova@kpfu.ru.

**Карим Айдарович Хабутдинов**,
НИУ «Высшая школа экономики»,
Россия, 109028, г. Москва, Покровский бульвар, 11,
karim.khabutdinov@mail.ru.

В статье систематизированы художественные произведения татарских писателей, посвященные Советско-японской войне 1945 г. и последующим событиям, связанным с японскими военнопленными. В произведениях татарской литературы послевоенного периода образы японских военных в бою и в плену даются по-разному. Самое раннее из произведений датируется 1945 г. Участник событий А. М. Маликов, будучи разведчиком, увековечил увиденное в дневниках, поэме, очерке, автобиографической повести. Анализ источников показал, что татарский писатель, с одной стороны, разрабатывал образ японцев в соответствии с установками цензуры как безжалостных, коварных врагов, а с другой стороны, его интерес к Японии и японцам развивался в ориенталистском ключе. Другому татарскому писателю А. М. Гилязову довелось столкнуться с японскими военнопленными в Карагандинском исправительно-трудовом лагере (Карлаге). В романе «Давайте помолимся!» писатель вспоминает о японских военнопленных с большим уважением, отмечая их организованность, трудолюбие, аккуратность, дисциплинированность, смелость, выносливость, терпение, способность к языкам. В книге Д. Г. Галлямовой содержится богатый фактологический материал о военнопленных Квантунской армии, которые в 1945–1948 гг. оказались в лагере НКВД № 97 в Елабуге.

**Ключевые слова:** татарская литература, Советско-японская война 1945 г., военнопленные, образ японцев, Адиб Маликов, Аяз Гилязов, Долорес Галлямова

**Для цитирования**: Усманова Л. Р., Болгарова Р. М., Хабутдинов К. А. Образ Советско-японской войны 1945 г. и японских военнопленных в татарской литературе // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 66–83. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-66-83



Adib Malikov's War Diary.
Әдип Маликовның сугыш көндәлеге.
Военный дневник Адиба Маликова.

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-84-95

# VECTORS OF SOVIET HEROISM DURING THE GREAT PATRIOTIC WAR (BASED ON JOURNAL PUBLICAIONS FROM "THE SOVET ƏDƏBIYATY")

**Aydar Yurievich Khabutdinov**,
Kazan branch of Lebedev Russian State University of Justice,
7A, 2nd Azinskaya Str., Kazan, 420088, Russian Federation,
aikhabutdinov@mail.ru.

This article analyzes the formation of the hero image in the pages of the Tatar socio-political and literary-artistic journal "Sovet ədəbiyaty" during the Great Patriotic War. The focus is on publications from 1943 to 1945, the period following the radical turning point in the war in favor of the USSR. The article identifies the nature of changes in the concept of Tatar history in the journal's publications after the adoption of the Resolution of the Central Committee of the All-Union Communist Party (the Bolsheviks) of August 9, 1944, and demonstrates that the editorial board shaped the pantheon of heroes strictly in line with the "Big Brother" concept. A number of publications from this period emphasize the continuity of the traditions of the Motherland joint defense from a common enemy in the history of the Tatar and Russian peoples, emphasizing their cooperation in the field of state and party building, in science and culture.

**Key words**: Tatar people, Great Patriotic War, pantheon of heroes, hero ideologeme, Resolution of the Central Committee of the VKP(b) of August 9, 1944 "On the state and measures to improve mass-political and ideological work in the Tatar Party organization"

**For citation:** Khabutdinov A. Yu. Vectors of Soviet heroism during the Great Patriotic War (based on journal publicaions from "The Sovet ədəbiyaty") // Tatarica. 2025. № 2 (25), pp. 84–95. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-84-95

## Introduction

According to A. Soboleva, the process of developing the image of the hero as a behavior model in our country began during the Civil War. "The hard wartime created a need for extraordinary individuals whose names and exploits were supposed to evoke a feeling of deep respect and a desire to emulate these heroes". Alongside the heroes of the Civil War, a corps of new heroes – the Soviet ones – was being formed, with a special place occupied by the "Stalin's Falcon pilots" in the 1930s (the Chkalovs, Baidukovs, Belyakovs, Gromovs, and Babushkins). "The Bolsheviks sought to demonstrate that anyone could become a hero, regardless of their origin and class affiliation. During the first five-year plans, the promotion of military exploits was combined with the popularization of labor achievements. In the 1930s, newspapers daily broadcast the images of heroes raised in the new Soviet society – the Stakhanovites and Busyginites, the builders of new cities" [1]. Millions of people in the USSR took the GTO (Ready for Labor and Defense) Standards to be able to repel the enemy in case of danger. "In the USSR, anyone could become a hero, anyone who agreed with the political line of the leadership, and, above all, a hero had to be disciplined within the framework of the system", believes N. Cherkunova [2].

The popularization of heroism became a necessary task of propaganda during the Great Patriotic War. This was stated in the report "On the state of military propaganda among the population" from the GLAVPUR (the Main Political Directorate) of the Red Army to the Central Committee of the All-Union Communist Party (Bolsheviks), addressed to A. Zhdanov, the Secretary of the Central Committee of the All-Union Communist Party (Bolsheviks), (January 1941): "Of course, our army and people must be educated in complete confidence in their strength and might, in the spirit of high Soviet patriotism. The historic victories of the Red Army, the facts of heroism and courage must be widely covered in mass media and through oral propaganda; these facts must be used to educate workers and mobilize them for further successes. At the same time, it should not mean 'hurrah-patriotism' and 'easily giving our enemies a licking..." [3].

From the first days of the war, the task of mass media was, according to I. Ehrenburg, to arm people with hatred for the enemy. Mass media played

a huge role in shaping the images of the enemy and the hero. First publications about the military exploits of soldiers from the Tatar ASSR began to appear in print, revealing the origins of the Soviet soldiers' fortitude and valor in the battlefields. War correspondents from Tatar frontline newspapers made a significant contribution to this work. As A. Kabirova notes, they wrote and published approximately 70 essays about the soldiers and officers of the Red Army. Much attention was paid to promoting the exploits of the Heroes of the Soviet Union. Over many years, our republic developed historiography that has studied and summarized the historical experience of the Soviet people in ensuring Victory in the Great Patriotic War (see [4]).

Since the post-war period, books "The Book of Heroes" [5], "Zhiңү yuly" [6], etc., which highlight the personal heroic experiences of our fellow countrymen, have appeared in the Tatar language in the TASSR and the Republic of Tatarstan. In 1984, A. Ainutdinov published his work "The Chronicle of the Feat" [7], a historical essay based on the publications of Tatar frontline newspapers. In 2022, A. Shamova's literary publication "The Press Born in Fire" [8] came out. In 2025, the Tatar Book Publishing House released "Kaharman kaləme" ("The Pen of a Hero"), a collection of works by frontline soldiers [9].

## Research Materials and Methods

The novelty of our study is the exploration of the ways in which the pantheon of heroes was introduced into the public consciousness in the pages of the journal "Sovet ədəbiyaty" (Soviet Literature) during the relentless advance of 1943–1945. In the year of the 80th anniversary of the Soviet people's victory in the Great Patriotic War, it is important to understand which heroes inspired soldiers and home front workers. Our study is based on the publications in the socio-political and literary journal "Sovet ədəbiyaty" (Soviet Literature) in the aforementioned period. We use the methods of the comparative historical, problem-chronological, synchronic and diachronic analysis, periodization, classification, and other methods.

The purpose of our study is to analyze in dynamics the pantheon of historical heroes from the Tatar ASSR during the war years, simultaneously identifying the nature of the adjustments made to it in connection with the publication of the Resolution of the Central Committee of the KVP(b) of August 9, 1944 "On the state and measures for improving mass-political and ideological work in the Tatar Party organization" [10].

## Discussion

From the first days of the war, despite the retreat, small articles about the exploits of soldiers began to spontaneously appear in newspapers. These articles not only shaped the image of heroes in the public consciousness, but also played a compensatory role against the backdrop of the retreat. The images of heroes were simple, allowing everyone to identify with them. A prominent place was occupied by the images of communists and Komsomol members. The shaping of heroic images was also facilitated by the re-emergence of heroic images from the past. The continuity of victories was intended to inspire Soviet citizens and convey the idea of a united people's militia, calling to fight the enemy.

One of the characteristic features of the period from the 1930s to 1940s was the publication of collective letters. Thus, a collective image of the people as defenders of the country emerged (cf. Stalin's address "brothers and sisters"). The collection of works in the Main Archival Administration under the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan contains two versions of the "Letter of the Tatar People to the Tatar Front-Line Soldiers" and responses to the "Letter" on behalf of the Tatar soldiers from the Leningrad, 1st Ukrainian, 1st Baltic, and 2nd Belorussian Fronts [11]. Currently, several versions of this letter are known. On March 5, 1943, the "Letter" titled "The Letter of the Tatar People to the Tatar Front-Line Soldiers" was published in "The Pravda" and "The Izvestiya", and the letter, dated March 6, appeared in the republican newspapers "Kyzyl Tatarstan" and "Krasnaya Tatariya". The "Letter" mentions the names of the heroes in Tatar and Russian history and focuses on the fraternal unity of the Tatar people with the Russians. The pantheon of the heroes in the "Letter" consisted of the glorious sons of the Volga Region in the person of Vladimir Lenin, Maxim Gorky, Yakov Sverdlov, Vyacheslav Molotov, Sergei Kirov, and Ivan Shishkin, as well as Tatar heroes: Khusain Yamashev, Mullanur Vakhitov, Kayum Nasyri, Gabdulla Tukay, Galiaskar Kamal, and Sharif Kamal. The idea of continuity was achieved by mentioning the examples of the Russian and Tatar peoples' joint struggle against external enemies during the Livonian War of 1558–1582 and the First World War of 1914–1918 ("The Brusilov Offensive" in particular). The patriotic oath was taken from the epic poem "Idegey" (compiled by N. Isanbet): "May the sun be a witness (koyash shakhit), the house of Idel (Idel-

Yort)! Until we liberate all the lands of our native land, we will not put down the sword!" [11, p. 32]. Initially, the authors of the letter put forward Shah Ali (1505–1567) as an unambiguously positive hero of Tatar and Russian history. However, in the "Letter", in order to comply with the ideological trends of the era, adjustments were made related to the concept of the Russian people as an "elder brother": By mentioning the khan, the letter would have downplayed the role of the "elder brother", contributing to the growth of "Tatar nationalism", "giving rise to the idea of the Tatar people as an independent force in the Tatar consciousness" [11, pp. 9–10].

The resolution of the Central Committee of the VKP(b) of August 9, 1944, "On the state and measures to improve mass-political and ideological work in the Tatar party organization", which negatively assessed the "popularization of the khan-feudal epic about "Idegey", changed the attitude towards this epic and the historical figure and this idea was reflected in the pages of "Sovet ədəbiyaty".

Although the fragment about the Kazan Khan Shah Ali's participation in the Livonian War disappeared from the final edition, we found traces of this material in Kavi Najmi's article "Tereklek biryche kuch" ("The Power that Gives Living Energy"). The writer cites the work of academic historian V. Velyaminov-Zernov (1830–1904), where the Kazan Khan is named as one of the main commanders at the initial stage of the Livonian War in 1558: He was in charge of the Kasimov and Sviyazhsk Tatars. The Russian historian notes the role of the Tatars in the Battle of Fellin in 1560. Then, Kavi Najmi constructs a chain of succession of Tatar soldiers' participation in the wars of the Russian state, especially against Prussia (Germany). The article mentions a number of wars: The Seven Years' War of 1756–1763, the Patriotic War of 1812, the Crimean War of 1853–1856, the Russo-Japanese War of 1904–1905, and the First World War (K. Najmi calls it "Yarman sugyshy" – "the German War") [12, p. 72].

During the Great Patriotic War (1941–1945), of crucial importance became the creation of a heroic image of the struggle of the Russian people and other USSR peoples for common statehood, including the Soviet period. A pantheon of heroes was constructed accordingly. This was especially true of the period following the victory in the Battle of Stalingrad. The image of the Volga-Idel (Itil) River occupies a unique place in both all-Russian and Tatar traditions. The Tatar epic poem "Idegey" is associated with the struggle for statehood on the Volga River where the Volga is called home, that is, it is associated with the native state: "Oh, Idel-Yort, Idel-Yort" [13, No. 12, p. 42].

The image of the Volga also appears in the front-line writer Adel Kutuy's nəser poem "We Are Stalingraders", which mentions the "chal Idel" ("the gray Volga") and extols the friendship of the USSR peoples: "Bez – ruslar, ukrainlylar, tatarlar, beloruslar" ("We are Russians, Ukrainians, Tatars, and Belarusians"). The text also mentions two Kazakh soldiers. The author glorifies "Lieutenant Colonel Mikhailov" - a worthy successor to heroes from the past: "Kutuzovtai tynych ul. / Chapaevtai kyzu ul" ("He is as calm as Kutuzov, / As hot as Chapayev"). Adel Kutuy considers Marshal (in the text – Colonel General) Konstantin Rokossovsky and Marshal of Artillery Nikolai Voronov to be outstanding modern commanders and heroes of the Battle of Stalingrad [14, pp. 29–30]. This reference to heroes of both the Soviet era and the era of the Russian centralized state and the Russian Empire is characteristic of a number of texts. It concerns both all-Russian figures and ethnic Tatars.

If we revisit the text of the "Congratulatory letter to the Tatar front-line soldiers from the Tatar people", we will find that it mentions the native of Yelabuga and the student of the 1st Kazan Men's Gymnasium Ivan Shishkin whose landscapes are believed to be the personification of Russian nature.

The theme of the Russian culture greatness is also found in Kavi Najmi and Gazi Kashshaf's essay "Dingez batyry" ("The Hero of the Sea") dedicated to Asaf Abdrakhmanov (1918–2000), a Hero of the Soviet Union (1944). He graduated from the Sevastopol Higher Naval School and fought heroically in the Black Sea Fleet (1942). The essay mentions such famous Russian naval commanders as Admirals F. Ushakov and P. Nahimov. The authors glorify P. Nahimov as the "heart of Sevastopol's defense" during the Crimean War (1853–1856). The essay presents the city in a historical context, as the custodian of the best traditions of patriotism in the Russian army. The cultural component plays an important role in the essay. Pushkin and Tukay are mentioned in the work as outstanding poets, while Aivazovsky as a brilliant artist. The friendship between the two peoples is reflected in the chronotope: The authors of the essay praise Pushkin and Aivazovsky for creating unforgettable paintings of Crimea [15, pp. 56–60]. Thus, just like the "Letter", this essay embodies the idea

of Soviet soldiers defending Russia's outstanding cultural achievements.

In the journal, the images of revolutionaries played a key role during the period under review. Their images are immortalized in the articles about the Tatar Bolsheviks Khusain Yamashev (1882–1912) [16] and Kamil Yakub (1894–1919) [17]. While the former's activities spanned the first decade of the 20th century, the latter's are closely linked to the establishment of Soviet power in Kazan and the period of the Civil War. The article about Khusain Yamashev highlights his graduate status at the Kazan Tatar Teacher Training School (1902), which trained Russian-language primary school teachers. Describing his political activities, M. Gainullin draws the readers' attention to Kh. Yamashev's participation in the activities of the Kazan Committee of the RSDLP (b), which began in 1903. Ya. Sverdlov, S. Lozovsky, and I. Sammer are named as the committee leaders during the 1905–1907 Revolution. The literary scholar notes that the name of the Tatar revolutionary as an organizer of party work among the Tatars is mentioned in the newspaper "Proletary", published in Geneva under the leadership of V. Lenin (October 11, 1905). In the article, "The Ural" newspaper, published in Orenburg, is characterized as a Bolshevik newspaper. Among Kh. Yamashev's comrades were G. Tukay, G. Kamal, and G. Kulakhmetov. In his article, M. Gainullin contrasts the Bolshevik newspaper "Nevskaya Zvezda", which published an obituary in honor of Kh. Yamashev, with "The Yoldyz" ("The Star") liberal newspaper, which failed to give a worthy assessment of the revolutionary. G. Tukay's poem "In Memory of Khusain" ("In Blessed Memory") is characterized as a true obituary for the Tatar revolutionary. The concluding section of the article discusses the special role of Kazan in the revolutionary movement in Russia. The article mentions the names of revolutionaries and prominent figures of the Soviet state: V. Lenin, V. Molotov, S. Kirov, and Ya. Sverdlov [16, pp. 62–69].

The hero of the essay "Our Kamil" is Kamil Yakub (1894–1919) who was one of the organizers of the Muslim Commissariat of the Kazan Council in 1918 and, from 1918 to 1919, performed the duties of the head of the Political Department of the Central Muslim Military Collegium. He was killed while addressing mutinous soldiers of the Tatar Reserve Battalion. The text mentions that Kamil Yakub was an official of the Central Muslim Commissariat, created under the People's Commissariat for National Affairs, which was headed by J. Stalin: "Leninnyn boek korəshtashe, Bolsheviklar partysendi milli məsəlane in yakhshy beluche iptash J. Stalin" ("Comrade J. Stalin, Lenin's great comrade-in-arms, the best expert on the national issue in the Bolshevik Party") [17, pp. 47–53].

The essay develops the German theme. S. Fazlullin integrates the character of Mulannur Vakhitov into the struggle against the threat of the German offensive in the spring of 1918. The essay asserts that the German officer Bartolad had a hand in organizing the Trans-Bulak Republic whose activities coincided with the German army's offensive against Petrograd in March 1918. The execution of Mulannur Vakhitov in August 1918 is regarded as revenge by the Tatar bourgeoisie for the disruption of its plans [17, p. 75]. In his essay "Tereklek biryche kəch" ("The Power That Gives Life"), K. Najmi characterizes Khusain Yamashev as a devoted comrade-in-arms of Lenin-Stalin". As a result, G. Tukay, who praised Kh. Yamashev, also became part of this revolutionary paradigm [12, p. 74].

In October 1944, in response to the Resolution on August 9, 1944, the editorial article "For Historical Truth" was published in the October issue of the journal [18, pp. 3–8]. It criticized Naki Isanbet' conception of the Golden Horde set out in "Tatar halyk eposy "Idegiy" dastynyyn 500 ellygy" ("500th Anniversary of the Tatar Folk Epic - Dastan "Idegey"), a scientific preface-article to the consolidated text of the dastan "Idegey" ("Idegey") in the journal "Sovet ədəbiyaty" (see No. 11 [pp. 13, 77 – 92], No. 12 [pp. 83 – 98]). The editorial board declared that the consolidated text of the dastan "Idegey" was not a progressive work, and Idegey himself, who had devastated the lands of Moscow, cannot serve as a positive example in the conditions of the Great Patriotic War in which the Russian people played a key role: "Idegei obrazyn gəyləndergən ehpos progressiv əsər itep tygel, artka səiri torgan zararly əsər itep karaluy bik dəres" ("It would be correct not to consider the epic, where the image of Idegey is immortalized, as a progressive work, it is a harmful work that throws us back") [18, p. 8].

The aforementioned Resolution influenced the assessment of frontline poetry. The literary scholar Gali Khalit, in the article "War and the Poet" dedicated to Sh. Mudarris, pointed out the poet's political error in his poem "The Commander" (1943) [19, p. 58]:

| | |
|---|---|
| Sin laeksyng mengə ylməs babangnarga, | You are worthy of the immortal memory of |

| | |
|---|---|
| Karakashtai gorur ochtyng jilgә karshy.<br>Sin laeksyng izge Idegәi kaharmannarga,<br>Chәnki enkәng, tugan enkәng – tatar khalky | your grandfathers,<br>Like Karakash, you proudly soared against the wind.<br>You are worthy of the glory of holy heroes like Idegey.<br>For your mother, the mother who bore you, is of Tatar descent (literal translation). |

In 1945, the Tatar people celebrated solemnly the 120th birth anniversary of Kayum Nasyri, a scholar and encyclopedist. In his anniversary article (1945, No. 1–2), the literary scholar M. Gainullin draws his readers' attention to the scholar's contacts with the Russian world. The author of the article approves of K. Nasyri's work at the Kazan Theological Seminary and his studies as an auditor at the Imperial Kazan University, and provides an assessment of these milestones in the biography written by the orientalist scholar V. Grigoriev (1816–1881) (No. 1 [20, pp. 70–78], No. 2–3 [21, pp. 87–93]). K. Nasyri's work "Fawakih al-Julasa" is shown in the light of the assessments given by the orientalist and censor Prof. V. Smirnov (1846–1922) who positively assessed the Tatars' departure from Istanbul publications in favor of Russian ones. At the end, the article provides information about the conflict between K. Nasyri and the ethnic German V. Radlov who was appointed the inspector for Tatar, Bashkir and Kyrgyz schools in the Kazan Educational District on October 23, 1871. The theme of the scholar's pro-Russian position is reinforced through the quote: "Bez Russia keshelәre, Rossiyada bulgan nәrsә bezgә jitә'" ("We are Russian citizens, what we have in Russia is enough for us") [21, p. 92].

In his article "Kayum Nasyri in Documents", M. Gainullin positively assesses the Tatar scholar's collaboration with the "Society of Archaeology, History, and Ethnography" at the Imperial Kazan University, while negatively speaking about K. Nasyri's contacts with the leadership of the Orenburg Muslim Spiritual Assembly (Mufti M. Sultanov, Qadi R. Fakhretdinov), Tatar liberal bays (A. Khusainov), and the official and scholar V. Radlov [22, pp. 45–52].

## Results

In analyzing publications in the journal "Sovet әdәbiyaty" (Soviet Literature) from 1943 to 1945, the period that marked the turning point in the Great Patriotic War in favor of the USSR, we found that the authors focused on events spanning four centuries of Tatars' existence within the Russian/Soviet state, as well as their activities for the benefit of that state. This covered the following areas of interaction between the Tatar and Russian peoples: military; party (Bolshevik); Soviet state; cultural and scientific. In the publications of this period, the leading ideas were the ideas of friendship between the Tatar and Russian peoples, the idea of the continuity of the military valor traditions in the fight against a common enemy (the Livonian War of 1558–1582, the Seven Years' War of 1756–1763, the Patriotic War of 1812, the Crimean War of 1853–1856, the Russo-Japanese War of 1904–1905, the First World War, including battles with the Germans in March 1918, and the Great Patriotic War). The following military leaders of the Russian Empire are cited as positive heroes: Kutuzov, Ushakov, Nakhimov, Brusilov (indirectly through "The Brusilov Offensive"), Chapaev, Rokossovsky, and Voronov. When developing biographies of national leaders, the authors of the articles, in line with the "Big Brother" concept, emphasized their connections with Russian revolutionaries. The same trend continued when describing achievements in culture and science. The pantheon of national heroes underwent changes under the influence of the Resolution of the Central Committee of the All-Union Communist Party (Bolsheviks) of August 9, 1944.

## Conclusions

The journal "Sovet әdәbiyaty", while creating a pantheon of heroes during the Great Patriotic War, highlighted typical aspects from the biographies of courageous defenders of the Motherland. The purpose of the publications was to inspire their readers to fight the enemy, to accomplish heroic deeds, and to labor valiantly in the name of Victory. Each stage of the war had its own heroes, depending on the goals and objectives facing society at the time.

**References**

1. Soboleva, A. N. (2017). *Formirovanie obraza geroya i vraga u sovetskoj molodezhi v 1920–1930-e gg.* [The Formation of the Image of Hero and Enemy among Soviet Youth in the 1920s and 1930s]. Politika i obshchestvo. No.10, pp. 78–87. (In Russian)

2. Cherkunova, N. V. (2012). *Formirovanie obraza geroya v 1930-e gg. v SSSR kak sposob voenizatsii soznaniya molodezhi* [The Formation of the Hero's Image in the 1930s in the USSR as a Way of Militarization of Youth Consciousness]. Izvestiya PGPU

im. V. G. Belinskogo. No. 27, pp. 1058–1088. (In Russian)

3. *O sostoyanii voennoi propagandy sredi naseleniya. Dokladnaya zapiska GLAVPURa RKKA v TsK VKP (b)* (1990) [About the State of Military Propaganda among the Population. Memo from the Commander-in-Chief of the Red Army to the Central Committee of the VKP (b)]. Izvestiya TsK KPSS. No. 5, pp. 191–196. (In Russian)

4. *Tatarstan v gody Velikoi Otechestvennoi voiny: Istoriografiya temy* [Tatarstan during the Great Patriotic War: Historiography of the Topic]. URL: https://tatfrontu.ru/content/tatarstan-v-gody-velikoy-otechestvennoy-voyny-istoriografiya-temy?ysclid=mg0b8hl7gf646189094 (accessed: 27.09.2025). (In Russian)

5. *Kniga geroev (sbornik)* (1946) [The Book of Heroes (A Collection of Works)]. Pod obshch. red. Kavi Nadzhmi; sost. Kavi Nadzhmi, Ahmet Erikeev, Bruno Zernit. 173 p. Kazan', Tatgosizdat (tip. Tatpoligrafa). (In Russian)

6. *Zhinu yuly* (1946) [The Way to Victory]. Tuz. R. Ishmuratov, G. Khudziyev. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

7. Ainutdinov, A. K. (1984). *Letopis podviga (Istoricheskii ocherk po stranitsam tatar. frontovikh gazet)*. [The Chronicle of the Feat (A historical essay based on the Tatar frontline newspapers)]. 110 p. Kazan, Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

8. Shamova, A. A. (2022). *Ut echendə tugan matbugat: Bөek Vatan sugyshy chorynda tatar telendə chykkan front gazetalary җyentygy* [The Press Born in Fire: A Collection of Tatar Frontline Newspapers, Published during the Great Patriotic War]. 247 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

9. *Kakharman kaleme* (2025) [The Pen of a Hero]. 223 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

10. *Postanovlenie CK VKP (b) ot 9 avgusta 1944 goda "O sostoyanii i merakh uluchsheniya massovo-politicheskoi i ideologicheskoi raboty v Tatarskoi partiinoi organizatsii"* (1944) [Resolution of the Central Committee of the Communist Party of the Soviet Union (VKP (b)) (August 9, 1944) "On the state and measures to improve mass political and ideological work in the Tatar Party organization"]. "Partiinoe stroitelstvo". No. 15–16, pp. 29– 32. (In Russian)

11. *"Pismo tatarskogo naroda frontovikam-tataram" i otveti na nego* (2012) ["A Letter from the Tatar People to the Tatar Front-Line Soldiers" and the Answers to It]. Gl. arkh. upr. pri Kab. Ministrov Respubliki Tatarstan (sost. I. A. Mustakimov, G. V. Gaffarova). 143 p. Kazan, Gl. arkh. upr. pri Kab. Ministrov Respubliki Tatarstan. (In Russian)

12. Najmi Kavi. (1944). *Tereklek biryche kuch* [The Power That Gives Living Energy]. Sovet edebiyaty. No. 11–12, pp. 71–78. (In Tatar)

13. Isanbet N. (1940). *Tatar halyk eposy «Idegəj» dastanynyң 500 ellygy.* [500th Anniversary of the Tatar Folk Epic Dastan "Idegey"]. Sovet ədəbiyaty. No. 11, pp. 77 – 92; No. 12, pp. 83 – 98. (In Tatar)

14. Gadel Kutui. (1944). *Bez – Stalingradchylar (neser).* [We Are Stalingraders (neser)]. Sovet ədəbiyaty. No. 1, pp. 29–30. (In Tatar)

15. Najmi Kavi, Kashshaf Gazi. (1944). *Dingez batyry* [The Hero of the Sea]]. Sovet ədəbiyaty. No. 4, pp. 56–60. (In Tatar)

16. Gainullin, M. (1944). *Khusain Yamashev* [Khusain Yamashev]. Sovet ədəbiyaty. No. 9, pp. 62–69. (In Tatar)

17. Faizullin, S. (1944). *Bezneng Kamil (uterelyene 25 el tulu ungae belen)* [Our Kamil (on the 25th anniversary of the murder)]. Sovet ədəbiyaty. No. 6, pp. 47–53. (In Tatar)

18. *Tarikhi chynbarlyk uchen (Naki Isanbet ipteshneng "Idegei" eposyna bagyshlangvn mrkalese ungae belen)* (1944) [For Historical Reality (in connection with Comrade Naki Isanbet's article dedicated to the epic "Idigey")]. Sovet ədəbiyaty. No. 10, pp. 3–8. (In Tatar)

19. Khalit, G. (1945). *Sugysh həm shagyjr. (Sheref Mudarris iiaty turynda)* [War and the Poet. (About the works of Sharaf Mudarris)]. Sovet ədəbiyaty. No. 1, pp. 56–65. (In Tatar)

20. Gainullin, M. (1944). *Atakly galim khem yazuchy Kayum Nasyiri* [The Famous Scientist and Writer Kayum Nasyri]. Sovet ədəbiyaty. No. 1, pp. 70–78. (In Tatar)

21. Gainullin, M. (1944). *Kayum Nasyiri* [Kayum Nasyri]. Sovet ədəbiyaty. No. 2–3, pp. 87–93. (In Tatar)

22. Gainullin, M. (1945). *Kayum Nasyiri dokumentlarda* [Kayum Nasyri in Documents]. Sovet ədəbiyaty. No. 2, pp. 45–52. (In Tatar)

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА СОВЕТ ПАТРИОТИЗМЫ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ («СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА)

**Айдар Юрьевич Хәбетдинов,**
В.М. Лебедев исемендәге Россия дәүләт гадел хөкем университетының Казан филиалы,
Россия, 420088, Казан ш., 2 нче Азин ур., 7А йорт,
aikhabutdinov@mail.ru.

Мәкаләдә Бөек Ватан сугышы елларында татар иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис «Совет әдәбияты» журналында герой образын формалаштыру үзенчәлекләре анализланган. Игътибар үзәгендә 1943–1945 еллардагы язмалар, ягъни сугыш СССР файдасына тамырдан борылганнан соңгы чор анализлана. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августы карары кабул ителгәннән соң журнал басмаларында татар тарихы турындагы концепциянең үзгәрешләре күрсәтелгән. Геройларның пантеоны «өлкән абый» концепциясе тирәсендә редколлегия тарафыннан шактый катгый формалаштырылган. Бу чорның кайбер язмаларында Ватанны татар һәм рус халыклары тарихында уртак дошманнан саклау традицияләренең дәвамлылыгы ассызыклана, аларның кайбер вәкилләренең шулай ук дәүләт һәм партия төзелеше, фән һәм мәдәният өлкәләрендә хезмәттәшлегенә игътибар юнәлтелә.

**Төп төшенчәләр:** татар халкы, Бөек Ватан сугышы, геройлар пантеоны, геройның идеологемасы, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августындагы «Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары» карары

**Сылтама өчен:** Хәбетдинов А. Ю. Бөек Ватан сугышы елларында совет патриотизмы юнәлешләре (“Совет әдәбияты” материаллары буенча) // Tatarica. 2025. № 2 (25). 84–95 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-84-95

## Кереш

Безнең илдә үз-үзен тотышы ягыннан эталон булган герой образын формалаштыру процессы Гражданнар сугышы елларында ук башланганлыгын А. Н. Соболева билгеләп үтә. «Авыр сугыш еллары гадәти булмаган шәхесләргә ихтыяҗ тудырды, аларның исемнәре һәм батырлыклары тирән хөрмәт хисе һәм бу геройларга охшарга тырышу теләге уятырга тиеш иде». Гражданнар сугышы геройлары белән беррәттән совет чорының яңа геройлары формалаша, алар арасында 1930 нчы елларда аерым урынны «Сталин бөркетләре – очучылар» (Чкаловлар, Байдуковлар, Беляковлар, Громовлар, Бабушкиннар) алып тора. «Большевиклар, сыйнфый карашларына һәм иҗтимагый килеп чыгышына бәйсез рәвештә, һәркемнең герой була алачагын күрсәтергә омтыла. Беренче бишьеллыкта сугышчан батырлыкларны пропагандалау хезмәт казанышларын популярлаштыру белән тәңгәлләштерелә. 1930 еллар газеталары көн саен яңа совет җәмгыятендә тәрбияләнгән – стахановчылар, бусыгинчылар, яңа шәһәрләр төзүчеләр образларын чагылдырды» [1]. СССРда миллионлаган кеше илгә куркыныч янаган очракта дошманга каршылык күрсәтү өчен ГТО нормаларын тапшыра. «СССРда һәркем герой була ала, җитәкчелекнең сәяси карашлары белән һәркем герой була ала иде, һәм, беренче чиратта, герой җитәкчелек (система) таләп иткәнчә, тәртипле булырга тиеш иде», – дип саный Н. В. Черкунова [2].

Геройлыкны популярлаштыру Бөек Ватан сугышы елларында пропаганда эшенең әһәмияле бурычына әверелә. Бу хакта ВКП(б) Үзәк Комитетының секретаре А.А. Жданов исеменә ГЛАВПУРның (Баш сәяси идарәсе) тарафыннан «Халык арасында хәрби пропаганданың торышы турында» дигән докладында болай диелә: «Әлбәттә, безнең армия һәм халык үз көчләренә һәм куәтләренә тулысынча ышанган хәлдә бөек совет патриотлыгы рухында тәрбияләнергә тиеш. Кызыл Армиянең тарихи җиңүләре, каһарманлык һәм батырлык фактлары матбугатта киң яктыртылырга тиеш. Алар нигезендә эшче көчләрне тәрбияләү, җиңүләргә рухландыру ята. Әмма «урапатриотизмга» һәм «бүрек атуга» юл куймаска кирәк»… [3].

Сугышның беренче көннәреннән үк, язучы И. Эренбург сүзләренә караганда, кешеләрдә дошманга нәфрәт хисе тәрбияләү бурычы куела. Дошман һәм герой образларын

күзаллауда массакүләм мәгълүмат чаралары зур роль уйный. Матбугатта Татарстан АССРдан сугыш кырларына киткән совет солдатларының рухи ныклыгын һәм батырлыгын чагылдырган беренче мәкаләләр чыга башлый. Моңа татар фронт газеталарында эшләүче хәрби корреспондентлар да зур өлеш кертте. А.Ш. Кәбирова билгеләп үткәнчә, алар Кызыл Армия солдатлары һәм офицерлары турында 70ләп очерк язып чыгарганнар. Советлар Союзы Геройлары батырлыкларын пропагандалауга зур игътибар бирелә. Озак еллар дәвамында совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүнең тарихи тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү буенча республика историографиясе барлыкка килә [4].

Сугыштан соңгы чордан башлап, ТАССРда һәм Татарстан Республикасында татар телендә якташларның шәхси батырлык тәҗрибәсен яктырткан китаплар барлыкка килә: «Геройлар китабы» [5], «Җиңү юлы» [6] һ.б. 1984 елда фронттагы татар газеталары битләрендә басылган тарихи очеркларны туплап, А.К. Айнетдиновның «Батырлык елъязмалары» басылып чыга [7]. 2022 елда А.А. Шамованың «Ут эчендә туган матбугат» [8] әдәби-нәфис басмасы дөнья күрә. 2010 елда Татарстан китап нәшрияты фронтовикларның әсәрләрен туплап, «Каһарман каләме» җыентыгын дөньяга чыгара (төзүчеләре – В. Нуриев, Л. Сафиуллина, китап 2025 елда кабат бастырыла) [9].

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Безнең тикшеренүебезнең яңалыгы «Совет әдәбияты» журналы битләрендә 1943–1945 нче еллардагы өзлексез һөҗүм итеп тору шартларында геройлар пантеонын массакүләм аңга кертү ысулларын өйрәнүдән гыйбарәт. Совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңүенең 80 еллыгын билгеләп, үткән елда сугышчыларның һәм тыл хезмәтчәннәренең нинди геройлардан үрнәк алуларын һәм рухлануларын аңлау мөһим. Безнең тикшеренү материаллары булып, югарыда күрсәтелгән чорда «Совет әдәбияты» иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналында басылган язмалар тора. Мәкалә чагыштырма-тарихи, проблемалы-хронологик ысуллар, синхрон һәм диахрон анализ, чорларга бүлү, классификацияләү һ.б. алымнарны куллануга нигезләнгән.

Тикшеренүебезнең максаты – сугыш елларында Татарстан АССРның тарихи геройлары пантеоны үзгәрешен анализларга, шул ук вакытта 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары» карары яктылыгында кайбер коррективаларны ачыклау [10].

## Фикер алышу

Сугышның беренче көннәреннән үк, чигенүгә карамастан, газета битләрендә тиз арада сугышчыларның батырлыклары турында кечкенә хәбәрләр барлыкка килә башлый. Алар халык аңында герой образын формалаштырып кына калмый, чигенү фонында тынычландыру ролен дә уйный. Һәркем үзен шуларга тиңләштерә алсын өчен геройларның образларын гади итеп күрсәтәләр. Әйдәп баручы урын коммунистлар һәм комсомоллар образларын ачуга йөкләтелгән. Геройлар образларын формалаштыруга элекке батырларның образлары белән чагыштыру ярдәм иткән. Җиңүләрнең тәңгәллеген күрсәтү өчен совет халкын рухландырырга, дошман белән көрәштә бердәм көч булып күтәрелү идеясен калкытып куярга кирәк булган.

1930-1940 еллар чорының характерлы үзенчәлекләреннән берсе булып, күмәк хатлар бастыру була. Халыкның илне яклаучы дигән җыелма образы әнә шул рәвешле хасил була (кар.: Сталинның «Братья и сестры» («Агалар һәм сеңелләр») дигән мөрәҗәгате). Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе җыентыгында ике редакциядә «Татар халкының фронтовик татарларга хаты» басылган һәм аларга җавап итеп Ленинград сугышчы-татарларының I Украина, I Балтыйк буе һәм II Белоруссия фронтлары сугышчыларының «Хат»ы урнаштырылган. Хәзерге вакытта бу хатларның берничә редакциясе булуы мәгълүм. 1943 елның 5 мартында «Хат» «Татар халкының фронтовик татарларга хаты» дигән исем астында «Правда» һәм «Известия»дә бастырыла, 6 мартта «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» республика газеталары битләрендә дөнья күрә. «Хат»та татар һәм рус халкының тарихи геройлары телгә алына, аларның тугандашлыгына һәм берләшүенә игътибар ителә.

«Хат»ның геройлар пантеоны Идел буеның данлыклы уллары булган В.И. Ленин, М. Горький, Я.М. Свердлов, В.М. Молотов, С.М. Киров, И. Шишкин, шулай ук татар геройлары: Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Каюм

Насыйри, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал кебек исемнәрне берләштергән. «Хат»ның үткән белән бәйләнеш идеясе татар һәм рус халыкларының 1558–1582 елларда Ливон сугышында бер якта каршылык күрсәтүе, 1914–1918 еллардагы Беренче бөтендөнья сугышы (аеруча «Брусилов янындагы алга китеш») турындагы искә төшерүләр аша күрсәтелә. Ватанпәрвәрлек анты «Идегәй» эпосыннан алынган була (җыелма текстны төзүче Н. Исәнбәт): «Бүген... бабаларыбыз гадәтенчә, Идел-анабыз ярына басып... ант итәбез:... Туган җиребезне тулысынча азат итми торып, без кылычларыбызны кыныга тыкмабыз!» [11, б. 32]. Хатны төзүчеләр башта татар һәм рус тарихының уңай герое буларак Шаһгалине (1505–1567) тәкъдим итә. Әмма «Хат»та чорның идеологик трендларын үтәү хакына рус халкының «өлкән абый» дигән төшенчәсе белән бәйле төзәтмәләр кертелгән: хан турында искә алу «өлкән абый» ролен киметүгә китерер иде, «татар милләтчелеге» үсешенә ярдәм итәр иде, «татар халкы мөстәкыйльлеген татарлар аңында яңартыр иде» [11, б. 9-10].

«Татарстан партия оешмасында массакүләм сәяси һәм идеологик эшне яхшырту торышы һәм чаралары турында» 1944 елның 9 августындагы ВКП(б) Үзәк Комитеты карары «Идегәй эпосының ханнар, феодаллар турындагы фикерне популярлаштыру»ын тискәре бәяләве нәтиҗәсендә, бу эпоска һәм тарихи персонажга мөнәсәбәтне үзгәртү «Совет әдәбияты» битләрендә чагылыш таба.

Казан ханы Шаһгалинең Ливон сугышында катнашуы турындагы фрагмент соңгы редакциядән югалса да, без бу материалның эзләрен Кави Нәҗминең «Тереклек бирүче көч» мәкаләсендә таптык. Әдип тарихчы-академик В.В. Вельяминов-Зернов (1830–1904) хезмәтеннән өземтәдә Казан ханын полководец дип атап, 1558 елда Ливон сугышының башлангыч этабында Касыйм һәм Зөя татарлары белән җитәкчелек итүе ассызыклана. Рус тарихчысы шулай ук 1560 елда Феллин янындагы сугышта татарларның ролен дә күрсәтә. Алга таба Кави Нәҗми татар солдатларының Россия дәүләте сугышларында, бигрәк тә Пруссиягә (Германиягә) каршы катнашуларының дәвамчанлыгына басым ясый. Мәкаләдә берничә сугыш искә алына: 1756–1763 еллардагы җидееллык сугыш, 1812 елгы Ватан сугышы, 1853–1856 еллардагы Кырым сугышы, 1904-1905 елгы рус-япон сугышы, Беренче бөтендөнья сугышы (К. Нәҗми аны «Ярман сугышы» дип атый) [12, б. 72).

Бөек Ватан сугышы елларында (1941–1945) совет чорын да кертеп, гомуми дәүләтчелек өчен СССРның рус халкы һәм башка халыклары көрәшенең героик сыйфатларын барлау төп әһәмияткә ия була. Димәк, геройлар пантеоны да төзелә. Бу аеруча Сталинград сугышында җиңүдән соң көчәя. Волга-Идел (Итил) елгасы образы гомумроссия һәм татар традицияләрендә аерым урынны алып тора. Нәкъ менә Идел буендагы дәүләтчелекне саклау өчен көрәш «Идегәй» татар эпосы белән бәйле була, анда Идел йорт дип атала, ягъни дәүләтчелек белән бәйләнә: «Идел-Йорт, Идел-йорт». [13, б. 42].

Идел образы Гадел Кутуйның «Без – сталинградчылар» нәсеренә дә килеп керә. Анда «чал Идел»не искә төшереп, СССР халыкларының дуслыгына дан җырлана: «Без – руслар, украиннар, татарлар, белоруслар». Текстта ике казакъ сугышчысы искә алына. Автор подполковник Михайловны мактап, үткәндәге геройларга лаеклы булуын күрсәтә: «Кутузовтай тыныч ул. / Чапаевтай кызу ул». Гадел Кутуй Сталинград сугышының танылган полководецы дип, маршал (текстта генерал-полковник) Константин Рокоссовскийны һәм артиллерия маршалы Николай Вороновны тасвирлый [14, б. 29-30]. Бу бер үк вакытта совет чорының геройларын да, Россия дәүләтенең үзәкләштерелгән дәүләте чорындагы бер төркем текстларга да карый. Ул бер үк вакытта гомумроссия персонажлары да, шулай ук татар этносыныкы да.

Әгәр яңадан «Татар халкының фронтовик-татарларга хаты»на әйләнеп кайтсак, анда Алабуга кешесе, I Казан ирләр гимназиясе укучысы Иван Шишкин ясаган табигать сурәтләре рус табигатенең чагылышы булуы белән танышырбыз.

Рус мәдәнияте Кави Нәҗми һәм Гази Кашшафның Советлар Союзы герое (1944) Асаф Абдрахмановка (1918–2000) багышланган «Диңгез батыры» очеркында да күрсәтелә. Кара диңгез флоты составында көрәшкән сугышчы Севастополь югары хәрби-диңгез училищесын тәмамлаган була (1942). Очеркта шулай ук адмирал Ф.Ф. Ушаков һәм П.С. Нахимов кебек танылган флотчылар да искә алына. Очерк авторлары П.С. Нахимовны Кырым сугышы елларында (1853–1856 елларда) «Севастопольны саклаучы йөрәк» дип күрсәтәләр. Очеркта шәһәр рус армиясенең иң яхшы патриотик

традицияләрен саклаучы буларак тарихи җирлектә бирелә. Очеркта мәдәни нигез (эчтәлек) әһәмиятле роль башкара. Пушкин белән Тукай – бөек шагыйрьләр, Айвазовский даһи рәссам буларак ачыла. Ике халыкның дуслыгы хронотопта чагылыш таба: очерк авторлары Пушкин белән Айвазовскийны Кырымның онытылмас картинасын тудырулары өчен югары бәяли [15, б. 56–60]. Шул рәвешле, әлеге очеркта «Хат»тагы шикелле совет сугышчылары тарафыннан Россиянең мәдәни казанышларын яклау идеясе алга чыга.

Без өйрәнә торган вакыт аралыгында журналда революция вәкилләрен күрсәтү әһәмиятле урын алып тора. Аларның образлары татар большевиклары Хөсәен Ямашев (1882–1912) [16] һәм Камил Якуб (1894–1919) турындагы мәкаләләрдә мәңгеләштерелгән [17]. Әгәр беренчесенең исеме XX гасырның беренче яртысына туры килсә, икенчесенеке Казанда Совет власте урнаштыру, Гражданнар сугышы чоры белән бәйле. Х. Ямашев турындагы мәкаләдә рус телен белүче башлангыч мәктәп укучыларын әзерли торган Казан Татар укытучылар мәктәбендә (1902) укуына басым ясала. М. Гайнуллин аның сәяси эшчәнлеген яктыртып, Х. Ямашевның 1903 елдан РСДРП(б)ның Казан комитетында катнашуын ассызыклый.1905–1907 революция елларында Я.М. Свердлов, С.А. Лозовский, И.А. Саммерның комитет җитәкчеләре булуы әйтелә. Әдәбият галиме партия эшен оештыручы татар революционерының исеме В.И. Ленин җитәкчелегендә Женевада чыгарыла торган «Пролетарий» газетасында искә алынуын искәртә (11 октябрь 1905 ел). Шулай ук мәкаләдә Оренбургта чыга торган «Урал» большевиклар газетасы буларак бәяләнә. Х. Ямашевның көрәштәшләре буларак Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов исемнәре күрсәтелә. Мәкаләдә М. Гайнуллин Х. Ямашевның некрологы бастырылган «Невская звезда» большевиклар газетасын революционер эшчәнлегенә лаеклы бәя бирмәгән «Йолдыз» либераль газетасына каршы куя. Г. Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» шигыре татар революционеры үлеменә некролог (матәм) булып яңгырый. Мәкаләнең йомгаклау өлешендә Россиядәге революция хәрәкәтендә Казанның аерым урын алып торуы ассызыклана. Мәкалә кысаларында Совет дәүләтенең аерым вәкилләре һәм революционерлары В.И. Ленин, В.М. Молотов, С.М. Киров, Я.М. Свердлов искә алына. [16, б. 62–69].

«Безнең Камил» очеркының герое 1918 елда Казан советының Мөселман комиссариатын оештыручы, 1918-1919 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге мөдире Камил Якуб (1894–1919) була. Ул Татар запас батальонының фетнәче солдатлары алдында чыгыш ясаганда үтерелгән. Текстта Камил Якуб Милләтләр эшләре буенча Наркомат каршында төзелгән Үзәк мөселман комиссариаты эшлеклесе, ул «Ленинның бөек көрәштәше, большевиклар партиясендә милли мәсьәләне иң яхшы белүче иптәш И. В. Сталин» ярдәмчесе булган». [17, б. 47–53].

Текстта немецлар темасы да күтәрелә. С. Фазлуллин 1918 елның язында Мулланур Вахитов образын немец һөҗүме куркынычына каршы көрәшүен ача. Очеркта Болак арты республикасы оешу 1918 елның мартында Петроградка немец армиясенең һөҗүме белән тәңгәл килгәнгә, немец офицеры Бартолад кулы уйнавы раслана. 1918 елның августында Мулланур Вахитовны үтерү татар буржуазиясенең планнарын җимергән өчен үч алуы дип бәяләнә [17, б. 75]. К. Нәҗми үзенең «Тереклек бирүче көч» очеркында Хөсәен Ямашевны Ленин-Сталинның тугры көрәштәше буларак бәяли («Ленин-Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән»). Нәтиҗәдә, Х. Ямашевка дан җырлаган Г. Тукай революция парадигмасының бер өлешенә әверелә [12, б. 74].

1944 елның октябрендә 1944 елның 9 августындагы Карарга җавап итеп «Совет әдәбияты» журналының октябрь санында «Тарихи дөреслек өчен» [18, б. 3–8] мәкаләсендә Нәкый Исәнбәтнең Алтын Урда концепциясен тәнкыйтьләп, «Идегәй» дастанының җыелма тексты алдындагы «Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы» фәнни кереш мәкаләдә җавап басыла [13].

Редколлегия, «Идегәй» дастанының җыелма тексты прогрессив әсәр булып тормый, ә Мәскәү җирен бөлгенлеккә төшергән Идегәй үзе, Бөек Ватан сугышы шартларында, төп рольне рус халкы уйнаган чорда уңай мисал булып тора алмый: «Идегәй образын гәүдәләндергән әсәр прогрессив әсәр итеп түгел, артка сөйри торган зарарлы әсәр итеп каралуы бик дөрес», – дип белдерә. [18, б. 8].

Югарыда әйтелгән карар фронт шигъриятен бәяләүгә дә йогынты ясый. Әдәбият галиме Гали Халит Ш. Мөдәррискә багышланган «Сугыш һәм шагыйрь» мәкаләсендә

шагыйрьнең «Командир» (1943) шигырендә җибәрелгән сәяси хатасын күрсәтә [19, б. 58]:

«Син лаексың меңгә үлмәс бабаңнарга,
Каракаштай горур очтың җилгә каршы.
Син лаексың изге Идегәй каһарманнарга,
Чөнки әнкәң, туган әнкәң – татар халкы».

1945 елда татар халкы галим-энциклопедист Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп үтә. Бер ел элек юбилей мәкаләсендә әдәбият белгече М. Гайнуллин укучыларның игътибарын галимнең рус дөньясы белән элемтәләренә юнәлтә. Мәкалә авторы К. Насыйриның Казан руханилар семинариясендә эшләвен, Казан император университетында ирекле тыңлаучы булуын да телгә ала, шулай ук әлеге кайтавазны шәрык галиме В.В. Григорьев (1816–1881) [20] биографиясендә дә күрсәтә. К. Насыйриның «Фәвакиһел җөләса...» хезмәте аша Шәрык белгече, профессор В.Д. Смирнов (1846–1922) тарафыннан татарларның Истанбул басмаларыннан Россия файдасына китүе уңай бәяләнә. Мәкалә ахырында К. Насыйриның 1871 елның 23 октябрендә Казан уку-укыту округының татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре буенча инспектор итеп билгеләнгән немец этносы вәкиле В.В. Радлов белән низагы турында мәгълүмат бар. Галимнең Россия яклы позициясе түбәндәге цитата аша көчәйтелгән: «Без – Россия кешесе, бу Россиядә булган нәрсә безгә җитә». [21, б. 92].

М. Гайнуллин «Каюм Насыйри документларда» мәкаләсендә татар галименең Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» белән хезмәттәшлеген уңай күренеш итеп күрсәтә. К. Насыйриның Мәхкәмәи-шаргыя Оренбургыя (мөфти М. Солтанов, казый Р. Фәхретдинов), татар либераль байлары (А. Хөсәенов), түрә һәм галим В. Радлов белән бәйләнышларын тискәре элемтәләр буларак бәяли. [22, б. 45–52].

## Йомгак

«Совет әдәбияты» журналы, Бөек Ватан сугышы елларында геройлар пантеонын формалаштырганда, Ватанны саклаучыларның типик биографияләренә басым ясый. Басмаларның максаты – укучыларны дошман белән көрәшкә, батырлык эшләүгә, Җиңү хакына фидакарь хезмәт итүгә рухландыру. Сугышның һәр этабында шул вакытта җәмгыять алдында торган максатларга һәм бурычларга бәйле рәвештә үз геройлары булып торган.

### Әдәбият


1. Соболева А. Н. Формирование образа героя и врага у советской молодежи в 1920–1930-е гг. // Политика и общество. 2017. №10. С. 78–87.
2. Черкунова Н.В. Формирование образа героя в 1930-е гг. в СССР как способ военизации сознания молодежи // Известия ПГПУ им. В.Г. Белинского. 2012. № 27. С. 1058–1088.
**Шагирзян Лена** (Шакирзянова Лена Галимзяновна, 1945–2017) – один из видных представителей поэзии XX в. В 1962 г. окончила Кулле-Кимовскую (Атнинский район РТ) среднюю школу и поступила на отделение татарского языка и литературы Казанского педагогического института. После окончания вуза один год проработала учителем в татарской средней школе № 80 г. Казани. В 1968–1973 гг. была певицей Ансамбля песни и танца ТАССР. Позже, в 1974–1987 гг., работала переводчиком-журналистом в Татарстанском государственном радиокомитете. С 1987 г. Лена Шагирзян целиком посвятила себя литературному творчеству. Является автором сборников стихов «Переполненная душа» (1982), «Верую сердцу» (1986), «Азбука веры» (1993), «Крылатый конь» (1999), «Круговорот» (2002) и др. Л. Шагирзян известна и как автор ярких публицистических, теоретических и критических статей по литературе, воспоминаний о выдающихся деятелях искусства, поэтических посвящений современникам. За заслуги в развитии татарской ли-

temporaries. For her merit in the development of Tatar literature and art, L. Shagirzyan was awarded the honorary title of "The Honoured Artist of the Republic of Tatarstan" in 2000, and the Literary Prize of the Writers' Union of Tatarstan named after H. Taktash for her book "Nostalgia" and her works dedicated to Hadi Taktash, the Tatarstan State Prize named after G. Tukay in 2011, and the honourary title "People's Poet of Tatarstan" in 2016.

тәнкыйди мәкаләләр, атаклы өлкән буын иҗат әһелләре турындагы истәлек язмалары, замандашларына атап язган шигъри багышламалар авторы буларак та билгеле

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Л.Шагыйрьҗан 2000 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, 2007 елда «Сагынмаклык» китабы һәм Һади Такташка багышланган әсәрләре өчен Татарстан Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге әдәби премиясенә, 2011 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, 2016 елда «Татарстанның халык шагыйре» мактаулы исеменә лаек була.

тературы и искусства Л. Шагирзян в 2000 г. была удостоена почетного звания «Заслуженный деятель искусств Республики Татарстан», в 2007 г. – литературной премии Союза писателей Татарстана имени Х. Такташа за книгу «Ностальгия» и произведения, посвященные Хади Такташу; в 2011 г. – Государственной премии Татарстана имени Г. Тукая, в 2016 г. – почетного звания «Народный поэт Татарстана».

**For citation:** Sharova, L. "We didn't get caught in the storm" // Tatarica. 2025. № 2 (25), pp. 162–173. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-162-173

**Сылтама өчен:** Шарова Л. Н. «Без давылга юлыкмыйча калдык» // Tatarica. 2025. № 2 (25). 162–173 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-162-173

**Для цитирования**: Шарова Л. Н. «Мы выстояли во время бури» // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 162–173. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-162-173

The historical discourse and literary legacy of the Great Patriotic War period in Tatar literature has been the focus of public attention to this day. Considering the current events in the country, we can argue that this topic has become even more relevant. In the work of the generations of 1941 and 1945, and later, it has been running like a red thread throughout the 20th century and into the early 21st century. Let's focus on one of those writers, poet Lena Shagirzyan, who from the very beginning of her literary work took an active civic position.

In the literary tradition of the Soviet period, that is, in the post-war years, the appeal to the theme of war was expressed primarily in the heroic-patriotic spirit. Literature served to create a heroic image of the Soviet soldier who gave his life for his Homeland, saved the whole world from destruction, when "writers fought with a pen as if it were a bayonet." Probably, there has never been a nation and its literature as united as in those years, feeling a common heart rhythm and breathing the same air.

*"Along with heroic pathos, the national character, the image of a courageous Tatar man rose in Tatar literature. This completely changed our literature, which had focused on internationalism within the framework of the socialist realism requirements. The image of a Tatar soldier, a Tatar man, placed in the center of each work, was equated with courage, honesty, loyalty, dedication to the country, idealized so as to be proud of it. The "masses" in pre-war Soviet literature were replaced by such concepts as "Tatar people", "native land", "Motherland". It was not a civic duty or class struggle that came to the fore, but the struggle for life, for the country, for love, and for the future. Thus, humanistic tendencies were strengthening in literature. They have remained in Tatar literature even after the end of the war." [1, p. 29]*

The lyrics and patriotism of the Great Patriotic War are a unique cultural phenomenon that we are still studying and have not yet fully understood, although numerous scientific research papers have been written and monographs have been published about this. Still, the military-themed works, created in the 70s and 80s, generally require a new focus, since their pathos, imagery, aesthetic, and psychological layers were different.

In the "thaw period", in the late 1960s and 1970s, and later in the literature of the 1980s, it was possible to talk about the wounds and sorrows left by the war not openly, but through symbolic images. The names of the repressed writers were returned, the archives were opened, the documents that had previously been classified were made public. Individual family stories and destinies were studied.

In the last two decades of the 20th century, the general public began to fully see, analyze, and understand the price at which the great victory had been won. Let's just recall the lines from the famous poem by Razil Valeev. Our generation, the children of the 1980s, remembers it as a song written by Rashit Abdullin. We sang this song "Twenty Million" at demonstrations and events dedicated to the Great Victory:

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Balalar uinyilar "sugyshly" ueny,<br>Sugysh ul alarga – tik uen.<br>E minem uemda kaitmyicha kalgannar –<br>Egerme million, egerme million.<br>Yaz kilgech, shytalar kan tosle chechekler,<br>Kotlyilar Zhinune – il tuen.<br>Meidanda ut yana, meidanda – chechekler,<br>Egerme million, egerme million [2, 568 b.] | Children are playing a "war game",<br>War is just a game for them.<br>And in my thoughts are those who did not return. -<br>Twenty million, twenty million.<br>When spring comes, blood flowers sprout,<br>Congratulations on the victory, the country's holiday.<br>There is a fire burning in the square, flowers in the square,<br>Twenty million, twenty million [2, p. 568]. | Children play their "war game", so bold,<br>For them, war's just a story to be told.<br>But in my heart, a sorrowful refrain,<br>For twenty million souls, who died in pain.<br>When spring arrives, red poppies bloom,<br>A victory day, dispelling winter's gloom.<br>But in the square, a burning pyre of shame,<br>For twenty million lost, a life's extinguished flame [2, p. 568]. |

Lena Shagirzyan was a poet who came to Tatar literature being quite mature, having lived a long life and worked a lot, having accumulated intellectual and aesthetic baggage [3], [4], [5], [6]. And from the very first years of her work, she appeared as a poet with a pronounced civic position. Before joining literature, she was employed as a teacher, was a soloist artist of the Tatar State Song and Dance Ensemble, and worked as a journalist and translator for the Tatarstan Television and Radio Company. Lena Shagirzyan received the blessing to enter great literature from the legend of her village, the veteran Sibgat Khakim.

The poet repeatedly mentioned this in her interviews and memoirs. When asked who her mentor was, she always mentioned Sibgat Khakim: *"Sibgat abyi! Sibgat abyi Khakim. He was also from Kulle-Kim. We were still children, silently watching his return and not even daring to talk to him. But after I entered the institute, I brought to Sibgat abyi my 10-15 poems and asked him to look at them. I am grateful to Sibgat abyi, he warmly welcomed me and told me to contribute them to "The Lights of Kazan" ("Kazan utlary"). There could be no greater happiness. I learnt a lot from Sibgat abyi and fell in love with him. I still love his poetry"* [7, p. 297].

Her birthplace was the village of Puchezh in the Aktanyshsky District, then her parents, teachers, moved to Bolshaya Atnya, settled in Kulle-Kim, where the future poetess spent her childhood, adolescence, and youth. Lena Shagirzyan was born on June 4, 1945, exactly after the end of the war. The family already had two older brothers, Amur and Nil, and her sister, Luara, would be born later.

The war did not bypass the Shakirzyanovs in those years. Their father returned with his leg wounded. But alive! And this was a great happiness. Lena Shagirzyan recalled that he was ashamed of his injured leg and his disability when he came to the school to teach in front of the class.

In general, the theme of war would occupy a huge place in her poems, and publicistic works. She would also touch on the theme of the orphanage that worked in Kulle-Kim in those years, and later – in the late 90s, in the noughties, when she was writing a book of her memoirs. In those years, when the facade of the Soviet era was well-designed and decorated with beautiful slogans, there was no place for orphans whose parents died in the war...

In the very first books, Lena Shagirzyan highlighted the topic of the home front heroes who had survived the Great Patriotic War. As early as in her first small poetry collections, she introduced new topics, psychological depth, and unusual generali-

zations. This was a completely different patriotism and different analysis of the events. It was her contemporaries, the children of 1941 and the pleiades of 1945, who brought the reflection of "the children of war" and "post–war" to Tatar literature. This reflection became widespread, shaped as an experience of an entire generation. In the end, it allowed us to understand even more profoundly that the catastrophe of the war had continued like an incorrigible seam.

Here is one of Lena Shagirzyan's first poems, written on this topic, but not directly using the word "war", it reflects the fate of an entire generation and should be known:

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Bez davylga yulykmyicha kaldyk…<br>dawyldan son kurdek don'yany.<br>Aktarylyp syngan imenneren<br>kurkyp karap yordek bez anyn.<br><br>Yugalyshyp katyp kaldyk ber mel,<br>tayanyrbyz, diep, kemnerge.<br>Dawyl uze bezge kagylmady –<br>tik afete toshte innerge [8, 203 b.] | We didn't get caught in the storm...<br>We saw the world after it had passed.<br>We looked at his<br>Oaks broken and uprooted.<br>At one time, we were dumbfounded,<br>not knowing who to lean on.<br>The storm itself did not touch us,<br>but the consequences fell on our shoulders [8, p. 203]. | We didn't get caught in the storm's embrace,<br>But witnessed the world in its ravaged space.<br>We saw the mighty oaks torn out of the ground,<br>A silent testament, where chaos was found.<br><br>At first, we stood there, dumbfounded and weak,<br>Unknowing with whom our support to seek.<br>The storm itself spared us in its furious might,<br>But its heavy aftermath fell on us, through day and night [8, p. 203]. |

The poet defines the chronotope very precisely, describing the picture of "the world seen after the storm". In this chronotope, time never flows in vain, the hands of the clock are constantly counting down lives. There is no room for indifference here, the lyrical hero lives by constantly listening and feeling the pulsation of the world and life around. The author conveys the disaster of war through the personification of nature, through comparisons, metaphors, and through very vital details, events, and everyday situations. Her works of this period are characterized by a long, dramatic development. This is, in fact, the introduction of new forms, new dimensions, a step into a new rhythm. Over time, she raised it to the level of her artistic and aesthetic identity.

Lena Shagirzyan urges the readers to look at this problem from a different angle, through the text which conveys the image of a father-soldier and a mother in the home front, providing for the family, and this reality is analyzed by the child's consciousness. We know the lyrical characters of Fatikh Karim who called for rising up with a child in arms to combat the cruelty of fascist predators, and the central events of Musa Dzhalil's poem "The Young Mother" ("Yesh ana")... But Lena Shagirzyan shows us a completely new, hitherto unknown character – the image of a child who is looking forward to her father's return and does not dare to speak it out loud. In this image of a child, we see both mothers and grandmothers who, despite all the difficulties, silently endure the hardships of war. This comparison reveals the "philosophy of silence" of an entire generation:

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Deres bara… Nemets tele derese.<br>Ipi-tozlyk kyna bulsa da,<br>Suzler yatlyi awyl balalary:<br>"Guten tag" dip selem birgen bula,<br>"Gitler kaput" diep kolgen bula,<br>Yoreklere<br>Sugysh sagyshy belen tulsa da…<br>Programma | There is a lesson going on... The German language lesson.<br>At least a few words<br>Rural children memorize:<br>"Guten tag" to welcome,<br>"Hitler Kaput" to play a joke,<br>Although the hearts<br>Are filled with longing...<br>The pro- | A German lesson starts to loom,<br>In a small and rural, humble room.<br>Just a few words they learn with care,<br>These country children, breathing air.<br><br>They learn "Guten Tag" to kindly greet,<br>And "Hitler Kaput" for a joke, a playful |

| | | |
|---|---|---|
| da – ash-su isemnere:<br>Buterbrodlar, elle nerseler…<br>Balalarnyn echen bora achlyk,<br>Isemen gene ukyp eitse de.<br>… Eni soilegende, min eladym, -<br>Kainar yeshem tamgan kitapka.<br>Ul dereslek isen…<br>Tynych kyna<br>Karyi almyim shul tapka…<br>Nemets tele bigrek achy inde,<br>Nik yaratsyn any sabyilar,<br>Nemets belen atyshyp yatsyn da di<br>Elle kaida eti, abyilar … [8, 203 b.]. | gramme includes the names of dishes:<br>Sandwiches and something like that...<br>It makes the kids' stomachs twist because of hunger,<br>Although they only mention their names.<br>...When Mom was telling, I was crying, -<br>Hot tears dripped onto the book.<br>It is still in one piece...<br>I can't calmly<br>Look at this old stain...<br>The German language is very bitter,<br>Why should children love it?!<br>While fathers, brothers<br>Are fighting with them…<br>[8, p. 203]. | feat.<br>Though deep inside, their tender hearts,<br>Are filled with silent, yearning parts.<br><br>The programme teaches of dishes, rich and fine,<br>Of sandwiches, and meals divine.<br>Their hungry stomachs twist in pain,<br>Though only names are mentioned again, again.<br><br>When Mother told this tale, my tears would flow,<br>Hot drops fell down upon the book, you know.<br>It's still intact, a relic of the past,<br>But that old stain, its memory holds fast.<br>I cannot calmly look upon that mark,<br>It brings back shadows from the dark.<br><br>That German tongue, so bitter, sharp, and cold,<br>A story of a conflict, bravely told.<br>Why should these children learn to love its sound?<br>While fathers, brothers, fight on the bloody ground. |

This poem ends with the lines: "my father fought the Germans, my mother taught German." Through this paradoxical intersection, the poet emphasizes that the world is not woven of single-layered, simple truths, its knots are intertwined. With this poem, she urges us – the new generations – to be extremely careful and vigilant.

Another poem, "In the Year When the War Came to an End" ("Sugysh betken elny"), tells us that the world after the hurricane is captured by the triumph of life, and this suggests the desire of the humanity to always renew itself, to live, to continue living. The lyrical hero is depicted here as a front-line soldier who comes to a new, already peaceful, prosperous world to pick up his own child from the maternity hospital. Of course, it is a solemn moment, but there are details indicating that this idyll is not idyllic, as the poet emphasizes, these details really awaken our imagination:

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Kyryk eshen kyrga kyep toryp,<br>Eti kilgen mine almaga.<br>Totyp kaitkan synar kuly belen, –<br>Ike kuly belen kocha almagan...<br>Beirem ashy, bebei ashy pesherep,<br>Awyldashlar kotep torgannar.<br>Bik kaderle buldyk miken elle<br>Sugysh betken elny tugannar? [9, 42 b.] | Putting everything aside,<br>My father came to pick me up.<br>He carried me with his one arm, –<br>Unable to hug me with both...<br>Having set the tables,<br>The villagers were waiting.<br>Were we very dear<br>Because we were born in the year of the war end? [9, p. 42] | Putting everything aside,<br>My father came, with loving stride,<br>To fetch me from the hospital door,<br>He carried me, wanting to hug me more.<br>He held me in his one soft hand,<br>No full embrace, as he had planned.<br>Having laid the tables wide,<br>The villagers waited for us with hope inside. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Were we so very dear<br>To be born in that war end year? |

Lena Shagirzyan's lyrical hero has no feeling that the war is over and forgotten. His perception of the world is a constant anxiety. His heart is constantly worried. Gradually, this feeling develops on a universal scale – an idea of the historical course. In some of her poetic texts, written in the 1980s, she pays attention to the realities of local conflicts and wars of modern times, and once again there is a warning for the next generations. The image of an "old military overcoat" becomes a part of her creative work, its meaningful image making a strong impression on the readers. This military overcoat, which is repeatedly found in the poet's works, serves as a reminder that "we have no right to forget." Through this image, the author repeats again and again that "tragedy walks nearby, and this tragedy has neither a stopping point nor an end." Can we hear it?

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Ikenche shinel choide, beznen oide.<br>Berse iske, tetelep betken,<br>Bik kuptenge.<br>Hichkem kimi any guye typ-tyn gyna<br>Soilep tora uzenen danly yul utkenen.<br>Sugysh ise senep kalgan bu shinelge,<br>Daru katysh dary ise, toten ise.<br>Kitergenge zhinu yazyn beznen ilge,<br>Totabyz bez any Tarikh tose itep.<br>Ikenchese – ine-zhepten chykkan, yana,<br>Kurshe egete armiyeden kaitty yalga.<br>Kuresherge kergen mene beznen yanga.<br>Ike shinel choide, beznen oide.<br>Berse tuzgan, zur yul uzgan,<br>berse – yana…<br>Utny-suny kichep kaitkan kart shinelnen<br>Eitese ber izge suze bar kuk ana… [8, 203 b.] | Two military overcoats are hanging on a peg in our house.<br>One is old, worn out,<br>It's very old.<br>No one puts it on, as if it quietly<br>Talks about its glorious past.<br>This military overcoat is saturated with the smell of war,<br>The smell of a mixture of drugs and gunpowder, the smell of smoke.<br>Because it brought victory to our country in the spring,<br>We keep it as a symbol of history.<br>The second one has just been stitched, it's new,<br>The guy next door returned from the army for his days-off.<br>He came to see us.<br>Two military overcoats are hanging on a peg in our house.<br>One of them is worn out, has come a long way,<br>Another one is new...<br>The old overcoat, which has crossed fire and water, looks<br>As if he has something to say to the new one... [8, p. 203] | Two military overcoats are hanging on a peg in our house,<br>One is old, worn out, as quiet as a mouse.<br>Very old, no one puts it on,<br>As if its glorious past has not yet gone.<br>This military overcoat is saturated with the smell of war,<br>A mixture of drugs and gunpowder, and smoke from afar.<br>Because it brought victory to our country in the spring,<br>We keep it as a symbol of history, its praises we sing.<br>The second one has just been stitched, it's brand new,<br>The guy next door, his army service through.<br>He returned from the army for days-off, a short stay,<br>He came to see us, on that special day.<br>Two military overcoats are hanging on a peg in our house,<br>One of them is worn out, as quiet as a mouse.<br>One has come a long way, the other one is new...<br>The old overcoat, through fire and water, seems to view,<br>As if it has something to say, a message to impart,<br>To the new one, speaking from its weary heart. |

The image of the "military overcoat" appears in another poem, in which the poet makes a direct generalization: "if a man puts on a military overcoat, it means that the young bride or the girl will have to put off her white dress". Through this gen-

eralization, the poet's lyrical hero begins to speak not only on behalf of an entire generation, but also on behalf of all the women in the past and in the future. Universal misfortune and universal sorrow have given them this right. The author herself "puts on" the archetype of Tugzak mothers created by Dzhalil, whose works she knew from her childhood, telling us that the Fates of the daughters of the entire nation are similar to this archetype.

Gradually, this lyrical hero rises high above the ordinary, contemplating the Motherland and what is happening to it from a bird's-eye view. First, he observes the country healing its wounds of war: he tours the glorious hero cities, visits the heart of besieged Leningrad – St. Petersburg, listens to the softly whispering memory of the Mamayev Kurgan. The Mother-Earth, as if through him, speaks, transmitting her word.

The poet's lyrical hero is still the same, he is alert: he hears the rumble of war in his heart, sees both longing and despair in the eyes of his Motherland, trying to understand where it all leads to:

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Idel builap ilne karap yordem,<br>Ielep suyn echtem Idelnen.<br>Upken kebek buldym kumelep bargan<br>Yaralaryn gaziz ilemnen [7, 140 b.]. | I travelled along the Volga River, looking at the country,<br>Drinking water from the Volga River, bending down.<br>I felt as if I had kissed<br>The healing wounds of my dear country [7, p. 140] | I travelled the Volga's path, the land to scan,<br>Drank from its waters, like a thirsty man.<br>Bending low, I felt so blessed,<br>As if a kiss, my lips had pressed,<br>Upon the wounds, a loving cure,<br>For my dear country, to endure. |

The culminating point of generalization is found in the poem "I Am Peace" ("Min tynychlyk"). Here we see how the author lifts her lyrical hero to the cosmic height, making him responsible for the globe. This lyrical hero addresses the reader not only on behalf of countries, states, but also on behalf of Memory and Time. And most importantly, it appeals not only to adults, but also to the children of the new age, because all hope is for future generations. Will these children make the globe flourish or turn it back to ashes? This thought worries the poet, this pain haunts her soul:

| Transliteration | Literal translation | Rhymed translation |
|---|---|---|
| Don'yada ber gene awyl da, sheher de<br>"Sugysh" dip atamas uramyn…<br>Zhirde bit million-million kesheler<br>Tynychlyk telende anlashyp yeshiler.<br>E sugysh – telsez ul,<br>Tele yuk soilerlek…<br>Bar eshe – kan koyu,<br>Zhimery oilerne…<br>Duslashyik, balalar!<br>Min bulam – Tynychlyk.<br>Min – menge Zhirneke,<br>Imanym korych, nyk! [7, 139 b.] | Not a single village or city in the world<br>Will name its street "War"...<br>Because there are millions and millions of people on Earth.<br>Who live in harmony because of the language of Peace.<br>And the war is dumb,<br>It has no tongue...<br>All it knows is bloodshed,<br>Destroying houses...<br>Let's make friends, guys!<br>I will be Peace.<br>I belong to the Earth forever,<br>My faith is steel, so strong! [7, p. 139] | Not a single village or city, you'll find,<br>Will name its street "War" of any kind.<br>Because on Earth, in millions, people dwell,<br>In harmony, where peaceful languages compel.<br>And war is dumb, it has no voice to speak,<br>All it knows is bloodshed, and homes made weak.<br>Destroying houses, a destructive blight,<br>Let's make friends, guys, and bring forth light!<br>I will be Peace, my purpose is clear and true,<br>I belong to Earth, forever, me and you.<br>My faith is steel, unyielding, strong, and bold,<br>A promise for the future, to unfold. [7, p. 139] |

In Lena Shagirzyan's work, both in poetry and journalism, the theme of war and the Motherland leads to the most central themes – the fate of Humanity and the Universe. In her voluminous poems

of the late 1990s and early noughties, her lyrical hero no longer occupies the position of an observer, a diagnostician, but assumes the guise of a visionary soothsayer. He calls for understanding the essence of the bloody events taking place in the international arena, to understand what mistakes need to be corrected in order to stop this catastrophe.

*"The sources and causes of wars are different, and identifying them would make it possible to find ways to prevent this catastrophe. I've read that it's wrong to consider war inevitable. I believe that the main thing is to unite powerful social and political forces fighting against the war. The world already knows that only the imperialists and colonialists organized wars under the guise of liberating other peoples or directly claiming national superiority. We also see and hear that the powers striving to become the main ones on the whole planet have a lot of experience in this field..."* [7, p. 262]

This is the general "recipe" that Lena Shagirzyan suggested in the last years of her creative life. I want to believe that humanity will listen to the poet's words and hear them.

**References**

1. Zagidullina, D. F. (2025). *Bөek vatan sugyshy chory prozasynda "okop khakyikate"* ["The Trench Truth" in the Great Patriotic War Prose]. Gasyrlar avazy. Ekho vekov, No. 1, pp. 20–31. (In Tatar)
2. Valiev, R. I. (1999). *Sailanma əsərlər: shigyr'lər, җyrlar: 4 kitapta* [Selected Works: Poems, Songs: In 4 Books]. 1 tom. 568 p. Kazan', Natsional'naya kniga. (In Tatar)
3. Kurbatov, Kh. R. (1993). *Җanga yakyn shigyr'lər* [Poems Close to Your Heart]. Rodina Tatarstan. 24 sent. (In Tatar)
4. Valiev, M. Kh. (1999). *Tuksanynchy ellar ədəbiyaty* [Literature of the Nineties]. Ogni Kazani. No. 8, 150 p. (In Tatar)
5. Rakhmani, R. F. (2008). *Shagyirənең yazmysh keləme* [The Fate of the Poetess]. Sovremennaya tatarskaya literatura. Pp. 234–246. Kazan', Obrazovanie. (In Tatar)
6. Valiullin, I. R. (2006). *Һər shagyir' – ber dər'ya...: ədəbi tənkyit' məkalələre* [Each Poet - Һәр shagyyr -Is a Separate Sea]. Pp. 94–113. Kazan', Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
7. Shagirzyan, L. G. (2024). *Kүңelemnең khөr koshlary: shigyr'lər, poehma, publitsistik yazmalar, məkalələr* [Free Birds of My Soul: Poems, Verses, Journalistic Notes, Articles]. 383 p. Kazan', Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
8. Shagirzyan, L. G. (1996). *Shigyr'lər, poehma* [Verses and Poems]. 203 p. Kazan', Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
9. Shagirzyan, L. G. (2020). *Җyly kirək moңga da: shigyr'lər, poehmalar, bagyshlaular* [Even a Melody Needs Warmth: Poetry, Verses, Dedications]. 544 p. Kazan', Rukhiyat. (In Tatar)
10. Shagirzyan, L. G. (1999). *Kanatly at: shigyr'lər.* [The Winged Horse: Poems]. 39 p. Kazan', Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

# «БЕЗ ДАВЫЛГА ЮЛЫКМЫЙЧА КАЛДЫК»

**Луиза Николаевна Шарова,**
«Татмедиа» АҖ, «Татарстан» журналы редакциясе,
Россия, 420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2 йорт,
koioakan54@mail.ru

Татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы чоры тарихи дискурсын һәм әдәби мирасын ваемлау әлегәчә дәвам итә. Хәзерге вакытта, ил-көндәге вакыйгаларны исәпкә алып һәм вазгыятьне күздә тотып, бу тема тагын да актуальләште, дисәк тә ялгышмабыз. Ә инде 1941-1945 нче елгы буыннарның иҗатында ул XX гасыр буена һәм XXI йөз башында да кызыл җеп булып сузылып килә. Шундый шагыйрьләрнең берсенә – иҗатының башлангыч чорыннан ук актив гражданлык позициясе булган Лена Шагыйрьҗан иҗатына тукталыйк.

Совет чоры әдәби традициясендә, ягъни утлы елларда сугыш темасына мөрәҗәгать, иң беренче чиратта, героик-патриотик рухта күзаллана. Әдәбият ватан өчен гомерен аямаган, бар дөньяны һәлакәттән саклап калган совет солдатының каһарман образын тудыруга хезмәт итә, «язучылар каләмне штык итеп тотып көрәшә». Әле беркайчан да бу еллардагы кебек тулы бер халык һәм аның әдәбияты уртак пульсны тоеп, уртак гамь белән суламагандыр, мөгаен.

*«Героик пафос белән бергә, татар әдәбиятында милли характер, батыр һәм кыю татар кешесе образы калкулана. Бу социалистик реализм таләпләре кысасында интернациональлеккә йөз тоткан әдәбиятыбызны тулысынча үзгәртә. Һәр*

*әсәрнең үзәгенә куелган татар солдаты, татар кешесе образы кыюлык, намуслылык, тугрылык, ил өчен үз-үзеңне аямау югарылыгына күтәрелә, горурланырлык итеп идеаллаштырыла. Сугышка кадәрге совет әдәбиятындагы «массалар» урынына – «татар халкы», «туган җир», «ватан» кебек төшенчәләр килә. Гражданлык бурычы, сыйнфый көрәш түгел, яшәү, ил, мәхәббәт, киләчәк өчен көрәшү алга чыга. Шул рәвешле, әдәбиятта гуманистик тенденция ныгый. Болар инде сугыш беткәннән соң да татар әдәбиятында урнашып калалар»* [1, б. 29].

Бөек Ватан сугышы чоры лирикасы һәм патриотикасы – уникаль культурологик феномен. Бу хакта күпсанлы фәнни-тикшеренү эшләре язылса, монографияләр дөнья күрсә дә, аны әле без бүгенге көнгәчә бар тирәнлегендә өйрәнеп, ваемлап җиткермибез. Ә инде 70-80 нче елларда сугыш темасына язылган әсәрләр гомумән яңа фокустан өйрәнүне таләп итә, чөнки аларның пафосы да, образ-эстетикасы да, психологик катламнары да башка.

«Җепшеклек чоры» нда, 60 нчы еллар азагы – 70 нче елларда, соңыннан 80 нче еллар әдәбиятында сугыш калдырган җәрәхәт эзләре, яралар һәм хәсрәт турында инде турыдан-туры булмаса да, образ-символларга төреп, тел тибрәтеп әйтергә мөмкин була башлый. Репрессияләнгән әдипләрнең исемнәре кайта, архивлар ачыла, моңарчы яшерен гриф астында яткан документлар халыкка барып ирешә. Шулай ук аерым бер гаилә тарихлары, язмышлар да күздән кичерелә.

Бөек Җиңүнең нинди югалтулар бәрабәренә яулап алынганын XX йөзнең соңгы ике дистәсендә киң җәмәгатьчелек инде бар колачында күзаллый, анализлый, аңлый башлый. Разил Вәлиевның мәгълүм шигырендәге юлларны гына искә төшерик. Безнең буын, 80 нче елгы балалар, аны Рәшит Абдуллин көй язган җыр буларак яхшы хәтерли. «Егерме миллион» дигән бу җырны без инде митингларда, Бөек Җиңүгә багышланган чараларда җырлап үстек:

*Балалар уйныйлар «сугышлы» уены,*
*Сугыш ул аларга – тик уен.*
*Ә минем уемда кайтмыйча калганнар –*
*Егерме миллион, егерме миллион.*
*Яз килгәч, шыталар кан төсле чәчәкләр,*
*Котлыйлар Җиңүне – ил туен.*
*Мәйданда ут яна, мәйданда – чәчәкләр,*
*Егерме миллион, егерме миллион* [2, б. 568].

Лена Шагыйрьҗан – татар әдәбиятына шактый соң һәм җитлегеп, зур тормыш, хезмәт юлы узып, интеллектуаль-эстетик багаж туплап килгән шагыйрь [3; 4; 5; 6]. Иҗатының иң беренче елларыннан ук аермачык, тәмам оешып-формалашып җиткән гражданлык позициясе булган шагыйрь дә ул. Лена Галимҗан кызы, әдәбиятка аяк басканчы, укытучы булып эшли, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты – артист була, «Татарстан» телерадиокомпаниясендә журналист-тәрҗемәче вазифасын башкара. Зур әдәбиятка килер өчен фатиханы да Лена Шагыйрьҗан үзе үскән авылның легендасы – фронтовик шагыйрь Сибгат Хәкимнән ала.

Бу хакта әңгәмәләрендә дә, истәлекләрендә дә кат-кат искә ала шагыйрь. Остазлары кем булуы турында сораганда, Сибгат Хәким исемен һич кенә дә атамыйча калмый: *«Сибгат абый! Сибгат абый Хәким. Күлле Кименеке дә булгач. Без әле бала-чага, аның кайтканнарын күзәтәбез, ә сораулар биреп йөрерлек кешеләр түгел әле. Ләкин инде институтка укырга кергәч, Сибгат абый янына шигырьләремне алып килдем. Сибгат абый, карап карагыз әле, дип, бер ун-унбиш шигырь китердем. Сибгат абыйга рәхмәт, җылы карады ул миңа. Шигырьләрегезне "Казан утлары"на бирәбез, диде. Моннан да зуррак бәхет булырга мөмкин түгел иде инде. Сибгат абыйдан бик өйрәндем дә мин, яраттым да аны. Аның шигъриятен яраттым»* [7, б. 297].

Туган төяге – туфрагы Актаныш районы Пучы җирлеге булса да, әти-әниләре – укытучылар – Олы Әтнә, Күлле Кимегә килеп урнаша һәм балачагы, үсмер еллары, яшьлеге шунда уза булачак шагыйрьнең. 1945 елның 4 июнендә, нәкъ сугыш тәмамланганнан соң дөньяга килә Лена Шагыйрьҗан. Гаиләдә инде ике олы абыйсы – Амур белән Нил бар, соңыннан сеңелкәше Луара туачак.

Сугыш ул елларда беркемне дә уратып узмый, Шакирҗановлар гаиләсенә дә җиле тиеп үтә аның. Әтиләре – гаилә тоткасы – яраланып, аягын имгәтеп әйләнеп кайта. Ләкин исән! Монысы инде – олы бәхет. Аның имгәнгән аягыннан оялуы, мәктәптә класс алдына укытырга кергәндә, гариплеге өчен пошынуы, хафалануы хакында язганнарында искә ала Лена Шагыйрьҗан.

Гомумән, аның шигырьләрендә дә, поэмаларында да, публицистикасында да сугыш темасы гомер буена зур урын биләячәк. Истәлекләрендә ул шул елларда Күлле Кимедә

эшләгән балалар йорты – детдом темасына да орыначак. Әлбәттә, инде соңрак – 90 нчы еллар азагында, нуленчеләрдә, истәлекләр китабын язганда. Ә совет чорының фасады алар үскән вакытта әле тантаналы, дөрес шигарьләр белән бизәлгән, анда ата-аналары яу кырында һәлак булган тома ятимнәргә бик урын юк...

Лена Шагыйрьҗан Бөек Ватан сугышы һәм совет солдаты белән сугыш чоры афәтен кичкән тыл батырлары темасын беренче китапларында ук яктырта. Тәүге кечкенә генә шигъри җыентыкларынңа ук, соңрак мәҗмугаларында басылган шигырьләрендә дә ул яңа оптика, психологик тирәнлек һәм гадәти булмаган гомумиләштерүләр алып килә. Бу – бөтенләй башка патриотика һәм анализ. Нәкъ менә аның чордаш каләм ияләре – 1941 ел балалары һәм 1945 елгылар плеядасы – татар әдәбиятына «сугыш чоры балалары» һәм «сугыштан соңгылар» рефлексиясен китерде. Бу рефлексия киң колач алып, тулы бер буын кичерешләре булып формалашты. Ахыр чиктә, безгә сугыш һәлакәтенең төзәлмәс җөй булуып сузылуын тагын да тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирде.

Менә Лена Шагыйрьҗанның бу темага иҗат ителгән, әмма «сугыш» дигән сүзне турыдан-туры атамаган, тулы бер буын язмышын чагылдырган, программ рәвештә өйрәнелергә тиешле тәүге чор шигырьләреннән берсе:

*Без давылга юлыкмыйча калдык...*
*давылдан соң күрдек дөньяны.*
*Актарылып сынган имәннәрен*
*куркып карап йөрдек без аның.*
*Югалышып катып калдык бер мәл,*
*таяныpбыз, диеп, кемнәргә.*
*Давыл үзе безгә кагылмады –*
*тик афәте төште иңнәргә* [8, б. 203].

«Давылдан соң күргән дөнья» картинасын сурәтләгәндә, хронотопны бик дөрес һәм анык билгели шагыйрь. Бу хронотопта вакыт беркайчан да үткәннең гыйбрәтен исәптә тотмыйча тиккә генә акмый, сәгать теле гел гомерләрне санап йөри. Монда ваемсызлыкка урын юк, лирик каһарман һәрдаим дөнья гаме һәм тормыш пульсациясен тыңлап, тоемлап яши. Сугыш афәтен автор шушындый табигатьне персонификацияләү, чагыштырулар, метафоралар аша да җиткерә, бик тормышчан детальләр, вакыйгалар, көнкүреш хәлләре аша да сурәтли. Бу чор иҗатында аның шигъриятендә озын, драматургик башлангыч белән өретелгән «полотноларга» йөз тоту үзен бик нык сиздерә. Бу, асылда, яңа формалар, яңа үлчәмнәр үзләштерү, яңа ритмикага атлавы була шагыйрьнең. Тора-бара инде ул аны үз өслүбе, эстетик үзенчәлеге дәрәҗәсенә күтәрә.

Фронтовик әтисе һәм тылда калып, дөньяны тарткан әнисе образларын бирү, аларның гамәлләрен бала үзаңы аша кичерү үзәктә булган текстта Лена Шагыйрьҗан укучысын бу темага көтелмәгән фокустан карарга чакыра. Без фашист ерткычларының кансызлыгы каршында, башка чарасы калмагач, баласын тотып үлемгә күтәргән Фатих Кәримнең лирик каһарманнарын да, Муса Җәлилнең «Яшь ана» шигырендәге үзәк өзгеч вакыйгаларны да хәтерлибез, беләбез... Ә менә Лена Шагыйрьҗан безгә бөтенләй яңа, моңарчы таныш булмаган каһарманны күрсәтә – күз текәп эткәсе кайтуын көткән һәм әнкәсенең дәресләрендә, нәни йөрәге белән өзгәләнсә дә, кычкырып сүз әйтергә җөрьәт итмәгән сабый образын. Бу балада без, авызы тулы кара кан булса да, телен яшереп, терсәген аркылыга тешләп түзгән аналарны да, әбиләрне дә күрәбез. Бу чагыштыру тулы бер буынның «дәшмәү фәлсәфәсен» дә ачып сала:

*Дәрес бара... Немец теле дәресе.*
*Ипи-тозлык кына булса да,*
*Сүзләр ятлый авыл балалары:*
*«Гутен таг» дип сәлам биргән була,*
*«Гитлер капут» диеп көлгән була,*
*Йөрәкләре*
*Сугыш сагышы белән тулса да...*
*Программада – аш-су исемнәре:*
*Бутербродлар, әллә нәрсәләр...*
*Балаларның эчен бора ачлык,*
*Исемен генә укып әйтсә дә.*
*...Әни сөйләгәндә, мин еладым, –*
*Кайнар яшем тамган китапка.*
*Ул дәреслек исән...*
*Тыныч кына*
*Карый алмыйм иске шул тапка...*
*Немец теле бигрәк ачы инде,*
*Ник яратсын аны сабыйлар,*
*Немец белән атышып ятсын да ди*
*Әллә кайда әти, абыйлар..* [8, б. 203].

Бу шигырь «әткәм немец белән сугышып кайткан, әнкәм немец теле өйрәткән» дигән соңгы юллар белән тәмамлана. Шагыйрь әнә шул парадоксаль кисешү аша дөньяның бер генә катлы, гади генә хакыйкатьләрдән үрелмәвен, аның төеннәре гаять чияләнгән булуын ассызыклый. Ул бу шигыре белән безне – яңа буыннарны – искиткеч сак, уяу булырга да өнди.

Тагын бер шигыре – «Сугыш беткән елны» – инде давыл узып киткәннән соңгы дөньяны яшәү тантанасы биләп алганлыгы турында сөйли, кешелекнең һәрчак яңарырга, яшәргә, дәвам калдырырга омтылуына ишарә итә. Лирик каһарман биредә фронтовик ир-егетнең яңа, инде тыныч, имин дөньяга туган баласын бала туу йортыннан алырга килгәнен сурәтли. Тантана, билгеле, әмма дә ләкин бу идиллиянең идиллия генә булмавына ишарә иткән детальләр бар, шагыйрь безгә аларны сызып-сызып күрсәтә, һәм бу детальләр, чыннан да, йөрәкне дә сыздырып төшә:

*Кырык эшен кырга куеп торып,*
*Әти килгән мине алмага.*
*Тотып кайткан сыңар кулы белән, –*
*Ике куллап коча алмаган...*
*Бәйрәм ашы, бәбәй ашы пешереп,*
*Авылдашлар көтеп торганнар.*
*Бик кадерле булдык микән әллә*
*Сугыш беткән елны туганнар?* [9, б. 42].

Бу афәт бетте дә онытылды, инде заманалар үзгәрде дигән тынычлану юк Лена Шагыйрьҗанның лирик каһарманында. Аның дөньяны тоемлавы – гел хәвеф ноктасыннан. Ил-дәвер зилзиләсе гел аның йөрәге аша уза. Тора-бара бу тоемлау галәми масштабка – Тарихи Барышны күзаллауга алып чыга. Локаль конфликтлар һәм яңа заман сугышлары чынбарлыгын күз уңында тотып, 80 нче елларда язган кайбер шигъри текстларында ул үзләреннән соңгы буынны янә бер мәртәбә кисәтә. Аның иҗатына «иске шинель» образы килеп керә, бу күпмәгънәле образ укучыга гаять көчле тәэсир итә. Ул шагыйрь иҗатында күп мәртәбәләр сискәндергән «онытырга хакыбыз юк» дигән искә төшерү функциясен башкара. Бу образ аша автор янә бер кабат «фаҗига янәшәдә генә йөри һәм ул фаҗиганең тукталыр ноктасы, чиге-азагы юк» дип чаң кага. Ишетәбезме икән без аны?

*Иске шинель чөйдә, безнең өйдә.*
*Берсе иске, тетелеп беткән,*
*бик күптәнге.*
*Һичкем кими аны, гүя тып-тын гына*
*Сөйләп тора үзенең данлы юл үткәнен.*
*Сугыш исе сеңеп калган бу шинельгә,*
*Дару катыш дары исе, төтен исе.*
*Китергәнгә җиңү язын безнең илгә,*
*Тотабыз без аны тарих төсе итеп.*
*Икенчесе – инә-җептән чыккан, яңа,*
*Күрше егете армиядән кайтты ялга.*
*Күрешергә кергән менә безнең янга.*
*Иске шинель чөйдә, безнең өйдә.*
*Берсе тузган, зур юл узган,*
*берсе – яңа...*
*Утны-суны кичеп кайткан карт шинельнең*
*Әйтәсе бер изге сүзе бар күк аңа...* [8, б. 203].

«Шинель» образы икенче бер шигырьдә дә кулланыла. Анда инде шагыйрь турыдан-туры гомумиләштерү ясый: «ир-егет шинель кисә, димәк, яшь киленчәк йә кыз бала ак күлмәген сала». Шушы гомумиләштерү аша шагыйрьнең лирик каһарманы тулы бер буын исеменнән генә түгел, ә үзенә кадәрге һәм үзеннән соң киләсе барлык хатын-кызлар исеменнән дә сөйләргә керешә. Бу хокукны аңа гомумафәт һәм гомумхәсрәт бирә. Автор үзе балачактан иҗатларын белеп-укып, хөрмәт итеп үскән Җәлил тудырган Тугзак Аналар архетипын «киеп» ала, шул архетипка бөтен милләт кызлары язмышы тәңгәл икәнен безгә ачып сөйли, иңри.

Ә инде тора-бара бу лирик каһарман Ватанына да, аның белән булган хәлләргә дә гомумән кош очар биеклектән, үзе хәтер булып төйнәлгән ноктадан карау масштабына чыга. Башта ул әле ярты гасыр эчендә сугыш яралары йомылып барган илен карап, күзәтеп йөри: данлы герой-шәһәрләрне урап чыга, блокада эзе калган Ленинград – Санкт-Петербургны йөрәге аша уздыра, Мамай курганының тын гына пышылдап яткан истәлеген тыңлап, җанына сеңдереп тора. Җир-Ана, әйтерсең, аның аша үз сүзен әйтә – сөйләшә, серләшә.

Шагыйрьнең лирик каһарманы һаман да шул ук, уяу: ул сугыш өрәгенең бер гасыр дәвамында каңгырап йөргәнен йөрәге белән ишетеп тора, Ватан-Ананың күзләрендәге сагышны да, сискәнүне дә күрә, бу хәлләрнең кая таба барганын ачыкларга тырыша:

*Идел буйлап илне карап йөрдем,*
*Иелеп суын эчтем Иделнең.*
*Үпкән кебек булдым күмелеп барган*
*Яраларын газиз илемнең* [7, 140 б.].

Гомумиләштерүнең иң кульминацион ноктасы «Мин – Тынычлык» дигән шигырендә. Биредә без инде авторның үз лирик каһарманын җир шары өчен җаваплы галәми яссылыкка күтәргәнен күрәбез. Бу лирик каһарман илләр, дәүләтләр, мәмләкәтләр исеменнән генә дә түгел, юк, ул укучысына Хәтер һәм Вакыт исеменнән мөрәҗәгать итә. Иң мөһиме: өлкәннәргә түгел, ә яңа дәвер балаларына эндәшә, чөнки бөтен өмет – киләчәк буыннарда. Алар – бу балалар – җир шарын гөл итәрләрме, әллә кабат көлгә әверелдерерләрме?

Әнә шул уй борчый шагыйрьне, әнә шул сызлану тынгы бирми аның җанына:

*Дөньяда бер генә авыл да, шәһәр дә*
*«Сугыш» дип атамас урамын...*
*Җирдә бит миллион-миллион кешеләр*
*Тынычлык телендә аңлашып яшиләр.*
*Ә сугыш – телсез ул,*
*Теле юк сөйләрлек...*
*Бар эше – кан кою,*
*Җимерү өйләрне...*
*Дуслашыйк, балалар!*
*Мин булам – Тынычлык.*
*Мин – мәңге Җирнеке,*
*Иманым корыч, нык!* [7, б. 139].

Лена Шагыйрьҗан иҗатында – поэзиясендә дә, публицистикасында да – сугыш һәм Ватан темасы иң үзәк өзгеч темаларга – Кешелек һәм Галәм язмышы темасына алып чыга. 90 нчы еллар азагы – нуленче елларда тудырган күләмле поэмаларында аның лирик каһарманы инде күзәтүче, диагноз куючы позициясендә генә торып калмый, ә күрәзәче-визионер рәвешен дә ала. Ул халыкара аренада барган канны өшеткеч вакыйгаларның асылын аңларга, бу афәтне туктатыр өчен, нинди ялгышларны төзәтергә кирәк икәнен ваемларга чакыра.

*«Сугышларның чыганак-сәбәпләре төрле, һәм аларны ачыклау бу афәтне булдырмый калу юлларын табарга да мөмкинлек бирер иде. Сугышны котылгысыз дип санау дөрес түгел дип укыганым бар. Минемчә, иң мөһиме – сугышка каршы көрәшүче куәтле иҗтимагый һәм сәяси көчләрне берләштерү. Бары тик империалистлар һәм колонизаторларның гына, башка халыкларны азат итү пәрдәсе астында яисә турыдан-туры милли өстенлеккә дәгъва кылып, сугышлар оештырганы инде дөньяга мәгълүм. Шулай ук бөтен планетага баш булырга омтылучы державаларның да бу өлкәдә тәҗрибәләре байтак икәнен күреп, ишетеп торабыз...»* [7, б. 262].

Әнә шундый гомуми «рецепт» та тәкъдим итә иҗатының соңгы елларында Лена Шагыйрьҗан килер буыннарга. Кешелекнең шагыйрь сүзен ишетер, ваемлар бер көне җитәр, диеп ышанасы килә.

**Әдәбият**


1. Заһидуллина Д.Ф. Бөек ватан сугышы чоры прозасында «окоп хакыйкате» // «Гасырлар авазы – Эхо веков», №1, 2025. Б. 20–31.
2. Вәлиев Р.И. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, җырлар: 4 китапта. 1 том. Казан: Милли китап, 1999. 568 б.
3. Курбатов Х.Р. Җанга якын шигырьләр // Ватаным Татарстан. 1993. 24 сент.
4. Вәли-Барҗылы М.Х. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. №8. Б. 150.
5. Рахмани Р.Ф. Шагыйрәнең язмыш келәме / Хәзерге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 234–246.
6. Вәлиуллин И.Р. Һәр шагыйрь – бер дәрья...: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Б. 94–113.
7. Шагыйрьҗан Л.Г. Күңелемнең хөр кошлары: шигырьләр, поэма, публицистик язмалар, мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 383 б.
8. Шагыйрьҗан Л.Г. Шигырьләр, поэма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 203 б.
9. Шагыйрьҗан Л.Г. Җылы кирәк моңга да: шигырьләр, поэмалар, багышлаулар. Казан: Рухият, 2020. 544 б.
10. Шагыйрьҗан Л.Г. Канатлы ат: шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 39 б.

Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-174-179

# REVIEW OF THE COLLECTION OF WORKS "JOURNALISM BORN IN FLAMES" BY ALFIA SHAMOVA (KAZAN: TATAR KITAP NASHRIYATY, 2022, 247 P.)

**Golnara Fandasovna Zhamaletdinova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Nuriya Usmanovna Khaliullina,**
Bashkir State Pedagogical University n.a. M. Akmulla,
3-a Oktyabrskoj revoljucii Str., Ufa, 450077, Russian Federation,
nurkha@yandex.ru.

The article reviews the collection of works "Journalism Born in Flames (Ut echende tugan matbugat)", compiled by Alfiya Shamova. In this book, based on archival documents, the author provides an overview of the multifaceted work done by Tatar correspondent writers who brought the harsh truth about the events in the fronts of the Great Patriotic War to the entire Soviet people. The articles have supplementary illustrative material, which complements the work, providing an opportunity to get acquainted with front-line newspapers and front-line correspondents.

**Key words**: Tatar literature, Tatar writers, Great Patriotic War, Tatar military press

**For citation:** Zhamaletdinova, G., Khaliullina, N. Review of the collection of works "Journalism born in flames" by Alfia Shamova (Kazan: Tatar kitap nashriyaty, 2022, 247 p.) // Tatarica. 2025. № 2 (25). pp. 174–179. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-174-179

In the book "Journalism Born in Flames" ("Ut echende tugan matbugat"), Alfiya Shamova makes a wonderful review of the frontline newspapers published in the Tatar language. The collection includes poems, letters, and excerpts taken from the articles of Tatar writers and journalists. These sources cover the activities of Tatar frontline newspapers, and clearly show how our famous writers, living in the trenches, fought for the liberation of the Soviet country from Nazi fascists.

The collection is dedicated to the memory of the outstanding Tatar writer Afzal Shamov (1901–1990). The military commander Afzal Shamov was the only Tatar writer who went through three wars:

the Civil War, the Great Patriotic War and the Soviet-Japanese War. He went to all the three wars of his own volition. The writer captured seven fascists on June 30, 1944 during the operation "Bagration" in Belarus. For three years and six months Afzal Shamov contributed articles to frontline and military newspapers "The Forward to Defeat the Enemy!" and "The Suvorov Onslaught" (1943–1946).

On October 23–24, as part of the State Program "Implementation of State National Policy in the Republic of Tatarstan", the International Scientific and Practical Conference "National Literatures of the Volga Republics: Problems of Intercultural Communication" was held jointly with the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan at the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University. Leading specialists from research organizations and universities in the Russian Federation, as well as international scholars, participated in the conference. The program of the Research Conference included a plenary session, as well as five sections where current issues of literary comparative studies and literary translation were discussed, reports were made on the development features and current state of Turkic and Finno-Ugric literatures of the Volga Region, etc. (for more details see: https://ifmk.kpfu.ru/news/mezhdunarodnaya-nauchno-prakticheskaya-konferencziya-naczionalnye-literatury-respublik-povolzhya-problemy-mezhkulturnoj-kommunikaczii-2/).

---

On October 28, the Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences held a roundtable discussion dedicated to the centenary of Zemyal Ibragimovich Gil'manov, the founder of the school for the study of the history of the Great Patriotic War in Tatarstan. (for more details see: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1375?ysclid=mib5s9rcim585878714).

---

On November 4–5, the International Research Conference "Science in the Golden Horde" was held in Istanbul, Turkey. The conference brought together leading experts in the history of the Ulus of Jochi from research centers in Turkey, Russia, and Kazakhstan. The participants discussed the formation of scientific traditions in the state of the Ulus of Jochi, the role of Islamic education, the interaction of cultures, the development of cities, and writing. (for more details see: https://e-history.kz/ru/news/show/50000853?ysclid=mib67plq5x318065221).

---

On November 11, the All-Russian Research and Practice Conference "Qayum Nasyri and His Era" was held at the Sh. Marjani Institute of History, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. Scholars from Moscow, Kazakhstan, Makhachkala, Ufa, Astrakhan, Yoshkar-Ola, Chelyabinsk, Samara, Orenburg, and Kazan participated in the conference. The key issues discussed included the life and work of Qayum Nasyri, the 19th-century Enlightenment, publishing activities in the late 19th and early 20th centuries, the historical legacy of the Tatar people, the daily life of the peoples from the Ural-Volga region, and the development of national languages. (for more details see: https://tataroved.tatarstan.ru/index.htm/news/2468620.htm).

---

On November 13–14, the 2nd International Research and Practice Conference "Cultural Cooperation with the Countries of the East and Asia: Current Status and Development Prospects" was held in Kazan as part of the Russia-East International Festival of National Cultures (the "Eastern Bazaar in Kazan"). More than 200 representatives of the scientific community, including philologists, historians, art historians, university professors, and graduate students, participated in the conference. The Russian participants represented research centers located from Moscow and St. Petersburg to Buryatia and Yakutia. Across nine thematic sections, participants discussed a wide range of topics, from the study of archaeological collections and traditional costumes to the role of theater, cinema, and modern media in cultural dialogue. Of particular interest were the studies devoted to the historical and cultural heritage of the peoples from the East and Russia, as well as the challenges of preserving traditions in the context of globalization. (for more details see: https://www.antat.ru/ru/iyli/news/20051/).

---

On November 13, as part of the 2nd International Research and Practice Conference "Cultural Cooperation with Countries of the East and Asia: Current Status and Development Prospects", a roundtable discussion was held on the topic of "Book Publishing and Periodicals in the Languages of the Peoples of Russia: Historical Experience and Contemporary Challenges" (for more details see: http://antat.tatar/ru/iyli/news/20051/).

---

On November 17-18, the 22nd All-Russian Research and Practice Conference "Faizkhanov Readings" was held in St. Petersburg. The conference was timed to coincide with the 200th anniversary of the outstanding educator Kayum Nasyri, the 150th anniversary of the world-renowned religious philosopher Musa Jarullakh Bigiev, and the 100th anniversary of the historian of Tatar books, Doctor of Philology Abrar Gibadullovich Karimullin. The participants of the Conference were leading Islamic scholars, historians, theologians, art historians, religious figures, and young researchers studying various aspects of the historical and cultural heritage of Islam in Russia. (for more details see: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1396).

---

On November 20, the Y. E. Emelianov Cultural Center, the Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences and the Public Organization of the Kryashens of the Republic of Tatarstan hosted the 3rd All-Russian Forum of Kryashen Local Historians "Yru Agachy" ("The Family Tree"), dedicated to the Year of Defender of the Fatherland in the Republic of Tatarstan and the Russian Federation (organizer and moderator: L. A. Mukhamadeeva, a Ph.D. in History). The forum was attended

by scholars and local historians from Moscow, St. Petersburg, Kazan, the Republic of Bashkortostan (Ufa, Bakaly), the Chelyabinsk Oblast (the Nagaybak Municipal District), and cities and districts of the Republic of Tatarstan. The following issues were discussed at the forum: war in the history of my family; heroes among us: memoirs of front-line soldiers; Kryashen genealogies; methodological, source studies and historiographic problems of studying Kryashen villages and hamlets; the preparation and publication of books on the history of Kryashen villages; the study of traditional culture and folklore of the Kryashens; cultural and everyday characteristics of the Tatars and Kryashens' ethnoterritorial groups; rural folklore ensembles: past, present and development prospects; the spiritual life of Kryashen rural settlements:their past and present; local history museums – "strongholds" for the preservation of the historical and cultural heritage of the Kryashens. (for more details see: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1398).

---

On November 21, the All-Russian Research and Practice Conference "Thousand-Year-Old Kazan" was held, dedicated to the 1020th anniversary of the City Foundation Day. The Mansur Khasanov Institute of Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Tatarstan Academy of Sciences initiated the research conference in Kazan's anniversary year. The representatives of the scientific community exchanged best practices and discussed new approaches to studying the millennial history of Kazan and other ancient cities, as well as methodologies for compiling specialized encyclopedias on urban agglomerations and megacities. The participants were leading scientists, historians, cultural scholars, economists, and encyclopedists from Moscow, St. Petersburg, Yoshkar-Ola, Saransk, Ulyanovsk, Ufa, Cheboksary, and other scientific centers. (for more details see: https://gossov.tatarstan.ru/index.htm/news/4279.htm).

---

On December 11-12, 2025, the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University hosted the International Research and Practice Conference "Tatar Linguistics in the Context of Eurasian Humanities", dedicated to the 200th anniversary of Kayum Nasyri's birth. The conference aimed to study and disseminate the multifaceted scientific, methodological, and creative legacy of the educator Kayum Nasyri, and to discuss a wide range of issues and areas of modern Tatar linguistics, pioneered by Kayum Nasyri. (for more details see: https://ifmk.kpfu.ru/).

*The information was submitted by G. A. Nabiullina, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University.*

# 2025 ЕЛНЫҢ II ЯРТЫСЫНДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

2025 елның 9-11 июнь көннәрендә Болгар һәм Казан шәһәрләрендә Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Болгар Ислам академиясе оештырган «Pax Tatarica: урта гасыр чыганаклары һәм тарихи контекст» дип аталган VIII Халыкара Алтын Урда форумы үтте. Форумда 16 илдән 151 галим катнашып, Алтын Урда тарихын өйрәнүнең хәзерге фәндәге әһәмияте һәм актуальлеге ачык рәвештә күрсәтелде.

Форум кысаларында Алтын Урда тарихы буенча I Халыкара җәйге мәктәп оештырылды. Мәктәпкә фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүче Россия Федерациясенең 32 төп фәнни үзәгеннән (Казан, Самара, Саратов, Уфа, Чабаксар, Воронеж, Санкт-Петербург), шулай ук Төркия һәм Казахстаннан студентлар, магистрантлар, аспирантлар катнашты. VIII Халыкара Алтын Урда Форумы программасы кысаларында Россия-Казахстан фәнни-сәяси хезмәттәшлегендә стратегик әһәмияткә ия булган ике дәүләт тарихчыларының фәнни-консультатив төркеменең Казанда беренче очрашуы узды. Бу чарада югары уку йортлары һәм фәнни үзәкләр, башкарма һәм закон чыгару хакимияте, шулай ук дипломатик хезмәт вәкилләре катнашты. (тулырак: http://татаровед.рф/news/1295?ysclid =miczus6xh9776479415).

---

2025 нче елның 1-5 нче июлендә Байкалда Доржи Банзаров исемендәге Бурят дәүләт университетының «Байкал» базасында «Трансчикләрнең этномәдәният-тел киңлеге: тарих һәм хәзерге заман» I Халыкара җәйге лингвистик мәктәбе узды (ЛЛШ 2025).

ЛЛШ 2025 тематикасы дөньяны заманча үзгәртеп кору шартларында Көнчыгыш трансчик буендагы заманча филологик тикшеренүләргә кагылышлы мәсьәләләрнең киң даирәсен колачлады. Җәйге мәктәп кысаларында үткәрелгән дәресләр төрле форматта узды: лекцияләр уку, практикумнар, тренинглар һәм мастер-класслар үткәрү, түгәрәк өстәлләр һәм тематик дискуссияләр оештыру.

Җәйге мәктәп вакытында биш түгәрәк өстәл үткәрелде: «Трансчик киңлегендә рус дөньясы: тел һәм этномәдәни үзара бәйләнеш стратегияләре», «Тарихи-лингвистик яктыртуда монгол телләре», «Себернең төрки-монгол тел ареаллары: синтаксис», «Төрки-монгол тел бәйләнешләры», «Төрки телләрнең төрле структуралы телләр белән үзара бәйләнеше». Шулай ук фонетик-фонологик секция нәтиҗәле эшләде.

Җәйге мәктәп заманча алымнар һәм методикалар нигезендә трансчик буе этномәдәни тел киңлегенең төрле аспектларын тикшерүдә аеруча актуаль проблемаларны хәл итүдә фикер алышу һәм тәҗрибә уртаклашу өчен, менә дигән мәйданчыкка әверелде. (тулырак: https://iling-ran.ru/web/ru/news/250725_sls).

---

3-5 нче июль көннәрендә Чиләбе өлкәсендә бөек мәгърифәтче Зәйнулла Рәсүлев истәлегенә багышланган чаралар узды. Форумның төп темасы – «Ватанны саклауда һәм нацизмга каршы көрәштә традицион конфессияләрнең бердәмлеге».

Конференция барышында түбәндәге тематик секцияләр эшләде: «Милләт бердәмлеген ныгыту һәм РФ халыкларының этномәдәни үсеше», «Тарихи ретроспективада Европа һәм Азия арасында ислам һәм христианлык», «Зәйнулла Рәсүлев. Чоры һәм мирасы», «Ватанны саклаучының рухи-әхлакый үсешендә конфессияләрнең әһәмияте», «Хәзерге хәрби шартларда полк имамнары һәм руханиларның роле». (тулырак: https://cdum.ru/news/44/12231/).

---

Болгарда 12-25 нче август көннәрендә XII Болгар халыкара археология мәктәбе узды. Чара ТР Фәннәр академиясенең А. Халиков исемендәге археология институты, Болгар музей-тыюлыгы һәм Халыкара Үзәк Азия тикшеренүләре институты (Сәмәрканд шәһәре, Үзбәкстан Республикасы) тарафыннан «Ватан тарихы» фонды ярдәмендә оештырылды. Оештыручылар хәбәр иткәнчә, быел мәктәп программасы археологик артефактларны реставрацияләү һәм консервацияләүнең заманча технологияләренә багышланган.

Чара кысаларында секцион дәресләр һәм гомуми лекцияләр, 24 августта «Археологиядә дисциплинаара тикшеренүләр: казанышлар һәм чакырулар» халыкара яшьләр фәнни-гамәли конференциясе узды. (тулырак: https://www.antat.ru/ru/iar/news/19720/).

---

26-28 нче август көннәрендә Казан шәһәрендә татар халкының 1000гә якын вәкилен берләштергән «Милләт Җыены» булып узды. Бу зур күләмле җыен кысаларында берничә мөһим форум оештырылды: VII Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы, IX Бөтендөнья татар яшьләре форумы һәм Бөтенроссия туган як тарихын өйрәнүчеләр җыелышы.

Чарада Россиянең 68 төбәгеннән һәм дөньяның 27 иленнән 1000нән артык татар активы вәкиле катнашты. Милли җыен Бөтендөнья татар конгрессының ике корылтае арасында көнүзәк агымдагы мәсьәләләрне хәл итү һәм хәзерге заман шартларында татар милләте үсешенең хәлиткеч юнәлешләрен билгеләү максатында үткәрелде. Форум тәҗрибә уртаклашу һәм бөтен дөньядагы татар оешмалары арасында элемтәләрне ныгыту өчен, яхшы мәйданчык булды. (тулырак: https://dumdnr.ru/novosti/v-kazani-proshyol-millet-zhyeny).

---

11 нче сентябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Россия империясенең иррегуляр формалашу составындагы татарлар» Бөтенроссия фәнни конференциясе узды. Конференция Ватанны саклаучылар елы һәм «Татарлар Ватанга хезмәттә» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелде.

Конференциядә Мәскәү, Уфа, Самара, Тольятти, Казан, Әлмәт, Яр Чаллыдан һәм Татарстан Республикасы авылларыннан туган якны өйрәнүчеләр, укытучылар, Россия галимнәре һ.б. катнашты. Конференция барышында иррегуляр формалашу составындагы татар династияләре; иррегуляр формалашу составындагы татарларның хәрби хезмәте; Урал буе казак гаскәрләре составында мишәр татарлары һәм башка сораулар каралды. (тулырак: https://www.antat.ru/ru/iyli/news/19801/).

---

2025 нче елның 15-18 нче сентябрендә Алтай Республикасында «Алтай – төркиләрнең ата-бабасы. Төрки цивилизациянең барлыкка килү чыганакларына карата» дип аталган Халыкара фәнни конференция узды. Чара Россия тарихы фәненең, гомумән, гуманитар дисциплиналар комплексының Россия цивилизациясенең Евразия чыганакларына фундаменталь борылыш башлангычы булып тора.

Форум Россия хәрби-тарихи җәмгыяте, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты һәм илебезнең башка абруйлы фәнни-агарту оешмалары эгидасында узды. (тулырак: https://m.business-gazeta.ru/article/683943).

---

25-26 нчы сентябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Россия һәм дөнья халыкларының экстремаль көндәлегендә хатын-кызлар һәм ирләр» Халыкара фәнни конференциясе узды. Чара Бөек Җиңүнең 80 еллыгына һәм Ватанны саклаучылар елына багышланды.

Конференция Россия хатын-кызлар тарихын тикшерүчеләр ассоциациясе (РАИЖИ), РФА Этнология һәм антропология институты һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан оештырылды. Фәнни форум хатын-кызларның көндәлек антропологиясен һәм хатын-кызлар тарихын тикшерүчеләрне берләштерде һәм 18 нче тапкыр уздырылды.

Конференция 15 фәнни юнәлеш буенча ике көн дәвамында эшләде. Бөек Ватан сугышын, Беренче бөтендөнья сугышын һәм башка чорлардагы тарихи вакыйгаларны, хатын-кызларның хәзерге хәлен өйрәнүгә аерым игътибар бирелде. Шулай ук сугыш елларында хатын-кызларның хезмәт көндәлеге, демография һәм гаилә, борылыш чорларында хатын-кызларның сәламәтлеге, хатын-кыз галимнәр эшчәнлеге, гаилә истәлекләре һәм башка актуаль темаларга багышланган

секцияләр узды. (тулырак: https://www.tatar-inform.ru/news/naucnaya-konferenciya-v-kazani-issleduet-zizn-zenshhin-i-muzcin-v-krizisnye-periody-6000657?ysclid=mhbw8llup373544656).

---

25-26 нчы сентябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясендә «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл» дигән Халыкара фәнни-гамәли семинар узды.

Семинарда Россия, Төркия, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казахстан, Азербәйҗан һәм башка илләрдән 70 тән артык галим катнашты. Әлеге дискуссия платформасы татар телен, әдәбиятын, сәнгатен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүчеләр арасында актуаль теоретик-методологик проблемаларны һәм татар фәнен үстерү перспективаларын тикшерү урынына әверелде.

Семинарның эш юнәлешләре: XX–XXI гасырларда татарны өйрәнү һәм тюркология: үсеш юнәлешләре, традицияләр һәм яңарышлар; татар теле, әдәбияты, тарихы, этнографиясе, сәнгате һәм мәдәнияте буенча тикшеренүләрдә яңа юнәлешләр һәм методлар; трансмилли контекстларда милли диаспоралар; гуманитар фәннәрдә чагыштырма методология перспективалары; Урал-Идел буе халыкларының телләре, әдәбиятлары һәм мәдәниятләре үзара бәйләнешләре. (тулырак: https://www.antat.ru/ru/news/19844/).

---

10-24 октябрьдә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Казан лингвистик мәктәбенә нигез салучы И.А. Бодуэн де Куртенэның 180 еллыгына, Казан университетында эшли башлауга 150 ел тулуга, КФУның Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбенең 190 еллыгына багышланган VI Казан халыкара лингвистик саммиты узды.

Саммитны КФУ белән беррәттән Россия Фәннәр Академиясенең Тел белеме институты һәм Лингвистик тикшеренүләр институты, Россия мәгариф академиясе оештырды. Саммит партнерлары буларак Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Мәгарифне үстерү стратегиясе институты, Россия Федерациясе халыкларының туган телләре федераль институты, Россия рус теле һәм әдәбияты укытучылары җәмгыяте (РОПРЯЛ), Халыкара рус теле һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе (МАПРЯЛ), Россия Федерациясе рус теле һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе (АССУЛ), Россия инглиз теле укытучыларының милли ассоциациясе (НАПАЯЗ), Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары ассоциациясе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Рус теле буенча Комиссия, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча Комиссия һ. б. катнашты. (тулырак: https://kils.kpfu.ru/ru/news/ob-itogah-vi-kazanskogo-mezhdunarodnogo-lingvisticheskogo-sammita/).

---

2025 елның 17-19 октябрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Кырым татарлары тарихының актуаль мәсьәләләре» IV Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференциядә Кырым республикасыннан, Казан, Ростов-на-Дону, Ульяновск, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән 60 тан артык катнашучы чыгыш ясады. (тулырак: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1369).

---

20-22 нче октябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган «Лингвистика фәнен үстерүнең заманча тенденцияләре: тикшеренүләр проблематикасы һәм методологиясе» дигән Халыкара фәнни симпозиум узды. Зур фәнни форум Россия, Казахстан, Үзбәкстан һәм Беларусь белгечләрен берләштерде.

Симпозиум өч көн дәвам итте. Аның кысаларында лингвистик эзләнүләр өлкәсендәге заманча тенденцияләргә һәм сынауларга багышланган «Хәзерге фәнни тикшеренүләр яктылыгында тел белеменең актуаль проблемалары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе, фонетика, диалектология һәм ареаль лингвистика мәсьәләләре буенча «Идиомнарның авазлар төзелешен тикшеренүнең хәзерге методлары» халыкара семинары, «Татар гыйлеме» Халыкара яшьләр фәнни мәктәбе эшләде, аның мәйданчыгында «Идел һәм Урал буе халыкларының традицион мәдәнияте: заманча тикшеренү стратегияләре» түгәрәк өстәле уздырылды. Түгәрәк өстәл эше нәтиҗәләре буенча Россия фәнни үзәкләре вәкилләре тарафыннан Идел һәм Урал буендагы этникара бәйләнешларны өйрәнүгә юнәлдерелгән уртак тикшеренү программасы булдыру инициативасы хупланды. Программаны гамәлгә ашыру даими эш төркеме төзүне, экспедиция эшчәнлеген оештыруны, фәнни кадрлар әзерләүне көчәйтүне күздә тота. (тулырак: https://www.antat.ru/ru/iyli/).

---

23-24 нче октябрьдә «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы кысаларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында «Идел буе республикаларының милли әдәбиятлары: мәдәниятара багланышлар проблемалары» халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды.

Конференция эшендә Россия Федерациясенең фәнни оешмаларыннан һәм югары уку йортларыннан әйдәп баручы белгечләр, чит ил галимнәре катнашты. Фәнни конференция программасы буенча пленар утырыш, 5 секция үткәрелде. Аларда әдәби компаративистиканың актуаль мәсьәләләре, әдәби тәрҗемә мәсьәләләре каралды, Идел буе төрки һәм фин-угор әдәбиятларының үсеш үзенчәлекләре һәм хәзерге торышы турында докладлар тыңланды. (тулырак: https://ifmk.kpfu.ru/news/mezhdunarodnaya-nauchno-prakticheskaya-konferencziya-naczionalnye-literatury-respublik-povolzhya-problemy-mezhkulturnoj-kommunikaczii-2/).

---

28 нче октябрь көнне Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Татарстанда Бөек Ватан сугышы тарихын өйрәнү мәктәбенә нигез салучы Җәмил Ибраһим улы Гыйльмановның йөз еллыгына багышланган түгәрәк өстәл узды. (тулырак: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1375?ysclid=mib5s9rcim585878714).

---

4-5 нче ноябрь көннәрендә Истанбул шәһәрендә (Төркия) «Алтын Урдада фән» дип аталган Халыкара фәнни конференция булып узды. Конференция Төркиядә, Россиядә һәм Казахстанда Җучи Улусы тарихы өйрәнү буенча фәнни үзәкләрнең әйдәп баручы белгечләрен берләштерде. Форумда катнашучылар Җучи Улусы дәүләтендә фәнни традицияләр формалашу, ислам мәгарифенең роле, мәдәниятләрнең үзара бәйләнеше, шәһәрләрнең һәм язу тарихының үсеше турында фикер алыштылар. (тулырак: https://e-history.kz/ru/news/show/50000853?ysclid=mib67plq5x318065221).

---

11 нче ноябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Каюм Насыйри һәм аның чоры» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция эшендә Мәскәү, Казахстан, Махачкала, Уфа, Әстерхан, Йошкар-Ола, Чиләбе, Самара, Оренбург һәм Казан галимнәре катнашты. Фикер алышуга чыгарылган төп мәсьәләләр – Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты, XIX гасыр мәгърифәтчелек мәсьәләләре, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы нәшрият эшчәнлеге, татар халкының тарихи мирасы, Урал-Идел буе халыкларының көндәлек тормышы, шулай ук милли телләрнең үсеше. (тулырак: https://tataroved.tatarstan.ru/index.htm/news/2468620.htm).

---

13-14 нче ноябрьдә Казанда «Россия-Көнчыгыш» («Казанда шәрык базары») Халыкара милли мәдәниятләр фестивале кысаларында «Көнчыгыш һәм Азия илләре белән мәдәни хезмәттәшлек: хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция эшендә фәнни җәмәгатьчелекнең 200дән артык вәкиле – филологлар, тарихчылар, сәнгать белгечләре, югары уку йортлары укытучылары һәм аспирантлар катнашты. Россия катнашучылары географиясе Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан алып Бурятия һәм Якутиягә кадәр фәнни үзәкләрне колачлады.

Тугыз тематик секция кысаларында катнашучылар археологик фондларны һәм традицион костюмны өйрәнү, мәдәниятләр диалогында театр, кино һәм заманча медиа роле кебек мәсьәләләр буенча фикер алыштылар. Көнчыгыш һәм Россия халыкларының тарихи-мәдәни мирасын тикшерү, шулай ук глобальләшү шартларында традицияләрне саклау проблемалары аеруча кызыксыну уятты. (тулырак: https://www.antat.ru/ru/iyli/news/20051/).

---

13 нче ноябрьдә «Көнчыгыш һәм Азия илләре белән мәдәни хезмәттәшлек: хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе кысаларында «Россия халыклары телләрендә китап нәшер итү һәм вакытлы матбугат: тарихи тәҗрибә һәм заманча чакырулар» темасына түгәрәк өстәл узды.(тулырак: http://antat.tatar/ru/iyli/news/20051/).

---

17-18 нче ноябрьдә Санкт-Петербургта күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга, дөньякүләм танылган дин фәлсәфәчесе Муса Җәруллаһ Бигиевнең тууына 150 ел тулуга, шулай ук татар китабы тарихчысы, филология фәннәре докторы Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллинның тууына 100 ел тулуга багышланган «Фәйзхан укулары» XXII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция эшендә әйдәп баручы Ислам галимнәре, тарихчылар, теологлар, сәнгать белгечләре, дин әһелләре, шулай ук Россиядә исламның тарихи-мәдәни мирасын төрле аспектларда өйрәнү белән шөгыльләнүче яшь тикшеренүчеләр катнашты. (тулырак: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1396)

---

20 нче ноябрьдә Я.Е. Емельянов исемендәге Мәдәният үзәгендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм ТР керәшеннәр иҗтимагый оешмасы белән берлектә Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә Ватанны саклаучылар елына багышланган «Ыру агачы» III Бөтенроссия туган якны өйрәнүче керәшеннәрнең форумы узды.

Форумда Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан шәһәрләреннән, Башкортостан Республикасы (Уфа шәһәре, Бакалы авылы), Чиләбе өлкәсе (Нагайбәк муниципаль округы), шулай ук Татарстан Республикасының шәһәр-районнарыннан галимнәр һәм туган якны өйрәнүчеләр катнашты. Форумда түбәндәге проблемалар буенча фикер алыштылар: минем гаилә тарихында сугыш; безнең арада геройлар: фронтовикларның истәлекләре; керәшен шәҗәрәләре; керәшен авылларын өйрәнүнең методологик, чыганак һәм тарих проблемалары; керәшен авыллары тарихы буенча китаплар әзерләү һәм бастырып чыгару мәсьәләләре; керәшеннәрнең традицион мәдәниятен һәм фольклорын өйрәнү; татарлар һәм керәшеннәрнең этнотерриториаль төркемнәренең мәдәни һәм көнкүреш үзенчәлекләре; авыл фольклор ансамбльләре: үткәне һәм хәзергесе, үсеш перспективалары; керәшен авылларының рухи тормышы: тарихы һәм бүгенгесе; туган якны өйрәнү музейлары - керәшеннәрнең тарихи-мәдәни мирасын саклау «таянычы». (тулырак: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1398).

---

21 нче ноябрьдә Казанда, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясендә шәһәр нигезләнүгә 1020 ел тулуга багышланган «Мәңьеллык Казан» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Казан өчен юбилей елында фәнни конференция үткәрү инициативасы белән ТР Фәннәр

Академиясенең Мансур Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты чыккан иде.

Фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре алдынгы тәҗрибә белән уртаклаштылар, Казанның һәм башка борынгы шәһәрләрнең меңьеллык тарихына бәйле мәсьәләләрне өйрәнүнең яңа алымнары, шулай ук шәһәр агломерацияләре һәм мегаполислары турында тармак энциклопедияләре төзү методологияләре турында фикер алыштылар. Форумда Мәскәү, Санкт-Петербург, Йошкар-Ола, Саранск, Ульяновск, Уфа, Чабаксар һәм башка фәнни үзәкләрнең әйдәп баручы галимнәре, тарихчылары, культурологлары, икътисадчылары һәм энциклопедистлары катнашты. (тулырак: https://gossov.tatarstan.ru/index.htm/news/4279.htm).

---

2025 нче елның 11-12 нче декабрендә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган «Евразия гуманитар фәне контекстында татар тел белеме» халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференциянең максаты - мәгърифәтче Каюм Насыйриның күпкырлы фәнни-методик һәм иҗади мирасын өйрәнү һәм тарату; Каюм Насыйри чыганакларында булган хәзерге татар тел белеменең проблемалары, юнәлешләре турында фикер алышу. (тулырак: https://ifmk.kpfu.ru/).

*Материаллар филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты Г. Ә. Нәбиуллина тарафыннан тупланды һәм әзерләнде.*

# ПРОШЕДШИЕ СОБЫТИЯ II ПОЛОВИНЫ 2025 ГОДА

С 9 по 11 июня в Болгаре и Казани прошёл VIII Международный золотоордынский форум «PAX Tatarica: средневековые источники и исторический контекст», организованный Институтом истории им. Ш. Марджани и Болгарской исламской академией. В форуме приняли участие 151 ученый из 16 стран, что наглядно продемонстрировало значение и актуальность изучения истории Золотой Орды в современной науке. В рамках форума была организована I Международная летняя школа по истории Золотой Орды. В школе приняли участие студенты, магистранты, аспиранты из 32 ведущих научных центров Российской Федерации (Казань, Самара, Саратов, Уфа, Чебоксары, Воронеж, Санкт-Петербург), а также из Турции и Казахстана. В рамках программы VIII Международного золотоордынского форума в Казани состоялась первая встреча научно-консультативной группы историков двух государств, имеющих стратегическое значение в российско-казахстанском научно-политическом сотрудничестве. В мероприятии приняли участие представители вузов и научных центров, представители исполнительной и законодательной власти, а также дипломатической службы. (подробнее: http://татаровед.рф/news/1295?ysclid=miczus6xh9776479415).

---

1-5 июля на базе Бурятского государственного университета имени Доржи Банзарова «Байкал» состоялась I Международная летняя лингвистическая школа на Байкале «Этнокультурно-языковое пространство трансграничья: история и современность» (ЛЛШ 2025).

Тематика ЛЛШ 2025 охватила широкий круг вопросов, затрагивающих современные филологические исследования трансграничья Востока в условиях современного переустройства мира. Занятия, проведенные в рамках летней школы, прошли в разных форматах: чтение лекций, проведение практикумов, тренингов и мастер-классов, организация круглых столов и тематических дискуссий.

Во время работы летней школы состоялось пять круглых столов: «Русский мир в трансграничном пространстве: стратегии языкового и этнокультурного взаимодействия», «Монгольские языки в историко-лингвистическом освещении», «Тюркско-монгольские языковые ареалы Сибири: синтаксис», «Тюркско-монгольские языковые связи», «Взаимодействие тюркских языков с другими разноструктурными языками». Результативно отработала фонетико-фонологическая секция.

Летняя школа стала замечательной площадкой для обмена мнениями и опытом в решении наиболее актуальных проблем в исследовании различных аспектов этнокультурного языкового пространства трансграничья на основе современных подходов и методик. (подробнее: https://iling-ran.ru/web/ru/news/250725_sls).

---

С 3 по 5 июля в Челябинской области прошли мероприятия, посвященные памяти великого просветителя Зайнуллы Расулева. Главная тема форума – «Единство традиционных конфессий в защите Отечества и борьбе с нацизмом».

В ходе конференции работали тематические секции: «Укрепление единства нации и этнокультурное развитие народов РФ», «Ислам и христианство между Европой и Азией в исторической ретроспективе», «Зайнулла Расулев. Его эпоха и наследие», «Значение конфессий в духовно-нравственном становлении защитника Отечества», «Роль полковых имамов и священнослужителей в современных военных условиях». (подробнее: https://cdum.ru/news/44/ 12231/).

---

С 12 по 25 августа в Болгаре прошла XII болгарская международная археологическая школа. Мероприятие было организовано Институтом археологии им. А. Х. Халикова Академии наук Республики Татарстан, Болгарским государственным историко-архитектурным музеем-заповедником и Международным институтом центральноазиатских исследований (г. Самарканд, Республика Узбекистан) при поддержке фонда «История Отечества».

Как сообщили организаторы, в этом году школьная программа посвящена современным технологиям реставрации и консервации археологических артефактов. В рамках мероприятия прошли секционные занятия и общие лекции, 24 августа – Международная молодежная научно-практическая конференция «Междисциплинарные исследования в археологии: достижения и вызовы». (подробнее: https://www.antat.ru/ru/iar/news/19720/).

---

С 26 по 28 августа в городе Казани прошло «Милләт Җыены» – «Национальное собрание», объединившее около 1000 представителей татарского народа. В рамках этого масштабного собрания были организованы несколько важных форумов: VII Всемирный форум татарских женщин, IX Всемирный форум татарской молодежи и Всероссийское собрание татарских краеведов.

В мероприятии приняли участие более 1000 представителей татарского актива из 68 регионов России и 27 стран мира. Национальное собрание проводилось между двумя съездами Всемирного конгресса татар для решения актуальных текущих вопросов и определения судьбоносных направлений развития татарской нации в меняющихся современных условиях. Форум стал отличной площадкой для обмена опытом и укрепления связей между татарскими организациями со всего мира. (подробнее: https://dumdnr.ru/novosti/v-kazani-proshyol-millet-zhyeny).

---

11 сентября в Институте истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан состоялась Всероссийская научная конференция «Татары в составе иррегулярных формирований Российской империи». Конференция проводилась в рамках Года защитника Отечества и реализации государственной программы «Татары на службе Отечеству».

В конференции приняли участие российские ученые, краеведы, учителя из Москвы, Уфы, Самары, Тольятти, Казани, Альметьевска, Набережных Челнов, сел Республики Татарстан и др. В ходе конференции рассматривались такие вопросы, как татарские династии в составе иррегулярных формирований, военная служба татар в составе иррегулярных формирований, татары-мещеряки в составе казачьих войск Приуралья и др. (подробнее: https://www.antat.ru/ru/iyli/news/19801/).

---

15-18 сентября в Республике Алтай прошла Международная научно-практическая конференция «Алтай – прародина тюрков. К истокам зарождения тюркской цивилизации». Мероприятие знаменует собой начало фундаментального поворота российской исторической науки и всего комплекса гуманитарных дисциплин к евразийским истокам российской цивилизации.

Форум прошёл под эгидой Российского военно-исторического общества, Института востоковедения РАН и других авторитетных научных и просветительских организаций нашей страны. (подробнее: https://m.business-gazeta.ru/article/683943).

---

25-26 сентября в Институте истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан состоялась Международная научная конференция «Женщины и мужчины в экстремальной повседневности народов России и мира». Форум приурочен к 80-летию Великой Победы и Году защитника Отечества.

Конференция организована Российской ассоциацией исследователей женской истории (РАИЖИ), Институтом этнологии и антропологии РАН и Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ. Научный форум объединяет исследователей антропологии женской повседневности и истории женщин и проводится в восемнадцатый раз.

Очное участие принимают около 100 ученых из различных регионов России и стран ближнего зарубежья – Беларуси, Казахстана и Узбекистана. На пленарном заседании 25 сентября выступили исследователи из Казани, Москвы и Екатеринбурга.

Конференция работала два дня по 15 научным направлениям. Особое внимание уделяется изучению Великой Отечественной войны, Первой мировой войны и историческим событиям других эпох, а также современному положению женщин.

Также прошли секции, посвященные трудовой повседневности женщин в годы войн, демографии и семье, женскому здоровью в переломные эпохи, деятельности женщин-ученых, вопросам семейной памяти и другим актуальным темам. (подробнее: https://www.tatar-inform.ru/news/naucnaya-konferenciya-v-kazani-issleduet-zizn-zenshhin-i-muzcin-v-krizisnye-periody-6000657?ysclid=mhbw8llup373544656).

---

В 25–26 сентября в Академии наук Республики Татарстан прошел Международный научно-практический семинар «Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика».

В семинаре приняли участие более 70 ученых из России, Турции, Узбекистана, Киргизии, Казахстана, Азербайджана и других стран. Данная дискуссионная платформа стала местом обсуждения актуальных теоретико-методологических проблем и перспектив развития татароведения среди исследователей татарского языка, литературы, искусства, истории и культуры.

Направления работы семинара: татароведение и тюркология в XX–XXI вв.: направления развития, традиции и новации; новые направления и методы в исследованиях по языку, литературе, истории, этнографии, искусству и культуре татар; национальные диаспоры в транснациональных контекстах; перспективы сопоставительной методологии в гуманитарных науках; взаимосвязи языков, литератур и культур народов Урало-Поволжья. (подробнее: https://www.antat.ru/ru/news/19844/).

---

10-24 октября в Институте филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета состоялся VI Казанский международный лингвистический саммит, посвященный 180-летию основателя Казанской лингвистической школы И. А. Бодуэна де Куртенэ, 150-летию со дня начала его работы в Казанском университете, 190-летию Высшей школы русской филологии и культуры им. Льва Толстого КФУ. Соорганизаторами Саммита, наряду с КФУ, явились Институт языкознания и Институт лингвистических исследований Российской академии наук, Российская академия образования.

В качестве партнеров Саммита выступили Академия наук Республики Татарстан, Кабинет Министров Республики Татарстан, Институт стратегии развития образования, Федеральный институт родных языков народов Российской Федерации, Российское общество преподавателей русского языка и литературы (РОПРЯЛ), Международная ассоциация преподавателей русского языка и литературы (МАПРЯЛ), Ассоциация учителей русского языка и литературы Российской Федерации (АССУЛ), Национальная ассоциация преподавателей английского языка России (НАПАЯЗ), Ассоциация учителей родного (татарского) языка и литературы, Комиссия при Раисе Республики Татарстан по русскому языку, Комиссия при Раисе Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан и др. (подробнее: https://kils.kpfu.ru/ru/news/ob-itogah-vi-kazanskogo-mezhdunarodnogo-lingvisticheskogo-sammita/).

---

17-19 октября состоялась IV Всероссийская научно-практическая конференция «Актуальные вопросы истории крымских татар», посвященная 80-летию Победы в Великой Отечественной войне, организованная Институтом истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан. В конференции приняли участие более 60 участников из Республики Крым, Казани, Ростова-на-Дону, Ульяновска, Москвы и Санкт-Петербурга. (подробнее: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1369).

---

20-22 октября в Академии наук Республики Татарстан состоялся Международный научный симпозиум «Современные тенденции развития лингвистической науки: проблематика и методология исследований», организованный Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. Крупный научный форум объединил экспертное сообщество России, Казахстана, Узбекистана и Беларуси.

В рамках работы симпозиума прошли три научных мероприятия: Международная научно-практическая конференция «Актуальные проблемы языкознания в свете современных научных исследований», посвященная современным тенденциям и вызовам в области лингвистических изысканий, Международный семинар «Современные методы исследования звукового строя идиомов», основными объектами обсуждения которого стали вопросы фонетики, диалектологии и ареальной лингвистики, ежегодная международная молодежная научная школа «Татар гыйлеме» – «Татарская наука», на площадке которой был проведен круглый стол «Традиционная культура народов Поволжья и Приуралья: современные стратегии исследования». По итогам работы круглого стола представителями российских научных центров была поддержана инициатива создания совместной исследовательской программы, направленной на изучение межэтнических контактов в Поволжье и Приуралье. Реализация программы предполагает формирование постоянной рабочей группы, организацию экспедиционной деятельности, усиление подготовки научных кадров. (подробнее: https://www.antat.ru/ru/iyli/).

---

23-24 октября в рамках государственной программы «Реализация государственной национальной политики в Республике Татарстан» совместно с Министерством образования и науки Республики Татарстан на базе Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета прошла Международная научно-практическая конференция «Национальные литературы республик Поволжья: проблемы межкультурной коммуникации». В работе конференции приняли участие ведущие специалисты из научных организаций и вузов Российской Федерации, а также зарубежные ученые.

В рамках программы научной конференции были проведены пленарное заседание, 5 секций, где обсуждались актуальные вопросы литературной компаративистики, вопросы литературного перевода, а также заслушаны доклады по особенностям развития и современному состоянию тюркских и финно-угорских литератур Поволжья и др. (подробнее: https://ifmk.kpfu.ru/news/mezhdunarodnaya-nauchno-prakticheskaya-konferencziya-naczionalnye-literatury-respublik-povolzhya-problemy-mezhkulturnoj-kommunikaczii-2/).

---

28 октября в Институте истории им. Ш. Марджани АН РТ прошел круглый стол, посвященный столетию Зямиля Ибрагимовича Гильманова, основателя школы по изучению истории Великой Отечественной войны в Татарстане. (подробнее: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1375?ysclid=mib5s9rcim585878714).

---

4-5 ноября в г. Стамбуле (Турция) состоялась международная научная конференция «Наука в Золотой Орде». Конференция объединила ведущих специалистов научных центров по истории Улуса Джучи из Турции, России и Казахстана. Участники форума обсуждали формирование научных традиций в государстве Улуса Джучи, роль исламского образования, взаимодействие культур, развитие городов и письменности. (подробнее: https://e-history.kz/ru/news/show/50000853? ysclid=mib67plq5x318065221).

---

11 ноября в Институте истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан состоялась Всероссийская научно-практическая конференция «Каюм Насыри и его эпоха». В работе конференции приняли участие ученые из Москвы, Казахстана, Махачкалы, Уфы, Астрахани, Йошкар-Олы, Челябинска, Самары, Оренбурга и Казани. Среди ключевых вопросов, вынесенных

на обсуждение, – жизнь и творчество Каюма Насыри, вопросы просветительства XIX в., издательская деятельность в конце XIX – начале XX в., историческое наследие татарского народа, повседневная жизнь народов Урало-Поволжья, а также развитие национальных языков. (подробнее: https://tataroved.tatarstan.ru/index.htm/news/2468620.htm).

---

13-14 ноября в Казани в рамках Международного фестиваля национальных культур «Россия – Восток» («Восточный базар в Казани») состоялась II Международная научно-практическая конференция «Культурное сотрудничество со странами Востока и Азии: современное состояние и перспективы развития». В работе конференции приняли участие более 200 представителей научного сообщества – филологи, историки, искусствоведы, преподаватели вузов и аспиранты. География российских участников охватила научные центры от Москвы и Санкт-Петербурга до Бурятии и Якутии. В рамках девяти тематических секций участники обсудили широкий круг вопросов: от изучения археологических фондов и традиционного костюма до роли театра, кино и современных медиа в диалоге культур. Особый интерес вызвали исследования историко-культурного наследия народов Востока и России, а также проблемы сохранения традиций в условиях глобализации. (подробнее: https://www.antat.ru/ru/iyli/news/20051/).

---

13 ноября в рамках II Международной научно-практической конференции «Культурное сотрудничество со странами Востока и Азии: современное состояние и перспективы развития» состоялся круглый стол на тему «Книгоиздание и периодическая печать на языках народов России: исторический опыт и современные вызовы». (подробнее: http://antat.tatar/ru/iyli/news/20051/).

---

17-18 ноября в Санкт-Петербурге состоялась XXII Всероссийская научно-практическая конференция «Фаизхановские чтения», приуроченная к 200-летию со дня рождения выдающегося просветителя Каюма Насыри, к 150-летию всемирно известного религиозного философа Мусы Джаруллаха Бигиева, а также к 100-летию историка татарской книги доктора филологических наук Абрара Гибадулловича Каримуллина. В работе конференции приняли участие ведущие ученые-исламоведы, историки, теологи, искусствоведы, религиозные деятели, а также молодые исследователи, занимающиеся изучением различных аспектов историко-культурного наследия ислама в России. (подробнее: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1396).

---

20 ноября в Культурном центре им. Я. Е. Емельянова совместно с Институтом истории имени Ш. Марджани АН РТ и Общественной организацией кряшен РТ состоялся III Всероссийский форум кряшенских краеведов «Ыру агачы» («Родовое древо»), посвященный Году защитника Отечества в Республике Татарстан и Российской Федерации (организатор, модератор кандидат исторических наук Л. А. Мухамадеева). В форуме участвовали ученые и краеведы из Москвы, Санкт-Петербурга, Казани, Республики Башкортостан (г. Уфа, с. Бакалы), Челябинской области (Нагайбакский муниципальный округ), а также городов и районов Республики Татарстан. На форуме обсуждались следующие проблемы: война в истории моей семьи; герои среди нас: воспоминания фронтовиков; кряшенские родословные; методологические, источниковедческие и историографические проблемы изучения кряшенских сел и деревень; вопросы подготовки и издания книг по истории кряшенских деревень; изучение традиционной культуры и фольклора кряшен; культурные и бытовые особенности этнотерриториальных групп татар и кряшен; сельские фольклорные ансамбли: прошлое, настоящее, перспективы развития; духовная жизнь кряшенских сельских населенных пунктов: прошлое и настоящее; краеведческие музеи – «оплоты» сохранения историко-культурного наследия кряшен. (подробнее: http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/news/1398).

---

